ЯҢӘШӘБЕЗДӘГЕЛӘР ҺӘМ ЯКЫНДАГЫЛАР ТУРЫНДА

№7 (331) – ИЮЛЬ 2019

ТАТАРСТАН

TATARSTAN

ISSN 0130-2418

ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ БАСМА

1920 елдан
нәшер ителә

Мәскәү. Татарстан мәдәнияте көннәре

Йосыф морза варислары

Матур туганда, яисә Уйчан кеше

ЗИЛӘ СӨНГАТУЛЛИНА: «МИН БӘХЕТЛЕ КЕШЕ»

16+

Редакция:
420066, Казан,
Декабристлар ур., 2,
тел. (843) 222-09-79
tatarstan@tatmedia.com

БАРЫСЫНА ДА НИЧЕК ӨЛГЕРЕРГӘ?

Әле биш-ун ел элек кенә җәйне шәһәрдә уздыру коточкыч күңелсез һәм эчпошыргыч хәл иде. Әйтерсең, матәм иленә килеп эләккәнсең – отпускта булмаганнар мескен генә кыяфәттә эшкә сөйрәлә, аннан кабат өенә – капкалап алырга да, телевизор карап, йокларга. Кешеләрне берләштергән һәм бер дулкынга көйләгән вакыйгалардан нәрсәне искә алырга мөмкин соң? Бәлки, 2010 елгы корылык вакытында зарыгып яңгыр көтүнедер?

Әмма хәзер Татарстандагы җәй – үзе бер бәйрәм. Җитмәсә, чып-чын республика масштабындагы, хәтта ки Россия, дөньякүләм дәрәҗәдәге дияргә дә мөмкин. Менә, мәсәлән, Свияжскида ачык суда йөзүләр уздырдылар: Россия буйлап җыелган спортчылар рәхәтләнеп утрау тирәли йөзә, үзләре белән медальләр генә түгел, шәп кәеф тә алып кайтып китә. Югары Ослан районында гольф яратучылар өчен россиякүләм ярышлар узды, бу ярышларда Австралия һәм Чехия спортчылары да катнашты. «Алабуганың җәйге кичләре» дип исемләнгән һәм инде традициягә әйләнгән пианист Борис Березовский фестивале июль аенда Россиянең дөнья масштабындагы йолдызларын гына түгел, ә Франция белән Шотландиядән килгән абруйлы музыкантларны да җыя алды. Халыкара регаталар, фестивальләр, Red Bull Air Race ярышлары, Мөслимдәге Лэнд-Арт фестивале, Черек күлдәге фестиваль, Аксубайда узган Уяв Бөтенроссия чуваш мәдәнияте фестивале…

Саный башласаң, бармак саны җитми. Димәк, җәйне эч пошырып утырып уздырмыйсың, дигән сүз. Барысына да ничек өлгерергә – әнә шул ягын да хәл итә алсаң…

СЕЗНЕҢ РЕДАКЦИЯ.

Баш мөхәррир: Татьяна Николаевна Вафина, vafina@tatmedia.com
Шеф-редактор: Әскәр Сабиров, sabirov@tatmedia.com
Баш мөхәррир урынбасарлары:
Нияз Әхмәдуллин, ahmadullin@tatmedia.com
Алсу Дәүләтшина
Чыгарылыш мөхәррире:
Фәридә Әхмәтҗанова
Бүлек мөхәррирләре:
Ольга Туманская, Алёна Кутыркина, Руфия Фазылова
Веб-редактор: Алсу Дәүләтшина
Авторлар: Ксения Семина, Фаяз Хуҗин, Луиза Шарова
Фотографлар: Александр Ефремов, Ната Смирнова
Дизайн-макет: Леонид Гобәйдуллин
Вёрстка: Игорь Глушков, Леонид Гобәйдуллин
Препресс: Игорь Глушков
Корректор: Айсылу Корманова
Офис-менеджер: Ләйсән Һадиева
Тышлыкта Россиянең һәм Татарстанның халык артисты Зилә Сөнгатуллина. Ната Смирнова фотосы

Журнал 1920 елдан нәшер ителә

1979 елда Халыклар дуслыгы ордены белән бүләкләнә

Журнал Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәттә теркәлгән. Теркәлү таныклыгы ПИ № ФС 77 – 66045, 10.06.2016.

Татар телендә тираж: 1150 данә,
рус телендә: 2350 данә

Гомуми тираж: 3500 данә

Бәясе ирекле

Редакциянең язма рөхсәтеннән башка «Татарстан» журналындагы материалларны күчереп бастыру тыела. Күчереп бастырганда, журналның исемен күрсәтү мәҗбүри. Автор фикере редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин. Реклама материалларының эчтәлеге өчен редакция җавап бирми.

Журнал «ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексы типографиясендә басылды: 420066, Казан, Декабристлар ур., 2

Заказ № О-1892
Басарга кул куелды: 24.07.2019
Басмадан чыкты: 29.07.19

Дистрибуция һәм трафик бүлеге җитәкчесе:
Миләүшә Байрашева,
milyaushanb@tatmedia.com

Коммерция директоры:
Юлия Фәсәхова, 89272483384_pr@mail.ru
тел.: (843) 222-09-76, +7-9272-483-384

Бухгалтерия:
Ольга Басаркина, тел. (843) 222-09-80

Махсус проектлар бүлеге җитәкчесе:
Алсу Троицкая, alsu_1970@list.ru
тел.: (843) 222-09-79

Редакция советы:
АЛАЕВ Юрий Прокопьевич
АЛЕКСАНДРОВСКАЯ Ирина Алексеевна
ӘХМӘТШИН Равил Кәлимуллович
БЕЛЯКОВ Роман Юрьевич
БИКЧӘНТӘЕВ Фәрит Рәфкатович
БОЛЬШАКОВ Андрей Георгиевич
ВӘЛИЕВ Разил Исмәгыйлевич
ВӘЛИЕВА Зилә Рәхимҗановна
ГАЛИЕВ Марат Гадыевич
СӘЛӘХОВ Мәгъзум Кәлимуллович
ФӘЙЗУЛЛИН Равил Габдрахманович
ХӘКИМОВ Рафаэль Сибгатович
ХОМЕНКО Вадим Васильевич

татмедиа

Гамәлгә куючы:
«ТАТМЕДИА» АҖ
Нәшер итүче:
«ТАТМЕДИА» АҖ

420097, Казан,
Академическая ур., 2

Республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы ярдәме белән чыгарыла

«Татарстан» журналына язылу барлык элемтә бүлекләрендә кабул ителә
Индекс **П2381** – татар телендә
Индекс **П2378** – рус телендә
Ярты елга язылу бәясе: **930 сум 00 тиен**

«Татарстан» журналына РФ буенча онлайн-язылу:
Индекс **П7076** – татар телендә
Индекс **П7077** – рус телендә

«ТАТАРСТАН»НЫҢ КАРТИНАЛАР ГАЛЕРЕЯСЫ



Айрат Гайфуллин

ИЮЛЬ

ЭЧТӘЛЕК

АКЫЛЛЫ ГАМӘЛЛӘР

6. **Сәлам, Мәскәү!** Башкалада Татарстан көннәре ничек үтте

10. **Гасырларга җитәрлек байлык.** Нефть һәм газга альтернатива бармы

12. **Фәрит Мөхәммәтшин белән әңгәмә.** Үлчәнелгән карарларны ничек кабул итәргә

14. **Авылны ничек саклап калырга.** Әлки рецепты

22. **Гаилә бәхете.** Дүрт буын бергә

ИГЕЛЕКЛЕ ЭШЛӘР

26. **Редакция кухнясы.** Күренекле галимдә кунакта

32. **Кем кая, без – су коенырга.** Татарстанда Урта диңгез буе курорты кайда урнашкан

34. **Дулкыннар артыннан.** Рәхмәт, «Атабай диңгезе!»

36. **Балыклы урын.** Кайда балык кармакка үзе каба

38. **Кыслалар ни өчен кызара.** Агыйделдә ничек ял итәргә

42. **Шайтан каласы.** Тойма елгасы ярына – пикникка!

48. **Язмышлар.** «Әни кебек хатыннар сирәк»

МӘҢГЕЛЕК КЫЙММӘТЛӘР

52. **Тарихи сәхифә.** Йосыповлар нәселе

56. **Шәриф Камал.** Матур туганда, яисә Уйчан кеше

62. **Вакыт тукталышлары.** Мизгелләрне туктатырга сәләтле профессионаллар

74. **Китап киштәсе.** Читтән караш

84. **Татар авыллары.** Иң тырыш кешеләр кайда яши

Тулырак мәгълүмат түбәндәге сайтта:
www.protatarstan.ru

АКЫЛЛЫ ГАМӘЛЛӘР

23.06

Курбангулы Бирдемөхәммәдов, Төрекмәнстан Республикасы Президенты, – Казан Кремлендә Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов белән очрашуда:

– Россиянең һәм Татарстанның сәнәгать куәте бик көчле. Алда безнең халыкларның мул тормышын тәэмин итә торган күп проектлар көтә әле.

ИГЕЛЕКЛЕ ЭШЛӘР

11.06

Мартин Шонка, Red Bull Air Race очучысы, – ярышның Татарстан этабы алдыннан:

– Казан – ярыштагы иң яраткан этапларымның берсе, миңа монда, вакыт булганда, урамнар буйлап йөрү ошый, барлар, рестораннарга керергә яратам. Этап кабул итүче иң яхшы шәһәрләр рейтингын ясыйсым килми, әмма ләкин Казан анда иң беренче урында торыр иде.

МӘҢГЕЛЕК КЫЙММӘТЛӘР

07.06

Александр Карелин, РФ Дәүләт Думасы депутаты, Россия Герое, – Петербург икътисадый форумында:

– Быелтыр кунакчыл Казан Универсиададан калган инфраструктурасы белән мундиальнең меңнәрчә катнашучысын кабул итте. Әлеге тәҗрибә мәйданы дөрес ориентирларны ап-ачык итеп билгеләи. Тупланган тәҗрибәне дәүләттә булган мөмкинлекләргә кушып җибәрергә була.

АКЫЛЛЫ ГАМӘЛЛӘР

БУ САНДА ТӘКЪДИМ ИТӘБЕЗ:

Мәскәү татарлары татарстанлыларны **НИЧЕК** каршы алды

Нефть саммиты замана таләпләренә **НИЧЕК** җавап бирә

Авылны **НИЧЕК** саклап калырга

Бәхетле гаилә **НИНДИ** була

ЯҢӘШӘБЕЗДӘГЕЛӘР ҺӘМ ЯКЫНДАГЫЛАР ТУРЫНДА

ТАТАРСТАН

TATARSTAN

1 июльдән 31 августка кадәр

2020 елның 1 нче яртыеллыгына
«Татарстан» журналына алдан
язылу игълан ителә

Реклама 16+

«Татарстан» журналына ТР буенча язылу индекслары:

П 2381 **татар телендә** 931 сум 68 тиен

П 2378 **рус телендә** 931 сум 68 тиен



ПРЕЗИДЕНТ МАРШРУТЛАРЫ БУЕНЧА

Татарстан Президентының эш графигы никадәр тыгыз булуын аңлар өчен, бернинди махсус хронометраж үткәрү таләп ителми. Аның сәфәрләре маршрутына күз салу да җитә. Республика, ил, дөнья буйлап туктаусыз йөри ул. Еш кына Рөстәм Миңнеханов иртән нинди дә булса Европа илендә потенциаль инвесторлар белән сөйләшүләр үткәрергә, көндез Россия башкаласындагы мөһим киңәшмәдә катнашырга өлгерә, берничә сәгатьтән соң исә Әлмәттә нефть тармагы үсеше перспективаларын тикшерә... Һәм көн саен диярлек шундый хәл күзәтелә.

Юлда үткән сәгатьләр һәм чакрымнар, мөһим очрашулар, җитди чыгышлар һәм җаваплы карарлар. ТР Президентының соңгы арадагы эш сәфәрләреннән «Татарстан» аеруча әһәмиятлеләрен сайлап алырга тырышты.

МӘСКӘҮ.
ТАТАРСТАН МӘДӘНИЯТЕ КӨННӘРЕ

Фото ТР Президенты сайтыннан алынды (Марсель Бадыйкшин)

НӘРСӘ:

Башкалада Татарстан Республикасы көннәре

КАЙДА:

Мәскәү

КАЙЧАН:

5 июль

Сергей Собянин, Мәскәү мэры:
– Татарстан, Россиянең инвестицияләр ягыннан иң кызыклы төбәкләрнең берсе буларак, киң колачлы инфраструктур проектларны тормышка ашыра, эшлекле климатны һәм халыкның тормыш сыйфатын яхшырта торган инновацияләрне эшли һәм гамәлгә кертә. Мәскәүдә Татарстан Республикасы мәдәнияте көннәрен уздыру безнең төбәкләр арасындагы уңышлы хезмәттәшлекне үстерүдә яңа этап булыр, матур чыгышлар һәм бәйрәм рухы белән истә калыр, дип ышанам.

ТУЛЫРАК:

Татарстан Республикасы мәдәнияте көннәренең ачылышы бөек татар шагыйре Габдулла Тукай һәйкәленә чәчәкләр салудан башланып китте. Шул ук көнне Мәскәү Халыкара музыка йортында Татарстан сәнгать осталары катнашында тантаналы кичә оештырылды. Чакырылган кунаклар арасында РФ Президенты Администрациясе, РФ Хөкүмәте һәм Мәскәү мэриясе, министрлыклар һәм ведомстволар вәкилләре, РФ Дәүләт Думасында Татарстаннан һәм Башкортостаннан депутатлар, республиканың эшлекле партнёрлары, башкаладагы «Татарстан якташлык җәмгыяте», Татарстанның Тулы вәкаләтле вәкиллеге каршында профессиональ кызыксынулар буенча төзелгән клублар әгъзалары бар иде. Чарада катнашырга теләкләрен 50дән артык чит ил дәүләте вәкилләре белдерде, шул исәптән Австрия, Нидерландлар, Израиль, Финляндия, Польша, Төркия, Бәхрәйн, Мисыр, Гыйрак, БГӘ, Беларусь, Кыргызстан, Үзбәкстан һәм башка илләрнең гадәттән тыш һәм тулы вәкаләтле илчеләре дә.

Мәскәү мэры Сергей Собянинның Мәдәният көннәрендә катнашучыларга юлланган сәламләү сүзләрен Мәскәүнең Милли сәясәт һәм төбәкара багланышлар департаменты җитәкчесе Виталий Сучков җиткерде. Ул шулай ук «Мәскәү белән Татарстан арасындагы яхшы эшлекле элемтәләр урнашуын, аларның көннән-көн ныгый баруын» билгеләп үтте. «Бездә теләсә кайсы катлаулылыктагы проектларны уңышлы башкарырлык потенциал тупланды», дип тә өстәде ул.

Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов Мәскәүдә Татарстан Республикасы мәдәнияте көннәренә багышланган тантаналы кичәгә килүчеләргә, күпмилләтле республика – Татарстанның мәдәнияте белән кызыксынучыларга рәхмәтен белдерде. Аерым алганда, ул болай диде: «Россия башкаласында республикабызны күрсәтү безнең өчен куаныч. Биргә татарлар да, республикага карата битараф булмаган башка милләт вәкилләре дә килгән. Форсаттан файдаланып, мин барыгызга да әлеге мөнәсәбәтегез өчен рәхмәтемне белдерәм». Рөстәм Миңнеханов зур уңышларга ирешкән ватандашларга Татарстан Республикасы дәүләт бүләкләрен тапшырды. ТР сәнгать осталарының гала-концерты тәмамланганнан соң, Татарстан Президенты исеменнән кабул итү оештырылды.

Икенче көнне Мәскәүдә Татарстан көннәре Сабантуй бәйрәме белән дәвам итте. Бәйрәмдә төрле милләт халыклары – йөзләгән мәскәүле һәм башкала кунаклары катнашты.

БЕЛЕШМӘ:

Татарстан Республикасы һәм Мәскәү арасындагы мөнәсәбәтләр 2011 елда имзаланган Сәүдә-икътисадый, фәнни-техник һәм социаль-мәдәни хезмәттәшлек турында килешү нигезендә алып барыла. Төбәкара товар әйләнеше 78 млрд сумнан артып китте. Үзара тәэминатның нигезен машина төзелеше продукциясе (транспорт, 65%тан артык) һәм шиннар тәшкил итә. 2011–2012 елларда Мәскәүдә Габдулла Тукайга һәм Муса Җәлилгә һәйкәлләр ачылды.

Рөстәм Миңнеханов, Татарстан Президенты:
– Мәскәү – безнең стратегик партнёр, безнең арадагы товар әйләнеше 78 млрд сумнан артып китте. Күп кенә кызыклы проектлар буенча без Мәскәүдән өйрәнәбез, күпләрен уртак гамәлгә ашырабыз. Сергей Собянин һәм аның командасына рәхмәтемне белдерәм – без һәрвакыт тулы аңлашуга ирешеп эшлибез.

АКСУБАЙ. ДУСЛЫК ҺӘМ БЕРЛӘШҮ БӘЙРӘМЕ

НӘРСӘ:

Уяв Бөтенроссия чуваш мәдәнияте бәйрәме

КАЙДА:

Аксубай

КАЙЧАН:

6 июль

Фото: Александр Ефремов

ТУЛЫРАК:

Быел Уяв Бөтенроссия чуваш мәдәнияте бәйрәмен үткәрү урыны итеп Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы сайланды. Һәм бу очраклы гына түгел. Тамырлары белән ерак гасырларга барып тоташкан әлеге чуваш халык бәйрәме күптән инде күпмилләтле республикабызның мәдәни брендына әйләнде. Татарстан Президенты билгеләп үткәнчә, «Уяв – нинди милләттән булуыбызга карамастан, бүген барыбыз да бергә җыелып, күңел ача торган матур бәйрәм». Чуваш Республикасы башлыгы Михаил Игнатьевка мөрәҗәгать итеп, Рөстәм Миңнеханов болай диде: «Мин республикага бүләк ителгән әлеге бәйрәм өчен ихлас рәхмәтемне белдерәм һәм һәрвакыт мондый бәйрәмнәрне бергәләп һәм күбрәк үткәрүебезне телим».

Үз чиратында Чуваш Республикасы башлыгы Михаил Игнатьев Аксубай районында оештырылган әлеге бәйрәмне шәп һәм затлы дип атады. Ул Чуваш Республикасы, Татарстан Республикасы һәм Россия халыкларының традицияләрен, мәдәни һәм рухи кыйммәтләрен бүгенге көнгә кадәр кадерләп саклап, яшь буынга тапшыра барганнары өчен, ветераннарга рәхмәтен белдерде. «Бүгенге глобальләшү шартларында бабаларыбызның мәдәни кыйммәтләренең җуелмавы зур әһәмияткә ия», – диде Михаил Игнатьев. Ул шулай ук узган елда федераль Сабантуйның чуваш җирендә –Чебоксарда уздырылуын искә төшереп үтте.

Мәртәбәле кунакларны бәйрәм капкалары янында Татарстанның төрле районнарында гомер кичерүче чуваш этносы вәкилләре каршы алды. Рөстәм Миңнеханов һәм Михаил Игнатьев «Икмәк пешерүче йортында», «Милли кухня йортында», «Аучы йортында», «Балыкчы йортында» һәм башка ихаталарда булдылар. Шунысын да билгеләп үтик: ике республика башлыгы да чуваш милли киемнәрен кигән иде. «Мин бүген үземә бер костюм сайладым. Дустыбыз Дмитрий Самаренкин (ТР Чуваш милли-мәдәни автономиясе җитәкчесе – ред.иск.) ике мең ярым шундый костюм тектергән. Мактанып та алды, мин әйтәм: «Миңа да бир әле», – дим. Менә ике костюм бирде. Без тулысынча үзгәрдек бүген, әлеге бәйрәмнең чып-чын катнашучыларына әвереллек», – дип аңлатып китте ТР Президенты.

Аннан соң Рөстәм Миңнеханов һәм Михаил Игнатьев Уявта традицион рәвештә башкарыла торган әйлән-бәйләнгә кушылдылар, ул дуслык, тынычлык, үзара татулык, бердәмлек һәм халыкларның чәчәк атуын аңлата.

БЕЛЕШМӘ:

Татарстанда 116 меңнән артык чуваш яши, бу республикада халык саны буенча, татарлардан һәм руслардан кала, өченче этнос. 95 чуваш мәктәбендә белем бирү чуваш телендә алып барыла. Республикада 100дән артык чуваш фольклор коллективы эшли.

ӘЛМӘТ. СТРАТЕГИК КУРС ҺӘМ ЗАМАНА ТАЛӘПЛӘРЕ

Рөстәм Миңнеханов, Татарстан Президенты:
– Әлегә нефть һәм газ эрасының тәмамлануы турында сөйләргә иртәрәк. Алар илебез үсешенең стратегик ресурсы булып кала бирәчәк. Аерым алганда, нефть-газ химиясе кебек гаять тиз үсә торган эре сегментта углеводородларга альтернатива юк.

НӘРСӘ:

Татарстанның нефть саммиты

КАЙДА:

Әлмәт районы

КАЙЧАН:

12 июль

Фотолар ТР Президенты сайтыннан алынды

ТУЛЫРАК:

Нефть саммитында панель дискуссиядә чыгыш ясап, Рөстәм Миңнеханов, бүген илебезнең нефть-газ тармагы каршында җир асты байлыкларыннан рациональ файдалануга, авыр чыгарыла торган запасларны эшкәртүгә, энергия чыганакларын цифрлаштыруга һәм үзгәртүгә бәйле җитди бурычлар тора, дип билгеләп үтте. «Халыкара экспертлар якындагы дистә елларда углеводородларга ихтыяҗ артачагын фаразлый. Әлегә нефть һәм газ эрасының тәмамлануы турында сөйләргә иртәрәк. Алар илебез үсешенең стратегик ресурсы булып кала бирәчәк. Аерым алганда, нефть-газ химиясе кебек гаять тиз үсә торган эре сегментта углеводородларга альтернатива юк», – дип басым ясады Татарстан Президенты.

Ул, альтернатив генерациянең бәясе төшүгә дә карамастан, электр энергиясен туплау технологияләренең булмавы дөнья энергобалансында альтернатив энергетика өлешенең чагыштырмача аз сакланып калуына китерә, дип билгеләп үтте. «Шул ук вакытта запаслар структурасының сыйфат ягыннан начараюы – тулаем тармак проблемасы. Энергетика министрлыгы бәяләмәләренә караганда, ил буенча исбатланган запаслар күләмендә авыр чыгарыла торган нефтьнең өлеше 65 проценттан артып китә. Өстәвенә әлеге сан елдан-ел арта гына бара», – диде Рөстәм Миңнеханов.

Татарстан Президенты, Россия күләмендә табыла торган нефтьтә авыр чыгарыла торган запасларның өлеше 8 проценттан кимрәк, диде. «Бу безнең илдә нефтьнең елдан-ел фән сыйдырышлы продуктка әйләнә баруы турында сөйли. Ул фән сыйдырышлы продукциягә, инновацияле технологияләргә, кадрларга һәм сыгылмалы салым системасына ихтыяҗны формалаштыра. «Сланец революциясе» мисалында без бөтен дөнья нефть-газ сәнәгатендә яңа технологияләрнең тамырдан үзгәрешләргә этәргеч бирә алуын күрәбез», – диде Рөстәм Миңнеханов.

Татарстан Президенты шулай ук, кулланучылыкның һәм энергия ресурсларын табуның үсеше экологиягә йөкләнешнең артуына китерә, дип билгеләп үтте. «Республика нефтьчеләре, «Татнефть» компаниясе тәҗрибәсе, нәтиҗәле җитештерү контролен алып бару һәм экологик куркынычсызлыкны тәэмин итү чараларын саклау нәтиҗәсендә, табигый мохиткә техноген йөкләнешне экосистеманың үзен үзе яңарта алу дәрәҗәсенә кадәр киметү мөмкинлеге булуын раслады», – дип йомгаклады ул сүзен.

Рөстәм Миңнеханов саммит эшендә беренче Халыкара нефть-газ яшьләр форумы делегатлары катнашуын да искәртеп үтте. «Әлеге чара яшьләрнең һөнәри потенциалын ачуга һәм перспективалы хезмәттәшлек нигезләрен формалаштыруга этәргеч бирер, дип ышанам. Моннан тыш, безнең яшь коллегаларыбыз, нефтьчеләрнең өлкән буыны тәҗрибәсенә һәм инновацияле технологияләргә таянып, тармак каршында торган актуаль таләпләргә үзләренең нәтиҗәле җавапларын бирергә сәләтле», – диде ТР Президенты.

Саммит кысаларында Рөстәм Миңнеханов нефть өлкәсенә караган алдынгы технологияләр күргәзмәсе белән дә танышты, андагы экспонатлар илебез компанияләре тарафыннан тәкъдим ителгән иде.

МАКСАТЛАР **БЕРДӘМЛЕГЕ** ҺӘМ ФИКЕР **ТӨРЛЕЛЕГЕ** ТУРЫНДА

Фәрит Мөхәммәтшин, Татарстан Дәүләт Советы Рәисе, яңа парламентны нинди итеп күрергә теләве хакында

Хакимиятнең вәкиллекле органнары һәр биш ел саен республика халкының турыдан-туры күпчелек тавыш бирүе нәтиҗәсендә кабат сайлана. Без моңа әзер. Вәкилләрне партияләр буенча, бермандатлы сайлау округларында сайлаячаклар. Бу юлы да республика парламентына иң лаеклы, әзерлекле, татарстанлылар тормышына битараф булмаган кешеләр сайлансын иде. Иманым камил, шулай булачак та.

Һәр сайлауда парламент 30–40 процентка яңара. Быел да шундый яңару булыр, дип уйлыйм.

Сайлау булачак кайбер төбәкләр, «Бердәм Россия» партиясенең рейтингы төшүдән һәм үзләренең күпмедер кешесен җирле парламентларга үткәрә алмавыннан шикләнеп, пропорцияләрне үзгәртте. 50 гә 50 иде: илле – бермандатлы округлар буенча, илле – партия исемлеге буенча. Кайбер төбәкләр бермандатлы округларга – 75, партия исемлекләре буенча 25 кә алыштырды. Бездә исә мондый сорауның беркайчан да туганы булмады.

Бүген «Бердәм Россия» партиясе рейтингы ышанычның шактый югары булуын күрсәтә. Халык яхшы аңлый: Татарстан Юстиция министрлыгында теркәлгән 53 сәяси партиядән әлеге сәяси көрәштә нибары 5–7 се, хәтта моннан да кимрәге генә катнаша. Һәм, билгеле инде, күп кеше бик аз халык яклаган сәяси партиягә ышаныч белдерүдән курка.

Халык «Бердәм Россиянең» кеше һәм финанс ресурслары барлыгын, зур сәяси, хуҗалык тәҗрибәсе булуын яхшы аңлый. Татарстаныбыз Президенты Рөстәм Миңнеханов – «Бердәм Россия» партиясе югары советы бюро әгъзасы, мин – партия генераль Советы Президиумы әгъзасы, без үзебезнең шик-шөбһәләребезне яки тәкъдимнәребезне партия структурасы аша федераль үзәккә җиткерәбез. Безнең арада, оялып, башка лагерьга күчүчеләр юк!

Мин ТР Дәүләт Советы Рәисе буларак парламентта берничә сәяси партия эшләве яклы. Төпле законнар кабул итү өчен бәхәсләр һәм төрле фикерләр кирәк. Минем өчен бу мөһим, мин бүген парламентта булган барлык партия вәкилләренә зур ихтирам белән карыйм. Бу – нинди дә булса партиядә торулары буенча яки үзләренең иҗтимагый эше нигезендә төркемләшкән кешеләр. Аларның үз аргументлары һәм дәлилләре булырга мөмкин, һәм аларны тыңларга кирәк, без шулай эшлибез дә.

Мин Дәүләт Советында карала торган бөтен нәрсәгә каршы чыгучыларны өнәмим. Әгәр син каршы киләсең яки канәгать түгелсең икән, максатка ирешүдә үз юлыңны күрсәт. Тәнкыйтьлисең икән – тәкъдим ит! Һәм без алар белән мөнәсәбәтләрне шул рәвешле урнаштырырга маташабыз.

Безнең парламентның шоу ясау, бер-береңә су сибү, пиджакның тискәресен әйләндереп кию һәм үзеңнең яки тагын кемнеңдер шәхси мәнфәгатьләрен яклау бурычы юк. Без үзебезне җаваплы тоябыз – кешеләр безгә ышаныч белдергән, безнең өчен тавыш биргән бит, үз вәкаләтләренең бер өлешен 5 елга без, депутатларга, тапшырган. Минә бу хис, нинди генә фракция вәкиле булса да, бер депутатның да күңеленнән китмәскә тиеш.

Парламент – төрле сәяси (шул исәптән оппозицион да) партия вәкилләренең булуы закон рәвешендә беркетелгән бердәнбер хакимият органы ул. Хөкүмәткә оппозицияне җыймыйлар, бирегә исә төрле карашлы вәкилләр сайлана. Алар белән бергә дөрес чишелешне табу, уртак фикергә килү-бөтен сәнгать тә менә шуннан гыйбарәт.

Партия әгъзалары теге яки бу партия мәнфәгатьләрен кайгыртырга тиеш. Әгәр без үз партиябезне дә өч-дүрт өлешкә бүлсәк, халык каршында кем җавап тотар? Кечкенә партияләргә бүленгән оппозициядән әллә ниләр таләп итеп булмый. Парламентның күпчелеген тәшкил иткән партиядән сорыйлар, билгеле. Әлеге җаваплылыкны зур сәяси партия үз өстенә алырга, сайлаучыларның

наказларын үтәрлек, аларның тормыш сыйфатын яхшыртырлык куәткә ия булырга тиеш. Парламентта яңгыраган нинди дер тозсыз сүзләр аркасында бүлгәләнү – мәгънәсезлек.

Россия эчендәге әһәмиятле проблемалар милли проектларны гамәлгә кертү хисабына хәл ителәчәк. Алар бүгенге көндә – 12, һәм тагын бер комплекслы план. Халык бу турыда белә һәм нәтиҗәне көтә. Без әлеге процесска кешеләрнең үзләрен дә җәлеп итәбез. Шәһәр һәм район территориясендәге бер генә проект та халык белән киңәшләшмичә тормышка ашырылырга тиеш түгел, дибез. «Бердәм Россия» партиясе гражданнарны битарафлыктан уятмакчы, үз тормышларын яхшырту өчен кирәкле карарларны кабул итүгә тартмакчы була. Без күпчелек тавыш белән проектның зарурлыгы турында карар кабул итәбез, аннары аны ТР Төзелеш министрлыгында, ТР Хөкүмәтендә яклыйлар, республика белән уртак финанслау максатыннан федераль акчалар дәгъвалыйбыз. Әлеге максатка һичшиксез ирешелергә тиеш.

Сайлау кампанияләре үткәрү субъектның сәяси активлык һәм сәяси культура дәрәҗәсен күрсәтә. Безнең республикада сәяси культура һәм активлык югары. Сайлаучыларның җаваплылыгы югары, катнашучылар күп. Мин алтынчы чакырылыштагы яңа парламентның бик күп кеше катнашкан сайлауларда формалашуын һәм республикабыз халкына җаваплы хезмәт итүен телим. ▪

Материал «Андрей Кузьмин белән галстуксыз әңгәмә» программасы нигезендә әзерләнде.

АВЫЛНЫ НИЧЕК САКЛАРГА: ӘЛКИ РЕЦЕПТЛАРЫ

Автор:
Фәридә Хәбибуллина

Бу темага күп сөйләнә, әллә нинди теләк-киңәшләр бирелә, әмма конкрет гамәлләрдән яхшырак нәрсә әлегә кадәр уйлап табылмаган. Конкрет гамәлләр исә Әлки районында башкарыла. Һәр авылда, Каргалы кебек зурларында да, Татар Чиябашы кебек кечкенәләрендә дә, халык җан-фәрманга яшәргә тырыша.

ТАТАР ЧИЯБАШЫ. КЕЧКЕНӘ ДӘ ТӨШ КЕНӘ

Татар Чиябашы – кечкенә генә һәм бик матур авыл. Ул Чиятөш елгасы буенда – район үзәге Базарлы Матактан 36 километрга көньяктарак урнашкан. Тагын шундый ике кечкенә авыл белән бергә Чиябашы авыл җирлегенә керә. Өч торак пунктта яшәгән 258 кешегә өч мини-ферма һәм бер крестьян-фермер хуҗалыгы туры килә, алар үз сөт белән авылдашларын да тәэмин итә, дәүләткә дә тапшыра. Бу Әлки районы башлыгы Александр Никошинның авылда хуҗалык итүнең кече формаларын кертү турындагы өметен тулысынча аклый – ул нәкъ менә шулар авылны салап калырга тиеш, дип исәпли.

Фото: Азат Низамиев

– Йорт саен берәр сыер асрау уңайсыз. Әгәр кеше ниндидер оешмада эшли икән, аңа тагын терлек тә асрау кыенга килә. Ахыр чиктә без шуңа ирешәчәкбез: һәр авылда биш-алты, җиде-сигез сыер асраучы кечкенә хуҗалыклар һәм унбиш-егермедән алып иллегә кадәр сыер асрый торган зур крестьян-фермер хуҗалыклары пәйда булачак. Болай эшләгәндә, авыл халкы да сөт белән тәэмин ителә, дәүләткә сөт сатып, шактый яхшы керем дә алып була. Авылны, бигрәк тә 30–40 йорттан торган кечкенәләрен саклар өчен, һәр авылда 3–4 мини-ферма булырга тиеш.



СОЛТАН ӨЧЕН ГАИЛӘ ЭШЕ

Түбәсенә иярченле тәлинкә куелган өр-яңа фермага карап фикер йөртсәң, Татар Чиябашында КФХ яхшы эшли.

Керәбез. 50 сыер, мөгезле башларын улакларыннан күтәреп, кунакларны дустанә кыяфәт белән, кызыксынып күзәтә – янәсе, килгәнсез икән, кадерле кунаклар, керегез инде һәм безнең колак артын бераз кашысагыз да була. Ә менә үгез бер дә кунакчыл түгел. Таныш түгел яңа кешеләр аның ачуын чыгара – ул мышный һәм тоягы белән җирне төя. Испан корридасын көткәндәй, күзен кан баса...

– Бу үгез бик усал безнең, – дип аңлата мөгезле эре терлекнең мондый кыланмышын Чиябашы авыл җирлеге башлыгы **Илфат Сәмигуллин.** – Сөзеп егарга да мөмкин. Күптән түгел хәтта хуҗасын да сөзә язган. Шунлыктан аны сатарга җыеналар.

Куркудан хәрәкәтсез калып диварга сеңгән хәбәрчеләрне җирлек башлыгы крестьян-фермер хуҗалыгы башлыгы **Нияз Минсабиров** белән таныштыра:

– Ул бу фермага грант отты, – ди Илфат. – Үзеннән кала, фермасында тагын биш кеше эшли: сыер савучылар, каравылчы, терлекче. Биредә 60 баш мөгезле эре терлек асрыйлар. Таналарны баш санын арттыру өчен калдыралар, үгезләрне саталар – ит белән шөгыльләнүгә караганда, сөтчелек файдалырак. Әле ул үгезләр үсеп җиткәнче... Менә бездә бер мини-фермадагы дүрт сыердан көн саен 50 шәр литр сөт тапшыралар – шактый табыш килеп чыга. Ә монда исә 50 сыер!

Фермер Нияз үзенең биләмәләрен күрсәтә – сыер абзары, көтүлек, тракторлар, «КАМАЗ»... Янәшәдә генә ниндидер төзелеш бара.

– Тагын бер корпус төзисем килә, – дип, сорау биргәнче үк аңлата Нияз. – Аннары шунда бозауларны күчерер идем.

Нияз – фермерлар нәселеннән, аның әтисе дә туган авылында фермерлык белән шөгыльләнгән. Хәзер инде ул – үзе әти һәм, гаилә эшен ышанычлы кулларга тапшырыр өчен, төпчек улы Солтанның үсеп җитүен көтә.

– Улыңа ничә яшь соң?

– Әле дүрт кенә, – дип елмая Нияз. – Тик ул фермада гел минем белән, булыша, күнегә, команда бирә...

– Солтан үсеп җиткәндә хуҗалыгың нинди рәк булыр икән, бу турыда уйлаганың бармы?

– Әлегә бурыч түлибез. Ул вакытка кадәр түләп бетерермен дип өметләнәм, – ди Нияз. – Малларның баш санын йөзгә җиткерергә ниятлим – никадәр күбрәк булган саен, шулкадәр яхшырак. Тагын бер корпусны төзеп бетерербез. Сөт эшкәртү белән дә шөгыльләнергә ният бар...

ЯШЬЛӘР ӨЧЕН ЭТӘРГЕЧ

Әлки районында булачак фермер Солтан Минсабиров кебекләр өчен авылны үстерү һәм авыл халкына булышу буенча яңа программаларны гамәлгә кертәләр.

– Программага Мәскәү 24 триллион сум акча бүлә, – ди Александр Никошин. – Бу акча нигездә торак төзелешенә бирелә. Торак белән тәэмин итүнең берничә варианты карала. Әлки районында инде 700 дән артык гаиләгә торак сатып алу өчен акча бирелде. Бераз катлаулырак булды, чөнки сумманың 70 процентын республика һәм Россия Федерациясе бирде, 30 процентын исә торак алырга теләүче үзе табарга тиеш иде. Бу авыл кешесе өчен шактый зур акча. Әйтик, йорт 1,5 миллион сум торса, аның 30 проценты 450 мең сумга тәңгәл! Бөтен яшь кешенең кесәсендә 450 мең сум ятмый бит. Хәзер исә процентны киметү мәсьәләсе тикшерелә. Авылда торак алучы бәянең 30 процентын түгел, 10 процентын гына үзе түләсен иде. Миңа тагын торакны арендага бирү темасы ошый. Әйтик, авылда салынган йортта кеше 5 ел яши – 5 елдан соң өйне бәянең 10 процентына сатып алырга мөмкин. Тагын 10 елдан соң, бәянең 1 процентын түләп була. Ул вакытка кадәр инде кеше ияләшә һәм аның китәсе дә килми башлый. Менә бу бик шәп стимул.

– Мондый программа, хуҗалык итүнең кече формалары кебек үк, авылны аякка бастырырга ярдәм итәчәк, – ди Чиябаш җирлеге башлыгы. – Яшьләрнең авылда каласы килми, пенсионерларга исә терлек асрау авыр. Без фермалар оештырудан башладык, һәм эш әкренләп алга китте. Бәлки, уңайлы шартлар тудыргач, яшьләр дә авылда кала башлар иде.

– Малларның баш санын йөзгә җиткерергә ниятлим – никадәр күбрәк булган саен, шулкадәр яхшырак. Тагын бер корпусны төзеп бетерербез. Сөт эшкәртү белән дә шөгыльләнергә ният бар, – диде Нияз Минсабиров.

– Тулаем күләме тонна ярым тәшкил иткән ярымфабрикатның яртысы пилмәнгә туры килә, аның өч төрлесен – вагын, уртачасын, эресен ясыйбыз.

КАРГАЛЫ. ПЕРСПЕКТИВАЛЫ ЗУР АВЫЛ

Зур гына Каргалы авылы Базарлы Матактан 10 километр ераклыкта, Актай елгасының ике ярында урнашкан. 140 йорты бар – бүгенгә көн өчен бу зур авыл санала. Шунлыктан Каргалы җирлегенә башка авыллар керми, үз халкы да җитәрлек. Биредә яшьләр дә шактый – район үзәгенә якында урнашкан бит. Хуҗалык итүнең кече формалары турында сөйләгәндә, биредә аның кулланучылар кооперативы формасын аерып атап буладыр.

– Бахила киябез! – дип команда бирә «Әлки» кулланучылар кооперативының әзерләүләр пункты директоры **Илсур Гыйбадуллин.** – Монда безнең бөтен нәрсә стериль – халат, башлыклар киегез, зинһар.

Бөтен кеше тиешенчә киенгәч кенә, дәвам итә:

– Ит сатып алу белән шөгыльләнәбез. Безнең җитештерү өчен яңа суйган ит кирәк. Челтәребез зур. Ә менә биредә, цехта, төрле ярымфабрикатлар җитештерәбез.

САФ АВЫЛНЫКЫ, ЧЫП-ЧЫН

Цехта безне «Әлки» кулланучылар кооперативы рәисе **Агыйдел Турнина** каршы ала.

– Биредә иттән ризык әзерлибез, – дип таныштыра ул үзенә ышанып тапшырылган бина белән. – Аена тонна ярым эшкәртәбез. Сыйфат өчен көрәшәбез, шунлыктан бездә бернинди өстәмәләр юк, бары авылда суелган чын ит кенә. Шәһәр халкы безнең продукцияне махсус килеп ала, пилмән, ит чумары, кәтлит, мантыйларны күпләп алып китәләр... Безнең кечкенә кибетебез бар, ул шәһәрдән кайтучылар өчен махсус якшәмбе көнне дә эшли.

– Чын иткә өстенлек биреп кенә базарда озак чыдарсызмы икән соң? Гадәттә җитештерү башланганда гына шулай була, аннары, практика күрсәткәнчә, чын ит еш кына төрле ясалма өстәмәләр белән алыштырыла...

– Әлегә барысы да әйбәт бара. Бездә 10 кеше эшли. Илсур абый – хәзерләүче, ит чабучылар бар, кызлар пилмән ясый. Шәп һәм тату коллектив тупланган. Җиһазларыбыз яхшы – бик тиз туңдыра торган ике аппаратыбыз бар. Аларда пилмән ап-ак булып кала, үзенең товар кыяфәтен югалтмый. Гади суыткычта исә камыр тиз арада каралып китә бит.

ПЛАНДА – «ХӘЛӘЛ» ҺӘМ ЫСЛАУ ЦЕХЫ

Без 2018 елның октябрендә ачылдык. Әлки районы хакимияте, үзе белән бергәләп, шундый хәзерләү конторасы булдыруыбызны үтенде. Әмма безнең үз продукциябезне дә җитештерәсе килде. Барысы да ниятләгәнчә килеп чыкты. Хәзер сугым цехы турында хыялланабыз. Бу очракта без «хәләл» маркалы продукция чыгара алачакбыз. ТР Диния нәзарәтеннән мөфти килгән иде, үз сугым цехыгызны төзесәгез, хәләл ризык җитештерүгә рөхсәт бирәчәкбез, диде.

Моннан тыш әле ыслау цехы да ачарга телибез. Кимендә тагын биш эш урыны пәйда булачак..

ПИЛМӘННӘН ТУТЫРМАГА КАДӘР

Продукция авылда да күп сатыла. Тулаем күләме тонна ярым тәшкил иткән ярымфабрикатның яртысы пилмәнгә туры килә, аның өч төрлесен – вагын, уртачасын, эресен ясыйбыз. Мантый ике төрле – ит белән һәм ит-бәрәңге белән. Кәтлит, ит чумарлары... Эчәк-бавырдан тутырма ясыйбыз, әлеге татар милли ризыгын шәһәр халкы бик яратып ала.

ИҢ МӨҺИМЕ – ТОРАК, ЭШ ХАКЫ ҺӘМ ЯЛ ИТҮ УРЫННАРЫ

– Күрәсезме, бүген никадәр мәсьәлә хәл ителә, – дип, сәяхәтебезгә йомгак ясый Әлки районы башлыгы. – Райондагы 69 торак пунктның барысына да юл салынган. Һәр авылның үзәк урамына асфальт җәелгән. Һәр баганага яктырткыч куелган. Үзара салым программасына рәхмәт – үзебез халыктан 5 миллион сум җыйсак, тагын 20 миллион сумны дәүләт бирә. Тулаем күләме 25 миллион сумга тәңгәл акчага юлларны ремонтлыйбыз һәм яктыртабыз, зиратларны төзекләндерәбез, парклар системасына булышабыз, су-газ буенча эш алып барабыз...

Әмма иң мөһиме, әлбәттә, яшьләрне авылда калдыру, аларга уңайлы шартлар тудыру. Хуҗалык итүнең кече формалары белән шөгыльләнә башлаучыларның күпчелегенә хәзер илле-алтмышар яшь. Биш елдан соң да сыер асрарга аларның хәленнән килерме? Сә-

ламәтлекләре нинди булыр бит аларның. Ә менә балаларының авылда яшәргә калуы зарур. Аларга исә торак кирәк. Шунлыктан хәзер безнең бурыч мондый: һәр ферма янәшәсенә йорт салып куюу һәм фермерга: «Менә бу синең улыңа!» – дип әйтү. Улы, йорт булгач, кызыгачак! Нишләп кайтмасын ди ул? Бик нык шәһәрдә яшисе килсә дә, кайтачак. Бездән Казанга кадәр – 132 чакрым гына ара. Бу сәгать ярым-ике сәгатьлек юл инде. Теләсә кайсы вакытта машинасына утыра да, концертка, спектакльгә бара ала. Казанлылар башкаладагы бөкеләр буйлап шәһәрне ике сәгать үтә, без исә шул вакыт эчендә районнан Казанга килеп җитәбез! Кеше рәхәтләнеп шәхси хуҗалыгында эшли һәм, Казанга барып, теләсә кайсы чараны карый ала. Юл бар, күпер бар. Шунлыктан хуҗалык итүнең кече формалары – авылны саклау, авылның демографик халәтен саклау ул. Халык китмәсен өчен, мәктәпләрне, иң әүвәл башлангыч мәктәпләрне саклау зарур. Балалар бакчаларын, инфраструктураны сакларга кирәк. Бу хәзер эшләнә дә – мәктәп-бакчаларны ремонтлау, спорт мәйданчыклары һәм клублар төзү мөмкинлеге биргән республика программаларына рәхмәт! Элегрәк авылда спорт мәйданчыклары, парклар, клуб зоналары бар идемени? Эштән соң ял итү урыны да булырга тиеш бит. Иң мөһиме – торак, эш хакы һәм ял итү урыны. Болар барысы да бергә булса, кеше авылда калачак. Һәм эшләячәк.

Әлки белән хушлашып, пилмән һәм тутырма сатып алабыз, һәм инде баганаларында утлар кабынган якты кичке урамнардан үтеп, кунакчыл районнан китәбез. Үз күзебез белән күреп, үз колагыбыз белән ишеткәннәр авылны ничек тә саклап калып булыр дигән өмет уята. Моның өчен Әлки халкы кебек җиң сызганып эшкә тотынырга гына кирәк икән! Т

Тутырманы шәһәрлеләр күп сатып ала.

Фото: Н. Гришин

КАЗАН ГИПРОНИИАВИАПРОМЫ – ЗАМАНЧА ПРОЕКТЛАР ИНСТИТУТЫ

2019 елның 27 маенда Яр Чаллыда КАМАЗ һәм Mercedes-Benz өчен кабина каркасларын җитештерү буенча яңа завод ачылды. Объектның сафка басуында «Казан Гипронииавиапромы» АҖ белгечләренең дә өлеше зур. Нәкъ менә әлеге проектлар институтына «КАМАЗ» ГАҖ шундый күләмле һәм югары технологияле проектны әзерләү эшен ышанып тапшырды. Бу аңлашыла да, күптән түгел «Алабуга» МИЗда институт проекты буенча төзелгән «Форд» двигательләре һәм автомобильләрен җитештерү заводлары эшли башлады.

ИҖАДИ ХЕЗМӘТТӘШЛЕК

– 4 ел дәвамында без «КАМАЗ» ГАҖ белән, аерым алганда, проект-төзелеш департаменты директоры Рөстәм Фәхретдинов һәм проект җитәкчесе Владислав Пастушенко белән тыгыз элемтәдә эшләдек, – дип сөйли проектның баш инженеры Николай Галанцев. – DAIMLER немец компаниясе – инвесторлар, җитештерү технологияләрен һәм технология җиһазларын уйлап табучылар һәм тәэмин итүчеләр белән хезмәттәшлек иттек. Шулай ук буяу цехларын җиһазлау өчен җавап бирүче – DURR, роботлаштырылган эретеп ябыштыру линияләре белән тәэмин итүче Comau компанияләре белән эшләдек. Бергә эшләү вакытында әлеге кызыклы, катлаулы һәм уникаль объектны сафка бастыру буенча яңа проект чишелешләре туды.

SFTP кабиналар җитештерү заводы логистика, эретеп-ябыштыру, энергия үзәге булган буяу цехларыннан тора, мәйданы 68 мең кв.метрдан артып китә. Егәрлеге – елына 55 мең кабина.

КОНСТРУКТИВ ХӘЛ ИТЕЛЕШЛӘР

Проектка беренчеләрдән булып институтның баш конструкторы Георгий Никитин һәм төзелеш бүлеге җитәкчесе Рөстәм Сафиуллин кул астындагы конструктив карарлар белгечләре кереште. Заводның концепциясен эшләү буенча техник бирем институт хезмәткәрләре алдына катлаулы бурычлар куйды. 2015 елның сентябрендә үк фундамент, аннары каркас сызымнары әзер иде. Проект чишелешләрен этаплап тикшерү төзелешне 2016 елның мартында башлап җибәрергә мөмкинлек бирде.

– Бина эчендә өслекне күтәреп торучы колонналар арасын зуррак итү кирәк иде, моның өчен өслекне каплау проектлары таләп ителде, беренче чиратта, бу логистика һәм эретеп-ябыштыру цехлары өчен актуаль. Технология җиһазларының зур басым ясаячагын исәпкә алгач, колонналарның тимер-бетон каркасларына шактый күп арматура кирәк булып чыкты, – дип аңлата Рөстәм Сафиуллин. – Без үз алдыбызга мөмкин кадәр кечерәк колонналар кулланып конструкциянең архитектура ягыннан җиңеллеген тәэмин итү бурычын куйдык. Конструкциянең техник таләпләренә туры китереп, колонна эченә зуррак диаметрлы арматура урнаштыру мөмкинме соң?

Моның өчен стандарт булмаган чишелеш кирәк иде, без арматураны бер-бер артлы тоташтыруга нигезләнгән классик ысулдан баш тарттык. Арматураларны берсе өстенә берсен урнаштырып, муфталар белән тоташтырдык. Әлеге технология кыйммәтрәккә төшсә дә, заказ бирүчегә ошады, чөнки төзелешне тизләтә һәм эш сыйфатын күтәрә. Бу технология буяу цехындагы күләмле каплау балкалары өчен бигрәк тә отышлы булды, конструкцияне бетонлаганда бушлыклар калдырмаска мөмкинлек бирде.

Буяу цехында тимер-бетон колонналарга һәм балкаларга детальләр тоташтыру өчен «химия анкерлары» принцибы буенча махсус җилем кулландык. Арматураның конструкция эченә урнашу дөреслеген сканер ярдәмендә тикшердек. Әлеге мәгълүматларны кулланып, тоташтыру элементлары анкерлары өчен тишекләр бораулаучы калыплар ясадык. Нәтиҗәдә, алмаз коронкалар белән бораулаганда арматураның төзеклеген саклап калуга ирештек. Тишекләргә махсус җилем тула, шул рәвешле тоташтыручы элементлар нык беркетелә.

ЭНЕРГИЯНЕ САКЛАУ ТЕХНОЛОГИЯЛӘРЕ

Проект өстендә берьюлы берничә бүлек белгечләре эшләде. Җылылык, җилләтү һәм суыту системаларын проектлау өлкәсе өчен бүлек җитәкчесе Алла Хәлиуллина һәм әйдәп баручы инженер Ирина Жидкова җавап бирде.

– Сәнәгать җитештерүе бина эчендә зарарлы матдәләр бүленеп чыгуына китерә, бу очракта көчле һава алмашу системасы кулланылырга тиеш, – дип сөйләде Алла Евгеньевна. – Елның салкын вакытында җитештерү мәйданына килүче һаваны – җылытырга, эссе чорда суытырга кирәк. Шуңа күрә җылылык, җилләтү һәм суыту системаларын проектлау эшендә энергияне саклау технологияләренә игътибар бирдек.

Уңышлы чишелешләрнең берсе – логистика цехында түшәмдә урнаштырылган панельле-нурлы сулы җылылык системасы булды. Әлеге технология буенча электр энергиясе кулланылмый һәм эксплуатация вакытында техник хезмәт таләп ителми. Панельләр бинаны тигез җылыта, температура чынбарлыктагыдан 3 градуска югарырак кебек сизелә. Димәк, кулай темпе-

Реклама

Фотолар «Казан Гипронииавиапромы» АҖнән алынды



САННАР ГЫНА:

- 68 787,68 мең кв. м мәйданлы корпус
- 3 мең тонна металл конструкция
- 49 куб. м бетон
- 6,4 мең кагылган свай
- 574 колонна
- 106 итальян роботы
- 700 эш урыны
- елына 55 мең кабина каркасы

ратурага азрак җылылык энергиясе тотып ирешелә.

Башка цехларда җилләтү системасы өчен роторлы рекуператорлар нигезендә эшләүче җиһазлар куйдык. Алар ярдәмендә куыла торган һава үзенең җылысын салкын һавага бирә, шул рәвешле җылылык энергиясе саклана. Ә елның җылы вакытында рекуператорлар шул ук принцип буенча салкынны да экономияли.

ПРОЕКЛАУДА BIM-ТЕХНОЛОГИЯЛӘР

Завод өчен проект эшләре мәгълүмати модельләштерүнең инновацияле технологияләренә нигезләнеп башкарылды.

– Институт белгечләре һәм технология җиһазларын эшләүчеләр арасында килештерү эшләре булачак заводның 3D-моделе ярдәмендә алып барылды, – дип аңлата проектның «Казан Гипронииавиапромы» АҖнең BIM-координаторы Марат Сафиуллин. – Бик яңа, кызыклы тәҗрибә булды. Аралашу шулкадәр тыгыз булды, һәрбер миллиметр өчен көрәшергә туры килде. Ләкин иң катлаулы мәсьәләләрне дә кыска вакыт эчендә хәл итүгә ирештек.

Проектның башка бүлекләре буенча эшләгән белгечләр дә уртак хезмәткә зур өлеш кертте: архитектура төркеме җитәкчесе Наталья Детинкина, су белән тәэмин итү һәм калдык суларны чыгару бүлегенең баш белгече Александр Соболев, янгын сүндерү төркеме җитәкчесе Пётр Чугунов, сәнәгать үткәргечләре буенча төркем җитәкчесе Илназ Шәйхетдинов, җылылык белән тәэмин итү бүлегенең баш белгече Валерий Охотин, электриклар төркеме җитәкчесе Мөдәррис Динмөхәммәтов.

ЛАЗЕРЛЫ СКАНЕР КУЛЛАНУ

Лазерлы сканер технологиясе ярдәмендә төзелеш-монтаж эшләрен контрольдә тоту белән әйдәп баручы инженер Леонид Рисин һәм геодезия төркеме җитәкчесе Андрей Тиховидов шөгыльләнде.

Лазерлы сканер куллану – институтның көндәлек тәҗрибәсе. Әлеге технология тирә-якның детальләштерелгән нокталы сурәтен һәм панорама фотосын алырга мөмкинлек бирә. Нәтиҗәдә, төзелгән бинаның, андагы инженер коммуникацияләренең һәм урнаштырылган технология җиһазларының төгәл 3D-моделе формалаштырыла. Бу исә кирәкле барлык үлчәүләрне башкарырга, теләсә кайсы яссылыктагы кисемнәрне карарга мөмкинлек бирә. Тикшерү программасы автомат режимда проекттагы 3D-модель һәм «ничек төзелгән» 3D-модель (бинаның узеллары һәм конструкцияләренең, инженер конструкцияләренең үзара урнашуы проблемасы) арасындагы тәңгәлсезлекләрне күрсәтә, алар кичекмәстән төзәтелә.

ТӨЗЕЛЕШНЕ ТЕХНИК ЯКТАН ТӘЭМИН ИТҮ

Әйдәп баручы инженер-куратор Алексей Аткишкин инженер системаларын монтажлый башлаганнан алып заводта булды һәм төзелешнең техник яктан тәэмин ителешен күз уңында тотты.

– Мин объектның актуаль 3D-моделе һәм эш документациясе булган ноутбукны кулымнан да төшермәдем, – дип сөйли Алексей Аткишкин. – Түшәм асты өлешендә төрле инженер системаларының күпсанлы магистраль үткәргечләре урнашкан. Проектта каралган күрсәткечләрдән тайпылышлар булырга тиеш түгел. Шуңа күрә миңа проекттагы чишелешләрнең дөреслеген һәрвакыт раслап, подрядчылар эшен күзәтеп, тикшереп торырга туры килде. Без чит ил коллегаларыбыз һәм заказчы белән даими рәвештә производство киңәшмәләре уздырдык, килеп туган сорауларны урыннарда ук хәл итә барлык.

«КАМАЗ» ГАҖ 3 ел эчендә проект егәрлегенә – елына 55 мең кабина каркасын җитештерү күрсәткеченә ирешергә планлаштыра.

Хәзерге вакытта халыкара дәрәҗәдә эшләү тәҗрибәсе булган инженерлар командасы яңа инновацияле проектларга җәлеп ителә. Ә уңышлы башкарып чыккан проект «Казан Гипронииавиапромы»ның илебез оборона һәм сәнәгать комплексы объектларын проектлаштыру өлкәсендә әйдәп баручы институтларның берсе булуын тагын бер кат раслады.

Казанский Гипронииавиапром

420127, Казан ш.,
Дементьев ур., 1 йорт
Тел.: (843) 571-95-48
Факс: (843) 571-96-56

ЗИЛӘ СӨНГАТУЛЛИНА: «МИН БӘХЕТЛЕ КЕШЕ...»

Июль аенда Россиянең һәм Татарстанның халык артисты, Татарстан Республикасының Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты, Н. Г. Җиһанов исемендәге Казан дәүләт консерваториясенең вокал сәнгате кафедрасы мөдире, профессор Зилә Сөнгатуллина үзенең юбилеен билгеләп үтә. Зилә Даян кызы татар һәм бөтендөнья җыр сәнгате өчен берничә буын җырчылар тәрбияләде, опера сәхнәсендә кабатланмас образлар тудырды. Хәзерге вакытта да газиз alma mater* укучыларына белем бирүен дәвам итә ул. Быел җырчы күпьеллык нәтиҗәле иҗади эшчәнлеге өчен «Татарстан Республикасы алдындагы казанышлары өчен» ордены белән бүләкләнде.

– Сезне Казан консерваториясенә легендар Нәҗип Җиһанов эшләргә чакырган дип беләбез...

– Әйе. Укытучым Валентина Андреевна Лазько киткәндә, Җиһанов аның мәктәбен дәвам итүчене эзләде. Ул елларда безнең төп педагогларыбыз – Зөләйха Хисматуллина, Владимир Воронов – эштән китте. Шундый четерекле вакытта Нәҗип Гаяз улы бер төркем яшь укытучыларны – Галина Ластовка, Юрий Борисенко, Эдуард Трескин, Алла Фадеичеваны чакырып, кафедраны саклап калды. Хәзер инде без Айрат Имашев, Филүс Каһиров, Екатерина Лейдер, Любовь Добрынина кебек яшьләрне җыярга тырышабыз, үз вакытында Гөлнара Мурзиеваны чакырдык.

– Сез театрда эшләгән вакытта ук консерваториядә укыта башлагансыз. Кыен булмадымы?

– Бик авыр булды. Операда мин аена 15 шәр спектакльдә уйный идем. Иртән консерваториягә килеп, укучылар белән шөгыльләнәм, аннары оркестр репетициясенә барам. Тәҗрибәм җитеп бетмәгәндер инде, дәресләр вакытында мин бик күп җырлый идем. Бер укучым нәкъ минем тембрны, башкару манерасын кабатлый башлады. Шул вакытта мин һәр укучының үзенчәлеген ачарга кирәк икәнлеген аңладым.

– Укучыларыгызның кайсылары чын-чынлап уңышка ирешә?

– Максим Аксенов – Мариинка театры артисты, искиткеч тенорлы башкаручы. Лилия Гобәйдуллина – халыкара конкурслар лауреаты, хәзерге вакытта Литвада яши. Тагын бер сәләтле укучым – Лариса Васюхина – хәзер Германиядә. Гульнора Гатина – үзебезнең опера театры солисты, аның да мөмкинлекләре зур. Сәрвәр Кадыйров исемле тагын бер укучым халыкка танылды, ул шулай ук безнең опера театрында җырлый. Россия буенча, Көньяк Кореядә һәм башка илләрдә барлыгы 60 укучыбыз сайлаган һөнәре буенча уңышлы гына эшли.

Консерваторияне бит аны төрле пландагы җырчылар тәмамлый. Филүс Каһиров, мәсәлән, театрда да нәтиҗәле эшли алыр иде, аның актер һәм вокалист буларак сәләте зур. Бүгенге көндә Филүс бездә укыта һәм мин аның киләчәктә яхшы педагог булып җитешәчәгенә ышанам.

– Опера театрына сез консерваторияне тәмамлауга ук килдегезме?

– 5 курста укыганда стажерлар төркеменә эләктем. Доницеттиның «Любовный напиток» операсындагы Адина партиясен ышанып тапшырдылар. Театрдагы беренче ролем Кальманның «Фиалка Монмартра» опереттасындагы Виолетта булды. Бу рольне башкару миңа бик нык ярдәм итте – үземне тамашачы алдында иркен тотарга өйрәндем, опереттада бии дә белергә кирәк бит әле. Гомумән, театрда эшләгәндә икенче тапкыр белем алу этабы башлана. Әгәр консерваториядә вокал нигезләрен өйрәнсәң, театрда инде гамәли тәҗрибә туплыйсың.

– Сезгә репертуар сайларга ярдәм итүче булдымы?

– Әйе, режиссер Нияз Даутов яшьләр өчен программаларны бик оста төзи иде. «Травиата»да син 7 елдан соң җырлаячаксың, дип әйтеп куйды ул миңа башта ук. Хаклы булган. Тәҗрибәсез җырчы шундый катлаулы рольне башкара аламы соң?! 15 елдан соң мин инде лирик партияләр дә, лирик-колоратур партияләр дә җырлый ала идем. Микаэла, Мими, Марфа, Иоланта – бу рольләрне мин табигый тавышымның мөмкинлекләрен кулланып башкардым. Аннары тагын да көчлерәк булган Дездемона, Тамара партияләренә алындым. «Зиләнең тавышы драматик рольләргә дә ярашлы икән бит!» – дип гаҗәпләнүчеләр күп булды. Мин бары тик булган тавыш мөмкинлекләреннән тиешенчә файдалана белдем.

– Сезнең язмышка тагын кемнәр йогынты ясады?

* Áльма-мáтер

– Валентина Андреевна Лазько мәктәбе ярдәмендә мин тавышымны саклап кала алдым, ул безне табигый итеп җырларга өйрәтте. Училищеда минем белән искиткеч педагог – Лилия Әхмәт кызы Кәримова эшләде. Консерваториягә керү имтиханнарына соңга калганнан соң, сәләтемә ышанган кешеләр минем өчен ректор белән очрашу оештырды. Җыр һәм бию ансамбле җитәкчесе, композитор Александр Ключарев үзенә солист итеп чакырды. Баш тарттым, чөнки укыйсым килде. Тенор Фәхри Насретдинов, вокал кафедрасы мөдире Зөһрә Бәйрашева да тормышымда зур роль уйнады. Бәхетемә, тыңлау оештырылды һәм Җиһановка мин ошадым. Бик зур теләк белән укырга керештем. Минем белән бер курста Ренат Ибраһимов, Рубин Абдуллин укыды, аларның кабатланмас шәхесләр булуы башта ук сизелде. Без көне-төне сайлаган һөнәребез турында гел уйладык, күп укыдык, архивларны тыңладык. Уку еллары тынгысыз һәм эчтәлекле булды, кыска гына вакыт аралыгында опера театрында эшләр өчен әзерләнергә кирәк иде.

– Бу мөмкин идеме соң?

– Укытучыларым ярдәмендә мин моңа ирешә алдым шикелле. Консерваториядә «Травиата», «Севильский цирюльник», «Алтынчәч»тәге әйдәп баручы партияләрдән өзекләрне өйрәндем. Безнең хәтта нәфис гимнастика дәресләре дә булды, аларны Венера Мөстәкыймова алып барды. Сәхнә хәрәкәтен Камал театрының танылган актрисасы Шәхсәнәм Әсфәндиярова укытты, биюгә опера театрыннан килеп балерина өйрәтте. Киләчәктә театрда хезмәт итәр өчен безгә бөтен мөмкинлекләр дә тудырылды. Аннары, эшли башлагач, нәрсәгәдер тотынып, башкарып чыга алмаган очраклар булмады, безне чын профессионал итеп әзерләделәр. Үзем дә бөтенесенә зур җаваплылык белән әзерләнә идем, чыгышымны һәрчак белеп тордым, дирижерлар үзләренә карап башламаган өчен үпкәлиләр дә иде! Ә мин сәхнә тормышы белән яшәдем, ни өчен игътибарымны башкаларга юнәлтеп, рольдән бүленеп торырга кирәк соң?

– Сәхнә буенча партнерларыгызның кайсылары аеруча исегездә калды?

– Тенор Геннадий Васько сәхнәдә минем беренче партнерым булды, ул искиткеч актер һәм вокалист иде. Мөгаен, аның ярдәмендә үземне шулай иркен тота алганмындыр. Аннары Тамара Синявская, Олег Кленов, Владимир Атлантов һәм башкалар белән эшләдем. Үзенчәлекле җырчы Хәйдәр Бигичевны аерып әйтмичә булдыра алмыйм, аңа яраклашырга кирәк иде. Ул калыпларны, чикләүләрне яратмады, ләкин аның тавышында кирәкле бөтен төсмерләр дә яңгыраш таба алды. Һәм бу төрлелек шулкадәр киң, аңа башка берни дә эшләргә кирәкми иде. Һәрбер роле аның үзенә туры килде. Баһадир Җик, кызу канлы Хозе, көнче Отелло – алар барысы да Хәйдәр Бигичевның үзенә охшаганнар.

Ул мине, Отелло ролендә, спектакльдә чынлап торып буды! Күрәсең, дөреслеккә туры китереп уйнар өчен аңа актерлык техникасы җитеп бетмәгәндер, ул барысын да ихлас, чынлап башкара иде. Аның каравы, тамашачыларга бик ошады! Зур Кремль сараенда «Кара йөзләр. Каһәрләнгән мәхәббәт» операсын куйганда, бөтен зал елады. Бу спектакль өчен без Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт премиясенә лаек булдык.

– Тормышыгызда нинди вакыйгаларны хәлиткеч дип саныйсыз?

– Аерып әйтүе кыен. 1996 елда Швейцариягә халыкара икътисадый форумга баруым истә калган. Без анда Ренат Ибраһимов һәм Мәскәү оркестры белән бергә барган идек, дөньяның 6 телендә җырларга туры килде. Минемчә, Татарстанның яңа эшлекле элемтәләре урнашуда артистларның роле зур булды – безнең салон игътибар үзәгендә иде. Швейцариядән без Россия, Татарстан өчен зур горурлык хисләре белән әйләнеп кайттык. Беренче абруйлы исемемне – Каракалпакстанның халык артистын – мин 80 нче елларда алдым. Күп эшләвемә дә карамастан, Татарстанда ул вакытта мин хәтта атказанган исемен дә алмаган идем әле. Каракалпакстанның мамык басуларында без көн саен 6–7 концерт куйдык, эшчеләр өчен 47 градус эсседә җырладык. Безнең бригадада, ялгышмасам, хатын-кызлардан мин үзем генә идем. Фидакарь хезмәтемне исем биреп югары бәяләделәр. Мин аннан горурланып кайттым – менә бу вакыйга иде! Аннары Татарстанның халык артисты исемен бирделәр.

Фото: Ната Смирнова

– Сез бит әле иҗтимагый эш белән дә шөгыльләндегез?

– 90 нчы елларда мин шәһәр советы депутаты идем. Миңа иң катлаулы район – Борисковоны беркеттеләр, авыр тормыш шартларында калган гаиләләр белән эшләргә туры килде. Аларның өйләренә бара идем. Хәзер уйлыйм: шул вакытта тотып суярга да мөмкин булганнар бит мине! Хулиганнарны үз спектакльләремә чакыра башладым. Моның өчен иң җиңел опера һәм опереттаны сайлап алдым. Таныш кешесе театрда җырлагач, кызыклы булгандыр инде. Болай эшләвемнең алга таба файдасы тигәндер дип уйлыйм, араларында тәртипкә өйрәнгәннәре дә бар. Балалары үсеп җитеп, минем белән урамда исәнләшеп уза. «Зилә, бу бандитларны син каян беләсең соң?», – дип сорыйлар иде. Мин: «Алар инде бандит түгел», – дип җавап кайтарам. Аннары 7 ел буе Иҗтимагый палатада гражданнарны кабул иттем. Күпме кешегә ярдәм итә алганмындыр, белмим. Ләкин мин кулдан килгәннең барысын да эшләдем.

– Бүгенге көндә иҗат юлын башлап кына җибәрүче яшь җырчыларга нинди теләкләрегез бар?

– Белемгә, камиллеккә омтылырга, кешеләргә карата игътибарлы булырга кирәк. Мин үзем бик тә төрле кешеләр белән аралашырга, теләсә кайсы мәсьәләне хәл итәргә өйрәндем, дип уйлыйм. Мөгаен, бу тәҗрибә һәм акылга бәйледер. Мин бәхетле кеше – көн саен транспортта барганда төрле буын кешеләреннән рәхмәт сүзләрен ишетәм, артист өчен бу – иң зур бүләк! Һәркемгә дә халыкка мөмкин кадәр якынрак булыгыз, дип телӛр идем! Шулай булганда, халык та сезне таный. Т

Әңгәмәне
Александра Нагорнова алып барды.

БЕР ӨЙДӘ – ДҮРТ БУЫН

Әлеге гаиләдәге иң өлкән кешегә – 77, иң кечесенә 3 яшь тулган. Дүрт буын бергә яшиләр: дәү әни, ул-килен, аларның балалары – яшь гаилә һәм нәни оныклар. Татар халкы элегрәк гел шулай берничә буын бергә гомер кичерсә дә, бүген мондый хәлне сирәк очратасың. Ил күләмендә Гаилә көнен билгеләп үткән көннәрдә без Арча районына юл алдык. Дүрт буын бергә яшәүче гаиләне үз күзләребез белән күреп кайтасыбыз килде.

ХЫЯЛНЫ – БАЛАЛАРГА!

Сафиннар гаиләсе Арча районының Яңа Сала авылында гомер кичерә. Йортларын эзләп озак йөрисе булмады, авыл үзәгендә генә яшиләр икән. Каршыга өч-дүрт яшьлек ике малай очрады. Һич ятсынып тормыйча, безнең белән аралашып алдылар да:

– Әйдәгез, бөтен кеше өйдә! – дип, үзләре артыннан иярттеләр.

Чынлап та, йорт тулы кеше, кемнең кем икәнен чамалап бетереп тә булмый. Барысы белән дә кул биреп күрешкәч, түр якка уздык.

Фото: Лилиана Вәлитова

Автор:
Руфия Фазылова

– Башта әни белән сөйләшегез инде, гаиләбезнең иң өлкән кешесе ул, – диде гаилә башлыгы Айрат абый.

Нурания апа күркәм бер тыйнаклык белән улына елмаеп карап алды:

– Бу нигезгә 1964 елда килен булып төштем, – диде ана кеше. – Ирем Илгиз Яңа Саланың дәрәҗәле егетләреннән санала иде, гармунчы, төс-биткә дә карап торырлык. Бер авылдан булсак та, кечкенәдән аралаштык дия алмыйм. Егет-кыз булып җитешкәч, ул миңа ничектер игътибар күрсәтә башлады. Берсендә, күрше кызы белән клубтан кайткач, капка төбендә кич утырдык. Дәү-дәү атлап Илгиз килеп җитте. Минем белән сөйләшәсе килгәнне күреп, күрше кызы сәбәп тапты да, өенә кереп китте. Шулай очраша башладык. Мин ул вакытта колхозда хисапчы булып эшли идем. Бер елга якын аралашып йөргәч, никах укыттык. Миңа 23 яшь иде.

Нурания апа тормыш иптәше Илгиз абый белән дүрт бала – ике ул, ике кыз тәрбияләп үстергән. Төпчек кызы Нуриясе генә читкә киткән, башкаланың 167 нче мәктәбендә татар теле, әдәбияты укыта. Калганнары – авылда. Иң олы улы, Ринаты, гаиләсе белән Яңа Салада яши. Икенчесе, Айраты, үзләренең янында калган. Олы кызлары, Энҗесе, күрше Каенсар авылында яши, клуб мөдире булып эшли.

– Яшь чакта бик нык укытучы буласым килде, – ди Нурания апа. – Балаларга дәрес бирәм икән, дип, төшләремә дә керә иде. Тик, күрәсең, Аллаһы Тәгалә язмаган булган.

– Алай бик зур теләк булгач, укырга иде, – дим Нурания апага.

– Мөмкинлек булмады шул, – ди ул. – Мәктәптә сигез класс бетергәч, ике ел колхозда төрле эшләрдә эшләдем дә хисапчы итеп алдылар. Бүгенгедәй хәтерлим: колхоз рәисе чакырып китерде дә: «Мәктәптә яхшы укыгансың икән, әйдә, безгә эшкә кил», – диде. Мәктәп директоры да шунда иде, ул да кыстады. Өлкән кешеләрнең сүзен тыңлап кына: «Ярар, эшләп карыйм, булдыра алмасам, китәм», – дидем. – «Арчага барып, укытучылыкка укыйсым килә», дип тә өстәдем. Тик эшкә бер алынгач, ничек ташлап китәсең инде? Менә шулай укытучы һөнәре хыялда гына калды. Шул сигез класс белемем белән колхозның бөтен исәп-хисап эшләрен алып бардым. 1999 елга кадәр эшләдем, хезмәт стажым 38 ел. Лаеклы ялга чыккач та ике ел эшләттеләр әле.

Аның каравы, Нурания апаның хыялын балалары тормышка ашырган. Ике улы, бер кызы – укытучылар. Кызы бүген дә укыта, ә уллары мәктәптән киткән. Яңа Сала урта мәктәбендә башлангыч сыйныфлар гына калган шул.

– Абый пенсия ала, өйдә генә эшли, мин исә авыл җирлеге башлыгы булып урнаштым, – диде Айрат абый.

ИКЕ ТӘКӘ БАШЫ БЕР КАЗАНГА СЫЯ?!

Нурания апа иренә караганда каенасы белән күбрәк гомер иткән. Тормыш иптәше илле биш яшендә кинәт йөрәк өянәгеннән үлгән. Ә менә каенанасы Миңниса әби 102 яшькә кадәр яшәгән.

– Каенанам авылның абыстае булды, – ди Нурания апа. – Бик уңган, чиста-пөхтә карчык иде. Урын өстенә калып та тилмереп ятмады. Үләр алдыннан ике ай гына авырып йөрде дә, бакыйлыкка күчте. Урыны җәннәт түрләрендә булсын, мин аннан разый...

– Нурания апа, – дим. – 46 ел каенана белән яшәп, төрле чаклар булгандыр. Сават-саба шалтыраган чакларда нишли идегез?

– Әлбәттә, төрле чаклар була тормыш алып барганда. Ачу килгәч, бер-ике көн эндәшмичә торасың да, шуның белән уза инде. Хуҗалык, ир, балалар бар, сөйләшмичә ничек торасың? Шуны әйтим – беркайчан да соңгы сүзне өздереп әйтмәдем, сабыр булдым.

– Ике тәкә башы бер казанга сыймый, диләр. Сезнең аш бүлмәсендә кем хуҗа иде? – дим.

– И, сеңлем, эш кем хуҗа булуда түгел! Мин көне буе эштә, әни кайткан җиремә ашарга пешереп тора. Ашыйм да хайваннар янына чыгып китәм. Шулай булгач, аш бүлмәсендә дә, башкасында да ул хуҗа булган инде. Һәм моның бер начарлыгын да күрмим. Эштән әзергә кайтасың, балалар каралган, өй җыештырылган. Тагын ни кирәк? Без кем хуҗа, дип баш ватмадык. Хәер, хәзер киленем белән дә шулай яшибез.

– Миңа калса, дилбегә күбрәк дәү әни кулында иде кебек, – дип сүзгә кушылды Айрат абый. – Әни бик сабыр ул, тавышланып йөри торган кеше түгел.

Нурания апа елмаеп куйды:

– Сабыр булмасаң, каенанаң белән генә түгел, ирең белән дә яши алмыйсың, – диде.

– Ә хәзер дилбегә кем кулында? – дим Айрат абыйга.

– Ир кеше буларак, мөгаен, миндәдер. Тик шунысын да әйтим: әнинең ризалыгыннан башка өйдә бер нәрсә дә эшләнми. Хатыным белән башта үзара сөйләшкәч: «Тукта, әни нәрсә дип әйтер?» – дибез. Без бала вакытта әти белән әни шу-

лай әбидән киңәш сорап эшлиләр иде. Бу хөрмәт кенә түгел, ә тормыш алып бару уңайлы булсын өчен дә кирәк. Әни безгә караганда өйдә күбрәк тора, эшли, димәк аңа ничек җайлы, шулай итәргә кирәк.

Сафиннарның йортлары заманча, ике катлы. Тормышлары җитеш. Күп итеп мал-туар, тавык-чеби асрыйлар.

– Мин бу нигезгә килгәч, яшәгән өченче йортым инде, – диде Нурания апа. – Килен булып төшкәндә каенатамнан калган иске йорт иде. Ул сугышта һәлак булган, аны белмим дә. 1968 елда Илгиз белән яңа йорт салып чыктык. 2000 елны яндык без. Мал-туар белән «Нива» машинасын санамаганда, бернәрсәсез калдык. Аннан Айрат менә шушы йортны салып чыкты. Авыл халкы, туганнар бик булышты. Мең рәхмәт аларга!

«УЛЫН ЯРАТКАЧ...»

Айрат абыйның тормыш иптәше Гөлнара ханым без сөйләшкәндә гел читтәрәк йөрде. (Камыр ризыклары пешергән икән, соңыннан гына белдек.) Аннан соң:

– Менә эшем бетте инде, – дип, безнең янга килеп утырды.

Гөлнара апа да укытучы икән. Арча педагогика училищесын тәмамлагач, Яңа Сала мәктәбенә җибәргәннәр аны. Айрат абый белән аларны мәктәп таныштырган һәм кавыштырган. Икенче уку елы тәмамланыр алдыннан, март аенда туй иткәннәр.

– Иң болгавыр заманда – 1991 елда өйләнештек, – диде Айрат абый. – Өч көн өйдә туй иттек. Әти белән әнигә шаккатам, ничек ризык табып бетергәннәрдер.

– Бөтен балаларыбызга да шулай зурлап туй ясадык, Аллага шөкер, – дип елмаеп куйды Нурания апа.

Минем исә Гөлнара апаның күңел кылларын тарткалап карыйсым килде: ике каенана, каената белән яшәргә ничек ризалык бирде икән?

– Улларын яраткач, риза буласың инде... Мин килгәндә, әле ике каенана гына түгел, өчәү иде, – диде Гөлнара апа. – Ул вакытта әнинең үги әнисе дә монда яшәде.

Бактың исә, Нурания апаның әтисе, хатыны вафат булгач, икенче тапкыр үзләренең авылларындагы Хәерниса әбигә өйләнгән. Ун еллап яшәгәннән соң, бабай да бакыйлыкка күчкән. Хәерниса әбинең үз балалары булмаган. Хәле авырайгач, Нурания апа, иреннән ризалык алып, үги әнисен үзләренә алып кайткан. Карчык аларда өч-дүрт еллап яшәгән.

– Авыр туфраклары җиңел булсын. Намаз укыганда каенанам, үз әти-әнием, Хәерниса әби өчен дә дога кылам, – диде Нурания апа.

Сөйләшә торгач, бер «сер» чишелде: Айрат абый белән Гөлнара апа, өйләнешеп азрак вакыт үткәч, чыгып китәргә уйлашкан булганнар икән. Хәтта авылдан бер йорт алып, аны ремонтлаганнар да. Тик гаиләдәге зур фаҗига яшь гаиләне бу адымыннан кире кайтарган.

– 1995 елда әти кисәк кенә үлеп китте, – ди Айрат абый. – Әни белән әбине шундый авыр хәсрәт килгәндә ялгызларын калдырып чыгып китеп булмый иде, билгеле. Ул турыда авыз ачып сүз әйтергә дә кыенсындык.

– Ә ни өчен чыгып китәргә уйлаган идегез? – дим Гөлнара апага.

– Әти белән әни яшьләр, рәхәтләнеп тормыш итәрдәй кешеләр иде әле. Алар да, без дә үзебезчә яшик, дигән идек. Әйтәләр бит: кеше берне уйлый, Аллаһы Тәгалә икенчене бирә. Юк, төп йортта калганыбызга бер дә үкенмим. Әни булмаса, ул өч баланы ничек үстерер идек. Бакчасыннан алып кайтты, ашатты, юындырды, хәстәрләде. Инде хәзер оныкларның балаларын карый. Әйтергә дә уңайсызрак: көндәлек эшләрнең күбесе әни җилкәсендә. Без көне буе эштә. (Гөлнара ханым Яңа Салада мәктәп башлангычка калгач, Арчага йөреп эшли башлаган).

Төп нигездә калган ир белән хатын ике ул, бер кыз үстергәннәр. Төпчек кызлары Зәринә әле мәктәп укучысы. Ә менә улларының икесе дә өйләнгән инде. Олы малай Рузил гаиләсе белән – Арчада, кечесе Альмир үзләре белән төп йортта яши. Кызганыч, яшь килен белән танышып булмады, Дилә әтисе янына киткән иде. Аның каравы, аларның уллары – өч яшьлек Данир белән дүрт яшьлек Зөлфәтне күреп сокландык. Гармунда да уйнап күрсәттеләр, бик ягымлы балалар.

– Альмир белән Дилә үзләре сезнең белән яшибез, дип әйттеләрме? – дим.

– Әле олы малай да башта гаиләсе белән монда яшәде, – ди Гөлнара апа. – Улларыбыз авылны ярата шул. Шуңа да шәһәргә китәселәре килми. Дөрес, Казанга йөреп эшлиләр, авылда эш юк бит.

– Яшь гаилә башка чыгарга теләмиме? – дип, Гөлнара апага сорауны икенче төрле биргән булам.

– Юк. Ә нәрсә, йорт зур, рәхәтләнеп яшәсеннәр. Бүлмәләр күп, икенче кат та бар. Безгә генә ул булмады. (Көлә.) Йокы бүлмәсе – стенка арты иде. Әле ул да икегә бүленгән: чаршауның бер ягында – каенанам белән каенатам, икенче ягында без йокладык.

Гаилә кыйммәтләре турында сөйләшә-сөйләшә ике сәгатьтән артык вакыт узганын сизми дә калганбыз. Ә бит Сафиннарны икенче яктан да ачарга кирәк – унга якын үгез, чабышкы атлар тоталар алар. Атлар белән төрле ярышларга да йөриләр, колынлата да саталар. 30 гектар җирләре бар. Быел җир эшкәртү өчен техника да сатып алганнар.

– Малайлар белән бергә эшлибез, – ди ата кеше. – Бездә хәзер пай җирен алучылар шактый. Үзем авыл җирлеге башлыгы булгач, күбрәк мал асраган кешеләрне: «Җир пайларыгызны алыгыз, үзегез эшкәртегез», – дип өндим. Малларга җитәрлек азыкны үзең үстереп тә була бит.

Яңа Саланың бу күркәм гаиләсе бездә генә түгел, укучыбызда да соклану тудыргандыр, дип өметләнәм. Гаилә бәхетләре кителмәсен, берүк.

ИГЕЛЕКЛЕ ЭШЛӘР

БУ САНДА ТӘКЪДИМ ИТӘБЕЗ:

Фаяз Хуҗин **НӘРСӘ** белән сыйлый

Татарстанда Урта диңгез буе курорты **КАЙДА** урнашкан

Балыкчылар **КАЙДА** балык тотарга ярата

Татарстанда «җилкуарлар» **КАЙДА** җил куа

Татарстанда «Нууксио» фин милли паркын **КАЙДА** күрергә була

ТАТАРСТАН
Татарстан
ТАТАРСТАН

Редакция кухнясы

Автор:
Руфия Фазылова

ГАЛИМНӘР ИТЛЕ БӘРӘҢГЕНЕ НИЧЕК ӘЗЕРЛИ?

Редакциябезнең күптәнге дусты Фаяз абый Хуҗинга һәрчак сокланып калабыз. Төгәл, зыялы һәм бик аралашучан кеше. Ә тирән белеме турында әйткән дә юк инде. Идел буе Болгар дәүләте, Алтын Урда һәм Казан ханлыгы археологиясен өйрәнгән санаулы галимнәрнең берсе ул. Ерак тарихны өйрәнсә дә, һәр яңалык турында хәбәрдар, һәр экспериментка әзер кеше ул. «Редакция кухнясы»нда берәр тәмле ризык пешерергә тәкъдим иткәч тә, Фаяз абый каршы килмәде.

«РИЗЫКНЫ ХАСИЯТЛӘП, БӨТЕН ШАРТЫН ТУРЫ КИТЕРЕП ӘЗЕРЛИБЕЗ!»

Фаяз абый белән аларның өч бүлмәле фатирында очраштык. Хуҗа кеше белән башта бүлмәләр буенча «экскурсия» ясап чыктык. Тормыш иптәше Гөлнур апа белән икәү генә гомер итәләр икән. Берданбер кызлары Нью-Йоркта яши. Төрек егетенә кияүгә чыгып, шунда күченгәннәр.

– Ә бу минем эш кабинетым, – диде, Фаяз абый түр яктагы бүлмәгә кергәч.

Стенаның ике ягында торган шүрлекләргә күз төште. Китаплар белән шыплап тулган алар.

– Китаплардан башка булмый, – ди ул. – Әле болар биштән бер өлеше генә. ТР Фәннәр академиясенә бик күп китапларымны бүләк иттем. Хәзер анда минем исемдәге аерым бер фонд бар.

Аш бүлмәсенә чыккач, әңгәмәдәшем ипләп кенә өстәлгә ризыклар чыгара башлады.

– Нәрсә әзерлибез? – дим.

– Запеканка. Тиз эшләнә ул.

Хуҗа кеше бәрәңге әрчергә кереште.

– Ризык әзерләгәндә иң яратмаган эшем – бәрәңге чистарту, – диде ул. – Кабыгын да калын әрчим, озак та була кебек.

– Ә көндәлек тормышта ашарга пешерергә туры киләме? – дим.

– Сирәк дисәм дә була. Болай үзе күп ризыкларны әзерли алам, ягъни җаен беләм. Алты баланың иң өлкәне бит, плитә янында күп торырга туры килде. Студент елларны әйткән дә юк инде. Эшли башлап, экспедицияләргә йөргәндә тагын пешердем. Соңрак, җитәкче булырак, аш-су әзерләүне дә контрольдә тоттым. Өйрәтәсең, күрсәтәсең, дигәндәй. Һич онытмыйм: берсендә ике кыз токмач пешерергә алынды. Карасам, болар капны ачтылар да токмачны юарга керештеләр.

– Кызлар, нишлисез? Токмачны пешкәч кенә юалар, – дим. – Гаҗәпләнделәр. Шундый кызык та, кызганыч та хәлләр булгалый иде.

Фаяз абый бәрәңгене әрчеп бетерде. Шуннан электр миченә куя торган савытны алды да аның төбенә фарш салды. Аны бөтен савыт буенча тигезләп җәйде, һәм өстенә тоз, борыч сипте.

ФАЯЗ ХУҖИННАН ЗАПЕКАНКА РЕЦЕПТЫ:

Кирәк булачак (4 порция өчен):
1. Иттарткычтан чыгарылган ит – 300 г
2. Бәрәңге – 4–5 данә
3. Суган – 3 баш
4. Сыр – 150 г
5. Майонез
6. Борыч – чама белән
7. Тоз – чама белән

Фото: Лилиана Вәлитова

РЕДАКЦИЯ КУХНЯСЫ

Татарстан Фәннәр академиясе мөхбир әгъзасы, тарих фәннәре докторы, Татарстанның атказанган фән эшлеклесе, Фән һәм техника өлкәсендә Татарстан дәүләт премиясе лауреаты Фаяз Хуҗинда кунакта.

– Мин элек борыч ашамый идем, хәзер исә ярата башладым. Файдалы икән ул, эчәклекләрдәге начар бактерияләрне үтерә, – диде.

Ирләр өчен иң авыр саналган эшкә (хәер, кайбер хатын-кызлар өчен дә) – суган турарга кереште.

– Суганны нәзек итеп, ярымбоҗралап турарга кирәк, – диде.

Фаяз абыйның күзәтәм: һәр эшен җиренә җиткереп башкара. Суганны турап бетергәннән соң, ярымбоҗраларны бер-берсеннән аерды. Аннан ит өстенә рәт-рәт итеп тезә башлады.

– Сез бик пөхтә кеше бугай, – дим Фаяз абыйга.

– (Көлә.) Тәртип яратам, әйе, холкым ул минем. Кечкенәдән шундый идем...

Тарихчы бәрәңгене яртыга бүлде дә, аны да ярымбоҗралап турады, һәм суган өстенә салды. Дөресрәге, берәм-берәм куеп, тезеп чыкты.

– Хатын-кызлар болай утырмый инде, ничек туры килсә шулай сала да, бетте китте, – дим.

– Әйе, шулайдыр. Ирләр хатын-кызларга караганда тәмлерәк пешерә, диләр. Һәм бу һич кенә дә арттыру түгел. Без сирәк әзерлибез бит. Шуңа ризыкны хасиятләп, бөтен шартын туры китереп әзерлибез. Ә хатын-кыз шул арада баласын да карый, керен дә юа... Йөз эше таралып ята, дигәндәй. Ә без плитә каршыннан китмибез.

Бәрәңгеләрне тезеп бетергәч, Фаяз абый сыр алды. Аны, угычтан уып, бәрәңге өстенә сала барды.

– Булды, – диде хуҗа кеше. – Хәзер 180 градуска кадәр кайнарлатылган электр мичено куябыз, унбиш минут пешерәбез.

«СЫЕР ДА САУДЫМ»

Без исә иркенләп өстәл артында сөйләшүебезне дәвам иттек. Фаяз Хуҗин – Казанның 1000 еллык тарихын дәлилләгән галимнәрнең берсе дә әле ул. Аның бу өлкәдәге эзләнү-тикшеренүләре турында шактый яздылар инде. Ә безне галимнең балачагы, археологиягә килүе кызыксындырды.

Тумышы белән Зәй районының Карман авылыннан ул. Урта мәктәпне күрше Бигеш авылында тәмамлаган. Аннан Казан дәүләт педагогика институтының тарих-филология факультетына кергән. Ул вакытларны менә ничек искә алды:

– Әдәбият, тарих белән кызыксынуым кечкенәдән килде. Китапханәләрдә китап калмагач, хәтта елый идем. Бер кызык гадәт турында сөйлим әле: уйнап арыгач, агач бура эченә кереп китап укый идек. Берәү укый, калганнар тын да алмый тыңлап утыра. Бүгенге күзлектән чыгып караганда, гаҗәп әйбер бит бу.

Ә институтның тарих бүлегенә керүем... үз теләгем булды. Әле дә истә: беренче имтихан рус теленнән изложение иде. Миңа калса, аны махсус беренче куйганнар: 80 процент абитуриент шунда ук төшеп калды. Рус телем яхшы иде, изложениене «5» кә яздым. Дөрес, бер хатам бар иде, тик барыбер билгене киметмәгәннәр. Ничек алай булгандыр, үзем дә аптырыйм. Икенче имтихан – тарихтан. Анысы тагын бер кыйсса! Ашыгудан, өйдә билге куела торган мөһим кәгазьне онытып калдырганмын. Вакытлыча яшәп торган фатирым Тукай урамында иде. Институттан шунда йөгердем. Кайтсам, ишек бикле. И, хәзер имтиханга соңга калам да укырга керә алмыйм инде, дим. Бәхеткә, фатир хуҗасы кайтып керде. Кош тоткандай кире институтка йөгердем. Имтиханга иң соңгы булып кердем. Сорауга җавап биргәнче, указка сорап алдым. Укытучылар башта аптырап калды. Аннан картага төртеп күрсәтеп сөйли башладым. Укытучыларга бу алымым нык ошады, хәтта мине башкаларга үрнәк итеп куйдылар. Менә шулай кабул итү имтиханнарын җайлы гына тапшырып, студент исемен йөртә башладым.

Фаяз абый өеннән бер тиен акча алмый, стипендия акчасына гына яши. Ни өчен дигәндә, күп балалы гаилә, әнисе авырый, бер әтисе эшләгән акчага тагын биш баланы ашатырга кирәк.

– Балачак еллары шактый авыр иде безнең, – дип, хатирәләре белән уртаклашты Фаяз абый. – Мин беренче класста укыганда әнием авырый башлады. Әтинең дә аягы гарип иде. Өйдә берсеннән-берсе кечкенә энекәш, сеңелкәшләр бар. Ничектер өйдәге бөтен эш минем җилкәгә төште. Идән юу, сыер саву... Миннән соң туган Миргаяз энем күбрәк колхоз эшендә булды, ат җикте. Менә шулай үстек. Аллага шөкер, тора-бара әни аякка басты.

Фаяз абый боларны зарланып, үзләрен кызганып сөйләми. Ә бәлки киресенчә, тормышта төшеп калмавының, тырыш булуының сәбәбе турында фикер йөртә.

Ул арада унбиш минут узып та киткән икән.

– Запеканканы әзерләп бетерәсе бар, – диде ул.

Электр мичен ачып, Фаяз абый ризыкны өстәлгә алып куйды. Бүлмәгә хуш ис таралды.

– Юк әле, булмады, – дип, хуҗа кеше эрегән сыр өстенә майонез якты. Һәм шуннан соң янә ризыкны электр миченә пешерергә куйды. Тагын утыз минут торырга тиеш икән.

СӨЙКЕМЛЕ СӨЯК

Фаяз абый үзенең укытучылары турында бик яратып, тәмләп сөйли. (Бу мизгелдә аның күзләре яктырып китә, йөзендә бер нур барлыкка килә). Күңел сандыгында һәр укытучысы белән бәйле аерым вакыйгасы бар аның. Узган ел «Бигешем – яшел бишегем, мәктәбем – яшьлегем тугае» дип атап, үзе укыган белем бирү йорты турында китап бастырып чыгарган. Фәкать үз тырышлыгы белән! Затлы, эчтәлекле басма.

– Без өч параллель классны 90 укучы тәмамладык. Биш ел саен очрашабыз. Телефоннан аралашып торабыз. Исән укытучыларыбыз белән дә даими сөйләшәбез, хәлләрен белеп кайтабыз, – диде Фаяз абый.

Кайберәүләр турында «Бәхетле йолдыз астында туган кеше» дип әйтәләр. Бер мәлгә танылган тарихчы-галимгә дә уңыш һич көтмәгәндә елмайган кебек тоелды.

Педагогика институтына җиңел генә укырга керүен бер исәпкә алсак, укып бетергәч тә, бәхетле очраклар гел көтеп тора аны. Югары уку йортын тәмамлап, Зәй районының Кадер сигезьеллык мәктәбенә укытырга кайта ул. Авыл балаларын мавыктыргыч тарих дөньясына җәлеп итәргә уйлый. Тик ике елдан СССР Фәннәр академиясенең Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институтынына кече хезмәткәр буларак эшкә урнаша. Моны үзе болай аңлата:

– Институтта укыганда шактый күп экспедицияләргә йөрергә туры килде, – ди Фаяз абый. – Мин бу эшне шулкадәр ярата идем, сөйләп аңлата торган гына түгел. Күрәсең, укытучылар да моны күргән, аңлаган. Әнә шулай авылга кайтып киткәннән соң да, яңадан Казанга чакыртып алдылар…

Бер мәлгә галимгә барысы да җиңел бирелгән дигән фикер туса да, бу һич алай түгел. Аның белән еш аралашкан кешеләр белә: ул бүген дә үзенә карата бик таләпчән, җаваплы кеше. Фән белән шөгыльләнүнең кызыклы-мавыктыргыч та, катлаулы да эш булуы хакында да сөйләде ул:

– Әйтергә дә оят: кандидатлык диссертациясен 13 ел эшләдем, – ди галим. – 1974 елда Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институтына килдем дә баш-аягым белән эшкә чумдым – Биләрне өйрәнергә керештем. Ә җитәкчелек һаман диссертация яклауны сорый. Әлбәттә, аны эшләү авыр түгел, Биләрдә никадәр яңа ачышларга юлыктык. Менә шуларны язып кына бир!

Шулай эшли дә Фаяз абый. 1987 елда фән кандидаты дәрәҗәсен ала. Ә ни өчен фәнни эшне язу шулай озакка сузыламы? Әлеге дә баягы җаваплылык: җиде кат үлчәмичә, булдыра алмый ул.

Тагын бер кызык очрак. Студентлар белән экспедицияләргә йөреп, фәнни һәм фәнни-популяр хезмәтләр язгач, аны галим дип атый башлыйлар. Ә Фаяз абый читенсенә.

– Галим – ул минем өчен бик җаваплы исем, – ди. – Син барысын да белергә тиеш. Менә шушы мәртәбәле сүз – галим исемен аклар өчен бик күп укырга туры килде. Ә бит шунсыз булмый. Укучылар янында буласыңмы, укытучылар белән аралашасыңмы – барысының да сорауларына җавап бирергә кирәк. Алай гына да түгел, галимнәр белән дә очрашасың. Аларның да сораулары бар. Менә шуңа да үземне үстерү өчен бик күп эшләргә туры килде.

Докторлык диссертациясен язганнан соң гына Фаяз абый үзен галим дип саный башлый, ягъни 50 яшьтән соң. Ә шулкадәр белеме белән ни өчен докторлык диссертациясен шул яшьтә генә язамы? Бу юлы иң төп сәбәп – вакытның җитмәве. Казанга 1000 ел барлыгын дәлилләгән еллар була ул – Кремльдә казу эшләре алып баралар. Һәр табылдыкны аерым өйрәнәләр, документлаштыралар…

– Доктор булу кирәк тә түгел миңа, дип йөрдем, – ди Фаяз абый. – Эш исемдә түгел бит. Шулай да 2001 елны каршы алганда үземә максат куйдым: 50 яшьлек юбилеема эшләгән хезмәтләрем буенча бер китап чыгарырга! Җиде ай дигәндә язып чыктым шуны. 2001 елда Мәскәүдән академик Валентин Седов килгән иде. Сөйләшеп киттек тә:

– Синең бу китабың докторлык диссертациясе булган бит, – диде ул. Менә шулай итеп, үзем дә уйламыйча, кайчаннан бирле өстә торган зур эшне башкарганмын булып чыкты.

Аш бүлмәсенә таралган ризык исеннән «айнып» киткән кебек булдык.

– Ай, бәрәңге! – дип сикереп торды Фаяз абый. – Юк, янмаган да көймәгән дә. Уф… Куркып куйдым.

– Янса, фотода ачык итеп күрсәтербез, – дигән булам.

– Юк, яна күрмәсен, әйбәт булсын. Эш ярты-порты гына булырга тиеш түгел.

Фаяз абый ризыкны тигезләп бүлеп, тәлинкәләргә салды. Авыз итәбез… Бик тәмле!

Запеканканың төрлесен ашаган бар. Тарихчы галим әзерләгәненә үзенә бер тәм хас кебек тоелды. Булганнан барысы да була, күрәсең!

P.S. Фаяз абыйга «сөйкемле сөяк» дигән сүзләр туры киләдер. Кабул итү имтиханнарында укытучыларның күңелен яуларга да, авылдан Казанга чакыртып алынуында да… Соңрак күпләрнең яраткан остазы, хөрмәтле коллегасына әверелергә дә әнә шул сөйкемле сөяге ярдәм иткәндер аның.

1. Тозлыйбыз!

2. Борычлыйбыз!

3. Болгатабыз!

4. Җәябез!

5. Турыйбыз!

6. Тезәбез!

7. Турыйбыз!

8. Тезәбез!

9. Борычлыйбыз!

10. Уабыз!

11. Мичкә куябыз!

12. Ягабыз!

PRESSA

ТАТАРСТАН ЕЛГАЛАРЫ

Татарстан елгаларга бай, аның территориясе буенча өч меңгә якын елга ага. Араларында зурлары да, кечкенәләре дә, киңнәре дә, тарлары да, тиз агымлылары да, салмак агымлылары да бар. Алар безгә онытылмаслык ял мизгелләре бүләк итәләр. «Татарстан» да, үз төбәгенең патриоты буларак, елга буйларында ял итүнең рәхәтлекләрен үзендә сынап карап, аннан бу турыда журналыбыз битләрендә язарга булды. Мондый ял татарстанлыларга да, республика кунакларына да ошар, дип уйлыйбыз.

ЧУЛМАН.

ЛАЕШТА УРТА ДИҢГЕЗ СТАНДАРТЛАРЫ БУЕНЧА ЯЛ

«АТАБАЙ ДИҢГЕЗЕ».

ҖИЛ ЯРАТУЧЫЛАР ҖЫЕЛГАН УРЫН

МИШӘ.

ТӘҖРИБӘСЕЗЛӘР ӨЧЕН БАЛЫК ТОТУ СЕРЛӘРЕ

АГЫЙДЕЛ.

ОНЫТЫЛМАС ТӘЭСИРЛӘР

НОКРАТ.

ЧУЛМАН БЕЛӘН ОЧРАШКАН МӘЛ

Чулман – Иделнең сул, иң зур кушылдыгы. Озынлыгы – 1805 км, шуның 360 км – Татарстанда. Куйбышев сусаклагычының Чулман култыгына кушыла.

ЧУЛМАН. ДИҢГЕЗ ЯРЫНДА ЯЛ

Ни дисәң дә, җәйне диңгезсез үткәрү ялны җилгә очыруга тиң! Бигрәк тә диңгез янәшәдә – кул сузымы ераклыгында булганда. Казаннан бары тик алтмыш километр гына китәсең, ә үзеңне Урта диңгез буендагы курорттагыдай хис итәсең. Әйе, әйе, дөрес ишетәсез – нәкъ менә Урта диңгез буендагы…

Автор:
Ольга Туманская

Җыйнак кына Лаеш бүген чыннан да көньяк шәһәрчеген хәтерләтә. Ә «диңгез» дип биредә тулы сулы Чулманны атыйлар, дөресрәге – аның иң киң өлешен. Елганың икенче яры ерак офыкта югала, аңа кадәр – 42 километр!

Заманча курортлардагыдай җиһазландырылган яңа яр буен ачканчы, әлеге җирле пляж «кыргый» саналган. Бүген исә «Чулман диңгезе» парк-пляжы халыкны үзенә тартып тора торган ноктага әверелгән һәм, әйтергә кирәк, җирле халык өчен генә дә түгел. Бирегә Татарстанның төрле почмакларыннан, хәтта күрше республикалардан да ял итәргә, рәхәтләнеп су коенырга киләләр. Пляж көн саен биш меңгә якын кешене кабул итә, дип сөйлиләр, шуңа күрә хәтта эш көннәрендәге иртәләрдә дә монда ялгызың булмыйсың икән.

«СЕЗГӘ ДИҢГЕЗ БУЕННАН ЯЗАМ…»

Ур-ра, машинабызны пляж янынарак куя алдык – безгә соңгы урын диярлек эләкте. Күрәсең, автомобильләрне урнаштыру мәсьәләсе әлегә ачык булып кала. Дөрес, шәһәр администрациясендә бу проблема тиз арада хәл ителәчәк, дип ышандырырга тырыштылар. Машина кую урыннарын, әйтүләренә караганда, соңыннан кеше юлын җәмәгать транспортына утырып дәвам итә алырлык итеп эшләячәкләр.

Һәм тагын бер күңелле яңалык – пляжга керү тулысынча бушлай, шул ук вакытта безгә вәгъдә ителгән комфорт дәрәҗәсендә. Карап карыйк! Шезлонгларда урын алабыз. Алар шулай ук бушлай – агачтан, иркен, сөялү өчен аркасы булганнары да, булмаганнары да бар. Берничә дистә урын, эссе кояш нурларыннан сакларлык итеп, рейкалардан эшләнгән махсус япма астына кертеп буйдан-буйга урнаштырылган. Әллә комда җылыныргамы? Монда ул йомшак һәм ачык төстә – елганың үзенеке дә, карьердан ташылганы да.

Сүз уңаеннан, әлеге парк-пляжның гомуми озынлыгы якынча тугыз йөз метр. Төзекләндерелгән яр буе мәйданы якынча тигез итеп бүленгән өч зонадан тора. Кызганыч, ул тулысынча җәй ахырына гына ачылачак, ә хәзергә аның бары тик бер өлеше – пляжда ял итү өчен ясалганы белән генә канәгатьләнергә кала.

Сүз уңаеннан, әлеге яр буеның проекты РФ Төзелеш министрлыгы уздыра торган «Кече шәһәрләр һәм тарихи җирлекләр» Бөтенроссия архитектура конкурсында җиңүчеләрнең берсе булган. Архитекторларның берсе, Лилия Гыйззәтова, әшләнгән әшләнгән...

Лилия Гыйззәтова, эшләгән

БАРЫГЫЗГА ДА – ФИЗКУЛЬТСӘЛАМ!

Иң беренче итеп, күзәтү манарасына йөгерәм. Зур-зур таш өемнәре арасында ул бик мәһабәт күренә. Әмма алда мине… тикшерү көтә икән! Өскә үрмәли торган урын текә, шуңа күрә «формада булмаганнарны» шунда ук кире боралар.

«Гражданочка, юл бирегез!» – кырыс тавыш уйларымны бүлә. Каршымда ике кеше – зәңгәр футболкаларына «МЧС России» дип тә язылган. Исәнмесез, коткаручылар! Алар, гадәтләнгәнчә, югарыга «очып» кына менәләр – мин артларыннан көчкә өлгерәм. Ләкин тырышлыгым бушка китми – өстән караганда гүзәл Чулман уч төбендәгедәй, матур булып җәйрәп ята! Шунда ук урнаштырылган махсус бинокль аша, каршы яктагы ярны күрергә омтылып, чал дулкыннарның шаяруын күзәтәм.

Инде хәзер, карап туйгач, коенырга да була. Сүз уңаеннан, узган елда ГТХМ коену өчен иң кулай, рөхсәт ителгән урыннарның исемлеген бастырды. Республика шәһәр пляжлары арасында андыйлар уникe икән, «Чулман диңгезе» дә – исемлектә. «Диңгезгә» керү урыны бик сөзәк. Шуңа күрә чиста елга суы диңгез температурасына кадәр җылына, бу бигрәк тә бала-чагага ошый. Әнә алар – ярдан ерак түгел генә. Чыр-чу килеп, су чәчрәтеп уйныйлар, яр буе төрле төстәге панамкалар һәм һава тутырыла торган әйләнәләр белән тулган.

Шунысын да әйтик: балаларны судан чыгару әллә ни авырлык тудырмый, чөнки коры җирдә дә алар өчен кызыктыргыч урыннар бик күп. Телисең икән, баланы алып, минем кебек манарага күтәрел, аннан, елга манзарасын карап туйганнан соң, балалар мәйданчыгына кил. Шәһәрдәге кебек туйдырып бетергән таганнар һәм шуа торган ясалма таулар юк монда. Алар урынына сиңа – ком чыгара торган карьер!Минем үземә дә кызык – карыйм, күзәтәм, барысының да ничек эшләнгәнен аңларга тырышам. Янымда бер яшь кенә пар кызларын алып килгән. «Әйдә, әйдә, ныграк эт!», – дип команда бирә кызчык әтисенә. «Ул арыды, ул бит әле генә зарядка ясады!» – ди көлә-көлә әниләре.

Зарядка? Әйе! Бездән илле метрлап читтәрәк воркаут – урам спорт залы ясалган. Велотренажёр һәм көч станнары, баскычлар һәм турниклар – әлеге күренеш парк һәм скверларыбыз өчен гадәти, әмма пляжлар өчен түгел. Шулай да, миңа калса, педаль әйләндерү өчен эссерәк. Хәер, бөтен кеше дә минем белән килешми. «Бер! Ике! Өч!» – дип саный турникта күтәрелүче ир-ат. «Бер, ике, өч…» – тулы гына гәүдәле бер малай йөгерү юлында мыш-мыш килә.

ЯҢГЫР АСТЫНДА КОЕНУ

Эх, булмады инде – әллә каян болытлар килеп чыкты! Яңгыр башланганчы, күп нәрсәгә өлгерәсе иде. Ким дигәндә, агач променад буенча йөреп карарга. Ул, әлбәттә, озын түгел – өч йөз метрлар чамасы, аның каравы, юлыбызда берничә кызыклы арт-объект бар.

Шулай итеп, ашыкмыйча гына, биш минутлап, пляжның сул кырыена якынлашабыз. Анда матур гына кафе урнашкан.

– Оһо! Алтын йомырка салучы тавыкмы әллә бу?! – дип шаярта, бәя язылган кәгазьгә карап, бер ха-

Фото: Ольга Туманская.

ным. Мин дә, аны-моны дәшмичә, аның белән килешергә мәҗбүр: кафедагы бәяләр «тешләшә». Әмма минем тамагым тук: пляжда ук туңдырма сатып алып ашаган идем.

Кафедан ерак түгел бәдрәф тә урнашкан. Бик четерекле, ләкин актуаль тема. Тикшереп карар өчен керәм. Ике кабинка, кулъюгыч та бар. Ә иң мөһиме – чисталык. Һәм түләүсез.

Биш минут үтте – һәм мин пляжның икенче башында. Янәшәдәге яшел зона ябык. Каршымда – аңлатма бирелгән элмә такта: эшчеләр таш түшиләр икән. Җиңелчә генә төзелгән койма җәйге амфитеатрны каплый алмый. Бик тиздән биредә курорт тормышы гөрләячәк дип сөйлиләр, үзенең барлык аһәңнәре-авазлары, көндезге тынычлыгы һәм кичке шау-шулы концертлары белән, күбрәк көньякны хәтерләткән чәчәкләрнең баш әйләндергеч һуш исләре һәм тын елга шаулавы белән... Тагын да арырак чуерташлы зона булачак, пляж ялы өчен генә түгел, пикниклар өчен дә шартлар тудырылган. Әмма барбекюдан башка гына – пляжда учак ягу тыелган, саф һавада, су, ком, чуерташ һәм яшеллекле табигать кочагында ял итәргә яраткан кешеләр өчен өстәлләр куелачак.

Яңгыр кабат уйларымны бүлә. Чишенү-киенү бүлмәсенә йөгерәм! Ләкин иң башта – душ астына!

– Ай, бигрәк салкын! Скважинаданмы әллә? – дип зарланып алды бер агай да.

Яңгыр көчлерәк ява башлады, авыр су бөртекләре халыкны пляждан куа. Мин шул арада ярны берничә мәртәбә фотога төшереп өлгерәм: болытлы манзараны. Лаештан кайтып китәсе килми. Һәм кирәкми дә! Монда һава торышына бәйле уңайсызлыклардан файдалы итеп котылыр, яңгыр үткәнен көтеп торыр урыннар шактый. Мәсәлән, Державин исемендәге Лаеш төбәге музееен яисә 1853 елгы София (Троица) соборын карап чыгарга мөмкин. Яңадан ялтырап кояш чыгуга, Чулман ярына берегеп «үскән» известьташлы кыялар – Ак тауларга экскурсиягә китәргә мөмкин. Яисә кино дөньясына сәяхәт итәргә: биредә «Зөләйха күзләрен ача» сериалын төшерү өчен махсус төзелгән гаять зур декорация – Себердә Ангара елгасы ярына салынган «Семрук» бистәсен хәтерләткән авылга әләгә аласыз. Әйе, Лаештагы Чулман елгасы буендагы ялны ялкауларча пляжда ятып кына түгел, күңелле һәм файдалы итеп үткәрергә дә була.

PRESSA

ТАТАРСТАН
елгалары буйлап

Идел – Европаның иң зур елгасы. Гомуми озынлыгы – 3530 км, шуның 186 км – Татарстанда. Казан янындагы киңлеге – 3–6 км, Кама Тамагы тирәсендә – 35 км га кадәр.

ИДЕЛ – ЧУЛМАН – МИШӘ. РӘХМӘТ, «АТАБАЙ ДИҢГЕЗЕ»!

Татарстан дәрья-суларга бай. Безнең сулар, тозлы булмасалар да, нәкъ диңгезләр һәм океаннар кебек үк, киң һәм чиксез. Бу охшашлык берничә елга кушылган урыннарда аеруча ачык күренә. Шундый гаҗәеп җирләрнең берсе Атабайда урнашкан – биредә Идел, Чулман һәм Мишә бергә очраша. Җирле диңгез яр буен су коенучы һәм кызынучылар гына түгел, дулкыннарны иярләргә яратучы кайтсёрфингистлар да үз итә.

Автор:
Алсу Троицкая

«Татарстан» командасы Атабайга шул ук исемдәге Татарстан урамы буйлап кереп, Совет урамына таба борыла. Без машина тәрәзәсе аша мул тормыш күренешләрен күреп, бу урамда инде асфальт булмавына да игътибар итмибез: тузанлы юлның ике ягында нәкъ Урта диңгез буендагы кебек коттеджлар тезелеп киткән, ә алда – чиксез диңгез, «Атабай диңгезе» җәелеп ята. Су өстендә әллә нинди сәер, ерактан карaганда өтер билгесенә охшаган күпсанлы кошлар бөтерелә.

ӨТЕРЛӘР

Кырый йорт каршындагы эскәмиядә утыручы әби аңлатып бирде: су өстендәге бу өтерләр бөтенләй дә кош түгел, ә кайтлар – паруслар икән.

– Аларга тотынасың да су өстеннән йөгертеп китәсең. Анда хәзер минем оныгым да бар әле. Җил искәндә йөреп кала, – дип елмая әби.

Бормалы бистә юлы безне нәкъ яр буена китерде. Якынтирә машина һәм палаткалар белән тулган. Ә «диңгез» өстендә паруслардан эскадрилья йөзә. Җилкәннәр борыннары белән берьюлы диярлек әле уңга, әле сулга борыла, кисәк кенә офыкка таба китеп, күзгә күренер-күренмәс өтергә әйләнеп кала...

– Бүген җил шәп исә! – дип тел шартлатты яр буенда шашлык пешергән арада парусларны күзәткән ял итүчеләр.

ҖИЛГӘ БӘЙЛЕ КЕШЕЛӘР

Әлеге шәп искән җилләр бөтен яр буена кыздырылган ит исен тарата, авыздан сулар китерә.

– Бу курорт почмагы шашлык һәм тән кыздыру өчен генә түгел, – дип сөйли башына сомбреро эшләпәсен киеп алып, бауларын һәйбәтләп бәйләп куйган Иван. – Бу – җилгә бәйле кешеләр урыны. Җил яхшы искәндә монда җәй дә, кыш та йөрергә була. Кайтсёрфинг – су өстеннән йөрү, сноукайтинг – кардан шуу, – дип, терминнарны аңлатты ул бу теманы бөтенләй белмәгәннәргә.

...Шулвакыт елгадан аяклары суга тияр-тимәстәй итеп, тавис кошыдай атлап, култык астына тактасын кыстырган яшь кыз чыкты. Искиткеч матур сыланып торган киемле бу сылуның йөзеннән бәхет сирпелеп тора иде. Тойгылары белән ул бик теләп бүлеште.

ТАТАР ДУЛКЫНЫ

– Күп җирләрдә йөргәнем бар, – дип сөйли ул, битеннән юеш чәчләрен сөртеп. – Анапада да, Балтыйк диңгезендә дә, Маврикиядә дә. Ләкин безнең татар дулкынынинан да яхшырагы юк. Үзегез йөреп карагыз! Монда кайт мәктәбе бар. Беренче сынау дәресендә үк берничә сикерү хәрәкәтен өйрәнеп була. Юнәлешне үзгәртеп, берникадәр ара уза алсагыз, үзегезне бәхетле хис итәчәксез! Уңышлы җилләр сезгә! – дип елмайды ул.

Аның сүзләрен, девиз кебек, каты җиргә аяк баскан башка бәхетле җил кешеләре эләктереп алды. Алар, бик теләп, үз тәҗрибәләре белән уртаклашырга керешә, Ташкирмән, Сингел кебек җилләр шәп исә торган башка урыннар турында кинәнеп сөйләде.

ҖИЛ ӘФСЕНЕ

Без яңа сүзләр өйрәнеп, «Татар дулкыны–2019» фестивале ничек узганы турында сөйләгәннәрен тыңлап, яр буенча йөреп килдек. Кызынып ятучылар һәм суда коенучылар янына комлыкка төштек, яр буен челтәрләп бетергән карлыгач ояларын карадык, аннары җилгә бәйле кешеләр янына кабат әйләнеп килдек. Беренче сынау дәресенә язылдык. Инструктор белән берничә галс ясадык, сикерү хәрәкәтләре өйрәндек тә, «уңышлы җилләр сезгә!» дигән сүзләр әйтеп, манма чыланып һәм үзебезне чынлап та чиксез бәхетле тоеп, кире комга шуышып чыктык.

Хәзер «Татарстан»ның төрле яштәге, төрле җенестәге, төрле һөнәр ияләреннән торган дус компаниясенең чираттагы яллар планында – җилләр теләү. Алда – кайтингның төрле юнәлешләрен өйрәнү: фристайл, ярышу, рельефларда йөрү, кайтта сәяхәт итү...

Рәхмәт сиңа, «Атабай диңгезе!» Шәп җилләр һәм онытылмаслык җәйге, дымлы һәм кадерле бәхет хисләре өчен рәхмәт сезгә, Идел, Чулман һәм Мишә!

ТАТАРСТАН *елгалары буйлап*

Мишә – Чулман елгасының уң кушылдыгы, Куйбышев сусаклагычының Чулман култыгына кушыла. Озынлыгы – 204 км. Чыгышы – Кукмара районы Шепшенәр авылыннан төньякка ике чакрым ераклыкта. Киңлеге – 30 метрдан 3–4 км га кадәр. Кукмара, Саба, Теләче, Питрәч, Лаеш районнары территориясе буйлап ага.

МИШӘ – БАЛЫКЛЫ ЯК

«Мишә – әле балык тоту тәмен яңа татый башлаган спиннингчылар, калкавычлы балыкчылар һәм төптән тотучылар өчен чын җәннәт ул», – дип укыйм TatFish форумында. Димәк, Мишә тирәләренә сәяхәт – елга буе матурлыкларын манзара кылып, бер үк вакытта безнең, дөресен генә әйткәндә, әле кармак салырга өйрәнеп кенә килгән компаниябезгә уңыш никадәр еш елмайганын сынап карау өчен менә дигән мөмкинлек тә икән.

Данил Шибанов:
– Карадуледән алып Атабайга кадәр участок – палаткалы һәм гаиләле ял өчен иң яхшысы. Анда күбесенчә көймә белән керεп балык тоталар. Монда – Мишә, Чулман һәм Идел елгалары кушылган җирләрнең матур манзаралары һәм елганың сай сулы, ком төпле урыннары.

Автор:
Ксения Сёмина

– Мишәнең иң популяр урыны Питрәч бусагасыннан алып Карадуле авылына (Татарстанның Лаеш районы – ред. иск.) кадәр, – дип аңлата спортчы-балыкчы Данил Шибанов. – Шәһәрдән машина белән 20 минутлык юл. Сазан, карп, корбан, чабак, густера, алабуга, чуртан, сыла, сула, опты, кушбаш – һәммәсе дә эләгә биредә…

ГИБРИД ДИП ЮЛӘРЛӘНҮ

Һәм менә ике универсаль кармак, спиннинг белән коралланып, берәр кап суалчан һәм чебен корты эләктереп, өмет тулы күзләр белән Мишә тарафына юл тотабыз. «Уңай һава торышы һәм көн вакытын файдалана белү дә бик мөһим», – дип укыйм, юлда барганда, соңарып булса да, Сергей Аксаковның «Записки об уженьи рыбы» әсәреннән файдалы юлларны. Сүз уңаеннан, ул Мишә турында: «Россиянең иң балыклы елгасы түгел микән әле», – дип язып калдырган. Төш вакыты җитеп килә, машина тәрәзәсенә әле яңгыр тамчылары чиертә, әле балкып чыккан кояш кыздырып ала, өстәвенә, җиле дә көчәючән.

– Әллә бәлки нәкъ елга тамагына барыргадыр? – дип, көтмәгәндә әйтеп сала дустым Ксения. Һәм без, бер капчык балык тотып кайтуыбызны теләп калганнарның киңәш-нәсихәтләрен бөтенләй бозып, Рождествено авылына юнәләбез.

Рождественога кадәр шактый әйбәт кенә асфальттан егерме минут эчендә килеп җиттек. Яңгырдан соң гөмбәдәй үсеп чыккан кебек тоелган коттеджлар арасында бераз адашып йөргәч, ниһаять, өмет ягтысын шәйлибез. Мул сулы киң елга күрү хыялын, ниһаять, чынга ашырырга мөмкинлек биргән Мишә манзарасын тамаша кылыр чак җитә!

Тик суга якын килеп булмый: зур булмаган текә яр буйлап шактый киң камышлык сузылып киткән. Бездән уң яктарак булган пирста бер төркем кармаклы халык мәш килә. Аларга комачауламыйсы килми, күрше Дятлово авылына китәбез. Безнең чиксез бәхеткә күрә, монда суга якын килеп була икән. Җим кидерү эше белән изаланып алгач, без, ниһаять, кармакларны суга салабыз да, калкавычның тартылып, биеп куйганын зарыгып күзәтергә керешәбез.

Егерме метр читтәрәк утырган, бу эштә инде бер пот тоз ашаган балыкчылар безнең тарафка бераз кызгану хисе белән күз салгалый. Рәхәтләнеп көләрләр яки безнең ыгы-зыгыга ачулары килеп, сүгеп ташларлар иде, балыкчылык әдәбе һәм потенциаль табышны өркетүдән куркулары тыеп тора, күрәсең.

– Ә сез нәрсә дә булса тоттыгызмы инде? – дип, безгә якынрак утырганыннан сорарга батырчылык итәм.

– Әйе, әнә шунда, читлек кәрзиндә, – дип, кулы белән ымлый әңгәмәдәшем Сергей.

Читлектә, чыннан да, балык бар. Тик нинди?

– Гибрид ул, – дип аңлата Сергей әйтергә өлгермәгән соравыма җавап итеп. – Монда әйләнә буенча йөри. Ә әнә иптәшемдә – корбан малайлары. Кармаклар бер үк, әмма ике арада – биш метр. Тирәнлеге башка – балыгы да бүтән.

Июль аенда Мишәдә беренче тапкыр балык тотуы икән. Су биеклеге нормальләшкәннән соң, биредә эшләрнең ничек торуы белән кызыксынган ул.

– Балык Чулманнан Мишәгә фасылына карап килә. Хан балык, бәртәс, чуртан, сыла, шыртлака яз һәм көз айларында йөзеп керә, монда туклана. Якынча май айларында уылдык чәчәләр, бу вакытта балык тоту тыела. Уылдык өлгерсен өчен, ул камышларга берегеп калырга тиеш. Быел биредә су булмады, шуңа күрә балык уылдыкны тирәнлектә чәчте. Ә анда күпме маймыч исән каласын Алла белә. Миңа калса, якындагы биш елда болар барысы да балык санында үзен сиздерәчәк әле, – дип аңлатты Сергей. – Елгаларга, әлбәттә, маймыч җибәрәләр, әйтик, әнә шул ук гибридларны. Әмма ул – күл балыгы, селекция белән чыгарылган, табигый балык белән чагыштырырлык та түгел.

Мишәдә балык тоту өчен иң шәбе – июнь ае. Июль аенда – тынлык. Су җылына, анда кислород кими, балык тынып кала. Ә августта бу тирәләргә ерткычлар – сазан, җәен килә. Тик алар өчен кармаклары да башка кирәк.

БАЛЫК! БАЛЫК!

Монда шул гибридны да, хәер, башка балыкны да тоту өчен тәҗрибәбез җитмәвен, кармакларыбыз да туры килмәгәнлеген аңлап, Мишәнең башка урынында, Сокуры янында бәхетебезне сынап карарга булдык. Мишә биредә аучыдан качкан куян кебек, әле бер, әле икенче тарафка борылып ага. Бу тирәдә елга киң түгел, тигез һәм уңайлы, барысы да безне генә көткән, диярсең. Хәтта комлы түбәнлектә бер кочак кармакларын җәеп салган күршеләр дә яхшы каршы алып, безгә ягымлы гына баш селки.

Ксения ялтыравык алдавычлы спиннингка тотына һәм, Ютубта бу нәрсәнең ничек эшләгәне турында дистәләгән видео караган тәҗрибәле кеше кыяфәте белән, аны суга ыргыта башлый.

Фотолар автордан алынды

Мишә Дятлово авылы янында.


Мишә Хәерби авылы янында.

Мишә Дятлово авылы янында.

Мишә Сокуры авылы янында.

Мишә Рождествено авылы янында.

Данил Шибанов:
– Питрәч бусагасына кадәрге югары агымда Мишә тирән түгел, монда зур булмаган сайлыклар һәм шактый тирән чоңгыллар бихисап. Питрәч бусагасыннан югарыга таба участок – кушбаш оясы. Мишә елгасының югары агымында Кызыл китапка кертелгән бурыш балыгы да очрый.

– Чиртми! Чиртми, дим мин сиңа! – каршы ярда бер балыкчы тынгысыз иптәшен бер кармактан икенчесенә йөгереп йөрүдән туктатырга тырыша, янәсе, тирә-якның матурлыгын карый-карый, чәен-мәен йоткалап утырыр вакыт.

Кармакны булдыра алганча ераккарак салам. Дулкыннарның калкавычны бәллүләп селкетүен күзәткәндә, уйлар диңгезенә чумам: бу балык тотуның матурлыгы ауда да, елга төпкелендә яшәүче үзсүзле җанварларны хәйлә һәм стратегия ярдәмендә җиңүдә дә түгелдер, мөгаен. Аның бөтен асылы шунда: уйлар өермәсеннән котылып, бар игътибарны су өслегенә юнәлтәсең, аның сизелер-сизелмәс хәрәкәтен күреп алырлык сәләткә ирешкәнсең икән, сине табигать үзенә шулкадәр якын китерә ки, шушы җанлы, шаулапгөрләп, сызгырып, кыштырдап, селкенеп торган дөньяны бөтен гүзәллеге һәм төрлелеге белән күрә, тоемлый башлыйсың. Моның минем һәм, гомумән, кешелек өчен нәрсә дигән сүз икәнен уйлап бетерергә өлгермәдем...

– Балык! Балык! – дип сөрән салды юлдаш кызларым. Спиннингка шундый җитез, тешле һәм усал чуртан малае эләккән. Куркып, күршеләргә күтәреп барабыз. Алар нәни ерткычны кармактан ычкындыра һәм җибәрергә киңәш итә. 32 сантиметрдан кыскарак чуртанны тотарга рөхсәт ителми, безнеке шуннан һич тә күбрәк түгел...

Аксаков киңәшләрен тотып («Төрле зурлыктагы һәм төрле тирәнлектәге кармакларга һәм үзегездә булган барлык алдавычларга тотып карамыйча, бу урыннан беркайчан да китмәскә»), без спиннингны чират белән салып карыйбыз, тик бәхетсезлеккәме, әллә инде бәхеткәме, бүген сезгә шул җитә, дип карар кыла Мишә.

– Бәлки, балык тоту минем өчен түгелдер, – дип куя Ксения, трассага чыкканда. Мин тагын смартфонымда Аксаковның балык тоту турындагы кулланмасын ачам. «Балык һич аңлап булмас дәрәҗәдә үзсүзле һәм сайланучан була, һәрхәлдә, безгә белемсезлегебез аркасында шулайрак тоела. Минем белән шундый хәлләр ничә тапкыр булгандыр: башкалардан начаррак көйләнгән, тиешле урында ятмаган кармактагы шул бер саплап салган суалчан яки кысла кисәгенә бертуктаусыз яхшы балык эләгеп тора иде...».

Яхшы тезис бу, өйрәнчекләр өчен. Һәм аны, Мишәдә булмый, тагын кайда тикшерәсең инде?

ТАТАРСТАН
елгалары буйлап

Агыйдел – Чулманның иң зур кушылдыгы. Озынлыгы – 1430 км, шуның 50 км – Татарстанда. Татар Ямалысы авылыннан түбәндәрәк Чулманга кушыла.

АГЫЙДЕЛГӘ – ҖӘЯҮЛӘП!

Казаннан Агыйделгә кадәр җәяүләпме? Күңелле булачагы бик шикле бу сәфәрнең. 400 чакрымга якын араны тәпиләп узу шул Федор Конюхов өчен генә кызыктыр ул. Аның каравы, Актаныштан Агыйделгә кадәр, үләннәрдәге чыкны чәчрәтә-чәчрәтә, рәхәтләнеп яланаяк та барып була…

Автор:
Әскәр Сабиров

Ни өчен нәкъ менә Агыйделгә? Хәтерлисезме бер әкиятне: «Бар шунда, белмим – кая, тап шуны, белмим – нәрсәне...»? Әнә шундыйрак мәсьәләне чын-чынлап тагын кайда чишә алам әле мин, йә?! Минем бурыч бит түбәндәгедән гыйбарәт: а) Татарстанда җәяүле һәм велосипед туризмы өчен идеаль урыннар табарга; б) елга һәм күлләр яныннан, кеше кулы тимәгән табигатьле һәм идеаль экологияле урыннардан узарлык маршрутлар төзергә; в) экологиянең идеаль икәнен раслап, бер дистә кысла тотарга.

Агыйдел – минем өчен иситкеч вариант. Картада күрсәтелгән калкулыклар, урманнар һәм болыннар арасыннан ул кинәнеп бормаланып агып ята. Завод-фабрика пычракларыннан ерак Актаныш районы – елга-күлләр һәм сазлыклар төбәгендә дә идеаль экология булмаса, тагын кайда була ала инде ул?!

Бу тирәләр Финляндиядәге «Нууксио» милли паркын хәтерләтә. Фин паркындагы җәяүле маршрутларда туристлар Лапландиядәге төньяк боланнардан да күбрәктер, чын мәгәр. Димәк, чагыштырыр манзаралар бар, дигән сүз.

«ТАБИГАТЕ ШУНДЫЙ КИ, БАЛЫК ИНДЕ КИРӘК ТӘ ТҮГЕЛ...»

Хәзерге Актаныш урнашкан тау итәгеннән үк зәңгәр су тасмасы сузылып китә, ул сәяхәт күңелле һәм җиңел булачак, дип, вәгъдә бирә кебек.

– Бу Агыйдел түгел әле, Иске Идел, елганың элеккеге юлы, – дип сәяхәтчеләрнең дәртен сүндерә төшә беренче очраган кеше һәм, офыкка таба ишарәләп, юл күрсәтә: – Ә Агыйдел ә-ә-ә-нә тегендә.

Картадан тикшереп карыйбыз. Агыйделгә кадәр, чыннан да, алты чакрым чамасы барасы. Иске елга юлы буйлап, инешләр, күл һәм сазлыклар яныннан – безгә нәкъ шул кирәк тә. Беренче маршрут өчен арасы да – иң кулае. Картина тулырак булсын өчен, теоретик әзерлек тә комачауламас: биредәге табигать, анда яшәгән җан ияләре, тыюлыклы урыннар һәм климат үзенчәлекләре турында барысын да белергә кирәк.

Финляндиядәге «Нууксио»да моның өчен махсус табигать үзәге – «Халтиа» оештырылган. Монда, мәсәлән, чын аю өненә кереп, саламәтлек өчен куркыныч тудырмыйча, бернинә онытылмаслык минут кичерергә мөмкин. Сенсор экраннары ярдәмендә виртуаль сәяхәт кылырга, маршрут сайларга, аның үзенчәлекләрен өйрәнергә һәм хәтта юламан-гид ялларга да була. Сүз уңаеннан, «Нууксио»да җәяүлеләр өчен маршрутлар дистәләгән. Иң кыскасы – ике километрлык, «өйрәнчек» туристлар өчен. Иң озыны – 110 километр, ул бөтен милли парк буйлап, урман, күл, сазлык һәм кыялар аша уза...

Актаныштa «Халтиа» тибындагы табигать үзәге дә, җәяүле туризм өчен әзер маршрутлар да юк әле. Аның каравы, импровизация өчен нинди иркенлек! Өстәвенә, социаль челтәрләрдә Агыйдел һәм аның тирә-ягы турында гел мактап, сокланып язалар. Балыкчылар форумнарының берсендәге Андрейнең фикерен нигез итеп алыйк, мәсәлән: «Әгәр Казаннан бу якларга килеп чыксаң, кичүгә хәтле хәрәкәт ит... Мондагы табигать шундый хозур ки, балык инде кирәк тә түгел...».

Менә ачыкладык та. Беренче җәяүле маршрут – кичүгә таба. Старт Иске Идел яныннан башлана.

ШОМЫРТЛЫ-БАЛАНЛЫ ҖӘННӘТ

Елганың иске юлы менә якында гына, бакча артыннан ук уза. Бердәнбер теләк – шунда ук теге як ярга чыгасы килә. Көймә прокаты дигән урын күренми, әмма бу якларда яшәүче Алмас ярдәм итәргә алына. Әзерлек өчен бер-ике минут киткәндер, һәм менә елга тынлыгын иске ишкәк кендекләренең елак ыңгарашуы гына боза. Тагын ун минуттан көймә төбе, каршы яр буенда суны болгатып, камышларда яшеренеп яткан ондатраны өркетеп җибәрә. Килеп җиттек!

Көймәдән төшүгә, бил тиңентен үлән ерып барасы. Алда – балан куаклары, чын балан урманы. Хыялыбызда шундый картина күз алдына килә: көз ахыры, һәм без өлгереп куе кызыл төскә кергән җиләк белән рюкзакларны тутырабыз. Монда баланны кәрзинләп, чиләкләп җыярга була...

Балан гына булса әле! Баланнан соң шомыртлык дивары башлана, аның җимешләре менә-менә карала башларга тиеш. Шомырттан соң – гөлҗимеш «басуы». Бу урын әрәмә дип атала, актанышлылар биредә борын-борыннан дару үләннәре, кайнатма өчен баланын, шомыртын җыя, дип, аңлатып китә озатып йөрүчебез.

Шомыртлы-баланлы җәннәткә сокланып кинәнгәч, алга таба, Агыйдел тарафына тәпиләргә булдык, әмма юлыбызда – сазлык. Без үз фикер-хыялларыбызның корбаны булганбыз икән, кичү янына, без теләгәнчә, турыдан бара алмыйсың – һәр якта саз, баткак. Иске елга юлын флангтан урап узу өчен, сәяхәтне башлаган урынга кире кайтабыз...

«Нууксио»ның көйләнгән-җайланган маршрутларында хәтта яңа кеше дә адашырлык түгел. Җәяүлеләр өчен һәр сукмакта – аңлаешлы юл күрсәтү системасы. Ә «Халтиа» үзәгендә урынның җентекле картасын алырга мөмкин. «Нууксио» буйлап җәяү, велосипедта яки атка атланып йөрергә була. Кайбер маршрутлардан инвалид коляскасында яки бала арбасы белән килүчеләр дә йөреп кайта ала. Күл буенда прокатка каноэ алырга мөмкин.

АККОШ, ЧЕЛӘН ҺӘМ ПАРОМ

Табигать безне кысыбрак кочаклый, кунакта мөмкин кадәр озаккарак калуыбызны телидер, күрәсең. Әҗәкүл авылы ягына таба бер-ике чакрым узуга, кабат кötелмәгән тоткарлык. Бу юлы – күңелле сәбәп. Агыйделнең башка бер иске юлы буйлап сузылган болын – иситкеч зур җиләк кыры ул. Җиләк исенә исереп, ярты сәгать эчендә бер чиләк җыеп алабыз – бу әле ашаганны санамаганда.

Болай дәвам итсәк, максатыбызга барып җитә алмаска да мөмкин икәнне аңлап, теләкләрне йөгәнлибез. Җиләге иситкеч тәмле булса да, мондый хозур урыннарга башка игътибар бирмәячәкбез, дип килешәбез. Бәхеткә, бу алай ук кыен эш түгел. Юлыбызда очраган галәмәт зур бөрлегәнлек (мондый нәрсәне беркайчан да күргән юк иде!) безнең ише юлчылар өчен берәр айдан гына кызыктырырлык булачак әле, өлгереп җитәсе бар...

Борма-борма сукмактан ераграк барган саен, табигать тагын да матурлана. Тирә-якта – зур булмаган күлләр, аларда кешедән куркырга күнекмәгән балык уйнаганы әледән-әле ялтырап күзгә чалына. Бер күл өстеннән безнең күз алдында гына челән очып китә. Икенчесендә, утрау артыннан, үз вәкарен белеп, ашыкмыйча гына, бер аккош йөзеп килеп чыга...

Биредә, Агыйдел бассейнында, сирәк очрый торган кошларны, хәтта Кызыл китапка кертелгәннәрен дә күрергә мөмкин. Елга каракошын, аккошлар, соры торналар һәм челәннәрне... Бу хакта без походка әзерләнгәндә үк белдек. Тик уку бер нәрсә, ә менә үз күзләрең белән күрү – бөтенләй башка.

Фото: Әскәр Сабиров

ТАТАРСТАН
елгалары буйлап

Шуннан соң ашкынып атлыйсы да атлыйсы килә башлый. Әмма яхшы нәрсә күп булмый ул. Куе таллык аша безгә таба капитан рубкасы якынаюын күреп алабыз. Алда, куаклар артында, – Агыйдел. Елга аша кичү урыны.

Җәяүле туризм өчен идеаль маршрутны таптык, ахрысы. Ялга туктап, төн кунар өчен урын табасы һәм кысла тотасы гына кала. Анысы гына инде!..

«Нууксио» паркында биотуалетлар куелган каплаулы җәйге кухнялар һәм учак ягу өчен махсус урыннар бар. Палаткалар өчен бушлай 12 территория дә бүленгән. Һәрберсенә учак урыны, биотуалет көйләнгән, утынлыгы, балтасы бар. «Нууксио»да чүп җыю һәм аны аеру урыннарын да кайгыртканнар.

АЗ-МАЗ УҢАЙЛЫКЛАРЫ БУЛГАН КЕЧКЕНӘ ВАГОН

Агыйделнең тыныч култыклары, таллык, комлы яры – алдан көйләнгән палаткалы шәһәрчек өчен идеаль урын. Әмма андый нәрсә монда да, якын-тирәдә дә юк, ә палатка белән елга ярында төн куну – безнең өчен романтиканың аргы ягы. Төньяктан кабарып килгән куе яңгыр болыты тиз генә мөһим карар кылырга мәҗбүр итә: кире Актанышка кайтабыз, аннан исә транспорт белән Татар Ямалысына юл тотабыз.

Ни өчен нәкъ менә Татар Ямалысына? Беренчедән, анысы да Агыйдел буенда урнашкан, икенчедән, бу авыл балыкчыларның Мәккәсе санала. «Балык тоту өчен гаҗәеп шәп урыннар: бернинди Иделе дә, Актүбәсе дә кирәкми», – дип язып калдырган Магнитогорскидан Марат исемле берәү балыкчылар форумында, үзе тоткан сыла белән фотосын да урнаштырып.

Шулай икән, димәк, килеп-китеп йөрүчеләр өчен монда махсус көйләнгән куну урыннары һәм тәмле кыслалар, һичшиксез, булырга тиеш, ни дисәң дә, балыкчы кунаклар хәтта Урал якларыннан ук килә бит…

Ямалы тирәсендәге Агыйдел буенда номерларына караганда Башкортостаннан килгән машиналны очратабыз.

– Балыккамы?

– Монда барысы да балык тотарга килә, – дип җавап бирә ир-ат, резин көймәсен суга төшергән җайга. – Тикмәгә генә ике йөз илле чакрым юл үтәр идеммени мин?!

– Ә якын-тирәдә турбаза бармы?

– Турбаза турында белмим, әмма бер-ике меңгә төн кунарга кертәләр. Әнә теге кечкенә вагоннар тирәсендә… – диде ул, шөкәтсез балыкчы йортлары ягына ымлап.

Ярый, анысы да ярап тора. Юлда барганда, яр буенда дебаркадер күренеп кала. Туктап, менеп карыйбыз: ишектә йозак. Тәрәзәдән күренгәне кунакханәдән ким түгел: плитә, өстәл, караватлар. Берәүләр шәп кенә яшәп ята… Әмма, күрәсең, бу номерлар кем өчендер махсус әзерләнгән…

Балыкчы йортлары янында безгә бәхет елмаер кебек…

– Дөресен генә әйткәндә, мин фатирга кертмим, – ди хуҗа кеше, безне баштанаяк игътибар белән тикшергәч. – Ә сез кайан? Казаннан? Безгә балыкчылар күбрәк Башкортостаннан килә…

Үзебез өчен түгел, танышлар, чын балыкчылар өчен сораштырабыз, дибез.

– Бик кирәк икән, әнә, вагон тәкъдим итә алам, – дип йомшара төшә әңгәмәдәшебез. – Караватлар, урын-җир, плитә – барысы да бар. Бер төнгә – ике мең.

Безне кызыксындырган вагоннан йөз метр чамасы читтәрәк – көймәләр өчен пирс. Пирста – Россия, Татарстан һәм Башкортостан әләмнәре җилферди. Берәү дә беркемне дә фатирга кертми, ахрысы, монда да. Җайлап сөйләшмәсәң…

– Ә сездә кысла тоталармы?

– Алла сакласын, – хуҗаның йөзе караңгыланып китә, әңгәмәнең шуның белән тәмамлануын белдереп ул сүзен кисә.

Соңрак шуны беләчәкбез: күптән түгел бу якларда сәнәгать масштабында кысла аулау белән шөгыльләнгән браконьерларны эләктергәннәр. Кыслаларны алар башкалага озатып торган, ә җирле полиция түрәсе яшерен бизнесны «каплап торган».

Шуннан соң биредәге балыкчылар даирәсендә «кысла» сүгенү сүзенә әйләнеп киткән диярлек. Хәер, кысланы законлы ысуллар белән тотудан берәү дә тыймады…

КЫСЛАЛАР НИДӘН КЫЗАРА?..

Кысланы барыбер тоттык без. Актанышка кайткач, җирле кунакханәгә урнаштык (бөркү номерлар кеше башына сигез йөз сум исәбеннән), кич белән, Иске Иделгә төшеп, уңайлы култык таптык та, сарымсак ышкыган ипи катысы һәм бераз исләнә башлаган балык кисәкләрен җим итеп, кысла тоткыч җайланмаларны суга төшердек. Иртән тозакларыбызда безне, келәшчәләрен болгый-болгый, дистәләп кысла көтә иде – бу якларда экология белән бар да тулы тәртиптә икән!

Кунакханә ресторанында (ресторан диярлеге чынлыкта исемдә генә) менюга бакканда, без күп илләрдән туристларны җәлеп итә торган финча үзенчәлекләрне янә искә төшердек. Мәсәлән, күл буйларындагы иске крестьян ызбаларында урнашкан кечкенә рестораннар. Әлеге мини-рестораннарда болан ите, яңа тотылган балык, яңа җыелган гөмбә һәм җиләк кебек җирле, табигый продуктлардан гына әзерләнгән ризыклар тәкъдим ителә… Туристларның өзелеп торганы юк.

Балыкка бай Актанышта исә безгә Ерак Көнчыгыштан кайтартылган сөләйман балыгын тәкъдим итәләр. Җиләк-җимештән – Төркия лимонын. Менюда кыслалар бар идеме, дип сорап торуның мәгънәсе дә юк.

Аның каравы, безнең Агыйделдәге табигать финнарның «Нууксио»сыннан һич тә кайтыш түгел. Ә кайсыдыр ягы белән баерак та әле!

P.S. Актаныш муниципаль районы сайтында Туризм һәм кунакчыллыкны үстерү программасы белән танышырга була. Монда бик тирән фәнни-тикшеренү нәтиҗәләре игълан ителгән: районда табигый юнәлешле туризмның төрле төрләрен: экологик туризм, су, балык тоту һәм ау туризмын үстерү өчен потенциаль мөмкинлекләр бар. Программаның максатлары арасында – «дөнья базары таләпләренә җавап бирерлек заманча туристлык продукты булдыру». Аларга ирешүнең анык юллары да билгеләнгән. Планда, мәсәлән, машина кую урыны, бәдрәфләре, палаткалар өчен мәйданчыгы яки кечкенә өйләре булган заманча кемпинг төзү каралган.





ТАТАРСТАН *елгалары буйлап*

Тойма – Чулман елгасы кушылдыгы. Гомуми озынлыгы – 212 км, шуның 81 км – Татарстанда. Чулманга Алабуга шәһәре янында кушыла.

ТОЙМА. ШАЙТАН КАЛАСЫНА – ПИКНИККА!

Татарстан елгаларында су коенып яки балык тотып кына ятарга димәгән, бездә шундый урыннар да бар: алар ничектер серле-сихерле. Анда бару – мистик сәяхәт өчен шәп идея. Тойма елгасы ярындагы иске каланча да гади генә түгел, диләр, имеш, аңа шайтаннар иялəшкән…

Автор:
Ольга Туманская

Әзрәк нервларны кытыклап алу һәм яңа тәэссоратлар белән баю ниятеннән Алабугага юл тотабыз. Туп-туры – риваятьләргә кергән Шайтан каласына. Анда, Тойманың иң биек борынында, Чулманга койган җиреннән ерак түгел генә, япа-ялгыз соргылт каланча басып тора. Әлеге урын күп кенә риваять һәм мифлар белән уратып алынган. Шуларның берсе буенча, имештер, бик борынгы заманнарда бер руханиның кызына шайтан гыйшкы төшкән. Менә ул эти кеше янына кыз яучылап килгән. Әмма рухани кызын ачы язмыштан аралау өчен бер хәйлә уйлап тапкан, ди: елга ярына бер төн эчендә гыйбадәтханә төзеп куярга кушкан. Шайтан өчен бик җиңел тоелган бу эш! Бер сызгыруга үзенең кардәшләрен чакырып китергән дә, тегеләре таң атканчы диварлар корып, түбәсен ябып та куйганнар. Гөмбәзенә генә тотынганнар – сызылып таң аткан, әтәч кычкыруга, яңа корылма тирә-якка чәчелеп беткән. Бары тик бер каланчасы гына торып калган. Әгәр якынрак килеп карасаң, анда шайтан бармаклары эзен дә күрергә була икән…

Тик менә шунысы кызык: никадәр генә җен-шайтан, димәсеннәр, Шайтан каласы халыкта аномаль зона гына түгел, ә көч туплау урыны буларак билгеле. Шулай ук сәяхәтче-мосафирларның маршрутындагы яраткан урын да ул – бу турыда туристларның интернет-форумнарындагы күпсанлы фикерләр сөйли.

РИВАЯТЬКӘ ЫШАНМАСКА?

Шайтан каласына ике яклап килеп була. Югары шәһәрдән – Нефтьчеләр проспекты ягыннан җайлырак. Ләкин без җиңел юл эзләүчеләрдән түгел, шуңа да елга ягыннан керәбез. Машинаны калдырып, карашларны куәтле итеп ургылып торган борынга төбәп, өскә күтәрелә башлыйбыз. Югарыга таштан җәелгән басмалар менә. Борынгы болгар сукмагын ун ел элек алабугалылар үзләре яңарткан, диләр. Озынлыгы мең адым, ди.

Безнең тырыша-тырыша өскә менүебез бушка китми – каршыда искиткеч манзара ачылып китә: бөдрә әрәмәләр белән әйләндереп алынган тугайлар җәйрәп ята. Әлеге яшеллек кочагында бормаланып-бормаланып Тойма ага. Аның көзгесендә зәп-зәңгәр күк чагыла. Нәкъ менә шушында ул үзенең мөстәкыйль агымын тәгәлли – мәгърур һәм үзкөйле Чулман аны үзенә кабул итеп ала. Бу гүзәллектән карашны аерып алу җиңел түгел. Аякларның арганлыгы инде онытылган, текә ярдан сулу капканчы менгәннең эзе дә юк. Чып-чын сихер! Көч җыю урыны, дип тикмәгә әйтмиләр икән!

Моннан елгага гына түгел, Алабуганың үзенә дә искиткеч гүзәл манзара ачыла. Шайтан тояклары эзе калганга бер охшамаган. Элекке заманнар да булсын, мондый күренешне форпост өчен кулланма да? Менә фаразларны раслый торган мәгълүмат үзе дә бар: безнең эрага кадәр VII–V гасырларда, тимер дәверенең элгәре чорында, биредә җәйләү урнашкан, X гасыр ахырында хәрби кальга булган. Без бүген күргән каланча кайчандыр ак ташлы цитадель вазыйфасын үтәгән. Археологлар аны кальга-мәчет калдыклары дип фаразлый. Идел буе болгарларының монголларга кадәрге чордан җир өстендә сакланып калган бердәнбер корылмасы ул!

Элеккеге кальга хәрабәләре – каланың төп истәлекле урыны. Әлеге уникаль каланча 150 ел элек танылган рәссамның әтисе Иван Васильевич Шишкинның хәерхаһлыгы белән торгызыла. Дәверләрнең таш шаһитлары туристларны җәлеп итә дә инде. Җилле көнне борынгы диварлар янында фотога тиз генә төшәбез. Фотоаппарат төймәсенә бер-ике тапкыр басабыз да, локацияне велосипедларда килгән парга калдырып, алга таба китәбез. Үзебез җылымса ташларга утырабыз – каланың гүзәллеге сихер җепләренә урап тота әле…

СУДАГЫ СИХЕР

Ә аннары су янында – ярда пикник ясадык. Һәм ачык итеп шуны әйтә алабыз: Тойма – үзкөйле елга. Агым сине үзеннә җәлеп итә, сихерли, гүя елга үзе бу урында мистик көчкә ия. Озак итеп аңа карап торсаң, ул сине тәмам медитациядә оета. Барлык проблемаларны һәм авыр уйларны юа да агым белән еракларга алып китә…

Шулай озак утырыр идең әле, тик менә әйләнә-тирә генә шомландыра. «Кыргый» пляж чүп-чар белән тулган, монда кадәр машина белән килергә ярамаса да, тәгәрмәч эзләре ярылып ята. Күренеп тора, көймәдә йөзәргә яратучыларның да, балыкчыларның да яраткан урыны бу. Әнә, бер эти кеше улына балык тоту серләрен өйрәтә. Икесенә – өч кармак.

– Чиртәме? – дим, аларның тынычлыгын бозып.

– Бөтенләй чиртми! Болай гына инде, елга буенда басып тору гына…

Күрүегезчә, Тойма минем генә күңелгә ятмаган икән! Эх, шушы шәбәреп беткән яр буен шәһәр чирәме белән түгел, ә туган як үләннәре һәм тукранбашлар утыртып бизәргә дә, бер-ике чүп савыты куярга иде! Балыкчыларга – басма, көймәчеләргә – елгага төшәр өчен җайлы урыннар, машиналы кешеләргә – зур булмаган парковка. Шуннан артыгы, мөгаен, кирәкмидер дә – артыгын кыланып, табигый атмосфераны бозмаслык итеп кенә орынырга.

Ә бит сихри пикник өчен табигатьнең кәефе нәкъ тә туры килә! Аның идеясе өстә генә ята. Хәтта ерак түгел генә җәйрәп яткан таллык та шул рухка көйле. Еракатан караганда – матур гына, эченә керсәң – шомлы: аяк асты тулы ауган агачлар, сынган ботаклар, кергән җирдә, әйтерсең, «җен оясы». Ә бәлки, алай ук та түгелдер, анысын фантазия үзе хәл итә!..

Фото: Ольга Туманская



ТАТАРСТАН
елгалары буйлап

Нократ – Чулманның зурлыгы буенча икенче кушылдыгы. Озынлыгы – 1314 км, шуның 60 км – Татарстанда. Чулманга Мамадыштан 17 км түбәндәрәк, Грахань авылы янында кушыла.

МОНДА **НОКРАТ** ЧУЛМАН БЕЛӘН ОЧРАША

Мәскәү кешесе өчен каядыр Иделгә чыгып ял итү – бәхет ул. Чулманны күрү – уңыш. Ә инде Нократны ук күрү – лотореяга зур бүләк отуга тиң... Әмма мәскәүле өчен зур вакыйга булган нәрсә татарстанлы өчен гадәти, көндәлек эш. Көн дәвамында Иделдә, Чулманда, Нократта коенып алу белән бездә беркемне дә шаккатырып булмый. Ә инде Нократның Чулманга коя торган урынын картада эзләп табып, шунда юл тотсак, ничегрәк?

Автор:
Әскәр Сабиров

Эре таш түшәлгән юл Италиянең ниндидер бер ерак почмагын хәтерләтә. Юл кырыена ук чыгып үскән наратлар – күлләргә бай Финляндияне. Башны әйләндерерлек хуш ис. Каршыбызда йортлар күренүгә (күбесенә, ни кызганыч, галиҗәнап Вакыт мөһере сугылган), гаҗәеп матурлыктан җиңелчә баш әйләнү юкка чыкты. Сәфәребезнең соңгы ноктасы булган Грахань авылы үзенә бер караудан гашыйк итәргә җыенмый кебек тоелды. Ләкин тиз арада моның табигый горурлыктан икәнлеген аңлап аласың...

ИЛАҺИ МАНЗАРА

Йортлар кинәт юкка чыгалар, кителмәгән манзарадан сулышың каба. Менә кайда ул Чулман белән Нократ очрашкан урын – түбәндә, нәкъ синең аяк очыңда. Елга киңлеге офыкка кадәр сузыла һәм Грахань урнашкан тауга килеп терәлә – бу салмак сулы Чулман. Ә инде Грахань авылына сул яктан килгәне – тиз агымлы, җилкуар Нократ. Очрашып кочаклашкач, юнәлешен туксан градуска үзгәртеп алга таба үз юлын бары тик төпле, салпы-салмак Чулман гына дәвам итә, Нократ исә аңарда эреп юкка чыга.

Һәр елга суының кабатланмас үз төсе бар, диләр. Шулаен шулайдыр да, бәлки, ләкин күпме генә текәлеп карасаң да, ике зур елга бергә кушылган һәм Нократның Нократ булудан туктаган урынын таба алмассың. Тирә-ягында иксез-чиксез зәңгәр дәрья. Һәм тагын – елга кушылган урында урта гасыр кирмәнедәй эленеп торган Лачын тавы.

Агымсуга күз дә алмый озак карап торып буламы, белмим. Ә менә әлеге авыл янында табигать-ана тудырган манзараның сезне, бөтен дөньягызны оныттырып, үзенә гашыйк итәчәге – факт. Тикшерелгән.

ЯР БУЕНДАГЫ ТАУ ОЧЛАРЫ

Елгага таба төшү яңа тәэсирләр уята. Грахань, тыйнаклыгыннан бераз гына оялгандай, үзенең швед өстәлендәгедәй сый-нигъмәтләрен тәкъдим итә: юл буенда коймадай – кура җиләге, карлыган, крыжовник куаклары... Кызганыч, сливаның әле балланып өлгерергә вакыты җитмәгән, әмма аңардан башка да кабып карар нәрсәләр күп: монда үскән чиянең әчкелтем тәме яңакларны камаштыра...

– Кайчандыр биредә янгын чыккан. Йортлар янган, халык киткән, ә бакчалар шул килеш калган. Алар һәр яз гөрләп чәчәк ата, җәенкөзен уңыш бирә, – дип аңлатты безгә авылда яшәүче Мария әлеге җиләк-җимеш коммунизмын. Җәннәт бакчасыдай урыннардан да китә икән кешеләр! Һәм бары тик бәла-каза аркасында гына түгел. Иң имин елларда Граханьда 600 дән артык кеше яшәгән, узган гасыр башында авылда земство мәктәбе эшләгән, ике кирәк-ярак кибете булган, ә пристаньдә 30 мең потка кадәр йөк бушатылган. Ә аннан соң күмәкләшү еллары башланган. Соңрак – сугыш афәте, авылның 113 кешесе яу кырында ятып калган...

Грахань авылыннан яшьләрне «суырып алган» соңгы вакыйгалар Яр Чаллы һәм Түбән Камада барган гигант төзелешләргә бәйле. Бүген авылда гадәттә дистә ярым пенсионер кыш чыга, ә инде кибетләрне атнага ике мәртәбә кешеләр сораган даруларны һәм азык-төлекне китерүче автолавка алыштыра.

Нократ-Чулман ярларындагы кечкенә генә каралып утырган йортлар – Граханьның гөрләгән вакытларын искәртеп торучы дәлилләр, тагын бер истәлек. Нәрсә соң алар? Сарайлармы? Баз өсләреме?

– Без аларны тау очлары дип йөртәбез – гомер-гомергә безнең балыкчылар кирәк-яракларын, ишкәкләрен саклый торган өйләр ул, – дип сөйләде безгә Мария, үткәннәрне сагынып. – Балыкның иксез-чиксез күп булган вакытлары... Әти безне кәлчәк балыгы (чехонь – тәрҗ.) белән сыйлый иде. Ул шундый майлы, тәмле, киптергәч тә кояшта үтә күренмәле була торган иде.

Балык биредә, әлбәттә, әле дә бар. «Яр буе зонасы» дип язылган күрсәткеч янында, елга буенда ук калдырылган балыкчы машиналары шуны раслый.

ТАРИХ ТӘГӘРМӘЧЛӘРЕ

Елганың тамагына кадәр җитеп, берьюлы Нократта да, Чулманда да су коенмау – экваторга барып, төньяк ярымшардан көньягына аяк атларга иренүгә тиң булыр иде. Дөрес, суы артык җылы түгел, хәер, бу хәтта бераз шатландыра да. Сәфәрнең икенче адымын атлар өчен нәкъ менә тонуста булырга кирәк тә. Грахань авылы – ике зур елганың очрашу урыны һәм искиткеч гүзәл манзаралар ачылган җир генә түгел. Авыл каршында, күрше текә һәм күтәрелеп булмастай тауда – борынгы Грахань шәһәрлеге. Үргә менәргә тәвәккәлләп, азрак башны эшләтеп, хыялларны да кушсаң, шәһәрлекне әйләндереп алган калку урыннарны, саклык максатыннан казылган чокырларны күрергә, кырыс болгар гаскәриләренең киң дәрьяга күзләрен текәп, ят кабиләне күзәтүләрен күз алдына китерергә мөмкин. Монда елганың агымы теләсә кайсы көймәне ярга таба борырлык итеп ага, шуңа күрә алар укчылар өчен менә дигән мишеньгә әверелгән, дип сөйлиләр, имеш, дошманның исән калу мөмкинлеге бөтенләй булмаган.

Грахань шәһәрлегендә беренчеләрдән булып казыну эшләре

Фотолар автордан алынды







алып барган «археологның» җирле тимерче булуы да кызык тоелды. Ләкин ул «кара казучы» булмаган – шәһәрлектә артефактларны хакимият кушуы буенча эзләгән. Берүзе, озак еллар эзләгән – XIX гасыр азагында ук. Калкулыклардагы түгәрәк таплар – әлеге тимерченең тырышлыгы нәтиҗәсе. Ә табылдыклар – тимерче тапканнары гына түгел, аңардан соң эшләгән профессионалларныкылар да – бүгенге көндә музейларда саклана. Мәсәлән, 1925 елда табылган бронза асма бизәк.

Шәһәрлек буенча йөреп, инде күптән музейларда үз урынын тапкан раритетлар турында тыңлау ялыктырырга да мөмкин. Ә менә инде үз кулларың белән берәр борынгы әйбердән вакыт тузанын сыпырып төшерү – кызыклырак шөгыль. Әмма бу инде шәһәрлектә түгел, авылның үзендә.

Авыл уртасында, кечерәк кенә аланда зур таш күрәм. Ташның уртасында – тишек, кырыйлары шактый тупас эшкәртелгән. Болар барысы да кайчандыр, моннан бик күп еллар элек, әлеге гаять авыр кантар белән таш юнучылар эшләгәнлеге турында сөйли.

– Тегермән ташы бу, – дип, уемны җөпли Мария. – Кайчандыр монда тегермән торган. Үзе калмаса да, ташы сакланган – истәлеккә.

Хәтер яши икән, димәк, Грахань да яшәячәк. Җәйләрен халык саны шактый арта, диләр – балалар, оныклар җыелыша. Якын-тирәдә урнашкан предприятиеләрдә эшләп ялга чыкканнар да туган якларына кайта – менә шундый тенденция. Әлеге гүзәллекне шәһәр ыгы-зыгысына алыштыру – акыллы гамәлмени? Биредә бит Нократ белән Чулман очраша!

НИЧЕК БАРЫРГА

Казаннан М7 юлы буенча Мамадыш чатына кадәр барасы, аннан соң – уңга борылып, Соколкага илтүче юл буенча. Соколкага килеп җиткәнче сулга борылсагыз, асфальт түшәлмәгән юл сезне Граханьга, Нократның Чулманга кушылган җиренә китереп җиткерер.

ТРАДИЦИЯЛӘРГӘ НИГЕЗ САЛУЧЫЛАР

«ТҮБӘН КАМА НЕФТЕХИМ» НИЧЕК ИТЕП ГАИЛӘ, МӘХӘББӘТ ҺӘМ ТУГРЫЛЫК КӨНЕН БӘЙРӘМ ИТӘ

«ТАИФ» Компанияләр төркеменә кергән «Түбән Кама Нефтехим» ГАҖ хезмәткәрләре өчен ел саен Гаилә, мәхәббәт һәм тугрылык көнен бәйрәм итү матур гадәткә әйләнеп китте. Нәкъ 5 ел элек нефтехимиклар беренче тапкыр 8 июль көнне Нефтехимиклар паркында шәһәр халкына бәйрәм оештырган иде, хәзер ул Түбән Камада зурлап үткәрелә.

БЕРГӘ БУЛГАНДА, КӨН ДӘ БӘЙРӘМ

Бәйрәмнең төп кунаклары – озак еллар буе тигез гомер иткән бәхетле парлар була. Алга таба, шәһәр халкы яратып өлгергән чараны оештыру өчен нефтехимиклар белән Түбән Кама ЗАГСы хезмәткәрләренең иҗади тырышлыкларын берләштерү зарурияте килеп туа. Бу исә бәйрәмне тагын да күңеллерәк, кызыклырак һәм киң күләмле итеп үткәрү мөмкинлеге бирә. Өч ел рәттән ул Нефтехимиклар паркында уза, ә ике ел элек аны «Гаилә» паркында билгели башлыйлар.

Быел, 8 июльдә дә, бирегә күңелле тамаша колач җәйде. Чаралар программасына игезәкләр парады, «Love story»* стилендә ярәшү йоласының театральләштерелгән тамашасы, исем кушу йоласы кергән иде. Бәйрәм кунаклары шәһәрдәге шеф-поварлар уздырган мастер-классларда, «Бөтен гаилә белән аш-су әзерлибез» дип аталган гастрономик шоуда катнашты. Иң истә кала торган мизгелләрнең берсе – бәйрәмнең тантаналы өлеше иде. Амфитеатрда 25 елдан артык бергә гомер кичергән парларны бүләкләделәр.

Шул рәвешле 5 гаиләгә – «Гаилә – Түбән Кама горурлыгы» дигән муниципаль бәйге җиңүчеләренә Россиянең иҗтимагый бүләкләре – «Мәхәббәт һәм тугрылык өчен» медальләре тапшырылды. Бүләкләү алдыннан «Юбилярлар парады» булды. 13 пар нефтехимик кояшлы аллеялардан үтте. Алар өчен предприятие – яраткан эш урыны да, ныклы, тату гаилә корып, гомер кичергән җир дә.

500 ЕЛ ЧИК ТҮГЕЛ

«Түбән Кама Нефтехим» төзелгән вакытта ук бөтен илдән комсомол яшьләрне, яшь белгечләрне җәлеп итә. Үз эшләренә мөкиббән кешеләр предприятиедәге атмосферадан илһамланып, алга таба да хезмәт юлларын завод белән бәйлиләр. Биредә комсомол туйлары гөрли, яшь гаиләләр барлыкка килә, балалар туа, шәһәр төзелеше бара.

Шәһәр елъязмасының хезмәт батырлыклары тулы һәр бите, һәрбер хәрефе меңнәрчә гади эшче кулы белән язылган. Еракта калган 1956 елда химкомбинат проектын башлаган, 1960 елда беренче сәнәгать бинасы нигезенә беренче кирпечне салган кешеләрнең кулы белән. Гади эшчеләр, инженерлар, 1967 елда ракетницадан атып, предприятиенең газ фракциясе җәйләнмасында беренче утны кабызган легендар директор Николай Лемаев...

Вакытлар уза тора, аларның балалары әти-әниләренең мөһим һәм кирәкле эшләре, химия тылсымы, технологик яңалыклар һәм һөнәри уңышлар турында хикәятләр тыңлый инде. Хезмәткә һәм гаилә кыйммәтләренә ихтирамлы мөнәсәбәт предприятиегә эшкә килгән һәркемгә, буыннан-буынга тапшырылып килә. Үз эшеңә һәм гаиләңә тугрылык – бәхетле кеше өчен табигый күренеш бит бу. Бүгенге көндә «Түбән Кама Нефтехим» Гавами акционерлык җәмгыятендәге кайбер династияләренең гомуми хезмәт стажы 500 елдан артып китә. Шуңа да компаниядә «көмеш», «алтын», «ахак» һәм «алмаз» туйларын каршылаучы парлар шактый.

ТУЙНЫ БӨТЕН ЦЕХ БЕЛӘН ҮТКӘРДЕК

Шундый гаиләләрнең берсе – Вәлиуллиннар. Быел алар «фланель» туйларын – бергә гомер итүләренең 43 еллыгын билгеләде. Аларның хезмәт династиясенең гомуми стажы – 290 ел. «Түбән Кама Нефтехим» белән Любовь Александровнаның, Рәшит Рафыйкъ улының, аның ике апасы һәм аларның җәмәгатьләренең, энесенең, улының һәм туганнан туган энеләренең язмышлары бәйләнгән. Әлеге пар, шәһәрдәге башка бик күпләр кебек үк, «Түбән Кама Нефтехим»да очрашып кавыша. Рәшит белән Любовь этилен җитештерү заводында күрешеп таныша. Туйны бөтен цех белән бергә 1977 елны каршылаганда бәйрәм итәләр. «Без җитештерүнең ничек оештырылганын, эшләтеп җибәрү-кабызу эшләрен, беренче продукция чыгарганны үз күзләребез белән күрдек. Без бу

Реклама   Фотолар «Түбән Кама Нефтехим»нан алынды

* «Love story» – мәхәббәт тарихы.

заводны үзебез кордык, һәм ул безгә туганыбыз кебек якын», – дип искә ала Любовь Александровна.

Бер-берсенә карата ихлас һәм кайгыртучан мөнәсәбәт Вәлиуллиннар гаиләсенә «Гаилә – Түбән Кама горурлыгы-2019» муниципаль конкурсында җиңәргә булышкан. 8 июль көнне бәйрәмдә әлеге парга тантаналы рәвештә Россиянең иҗтимагый бүләге – «Мәхәббәт һәм тугрылык өчен» медален тапшырдылар.

МӘХӘББӘТ ҺӘМ ТУГРЫЛЫК ҮРНӘКЛӘРЕ

Җәй уртасы, бәйрәмнең ачык, җете төсләре балаларны да, өлкәннәрне дә шатландыра, музыка астында процессия сәхнәгә үтә. Бөтен парлар бер-берсенә гашыйк күзләр белән карый, куллар-кулда, иреннәрдә – оялчан елмаю. Мәхәббәт тылсымы аларга гаилә кыйммәтләрен һәм туй көнендәге хисләрне саклап калырга ярдәм иткән. Шулардан берсе – Гыйльмановларның тату гаиләсе. 25 ел бергә яшәү дәверендә алар дүрт бала тәрбияләп үстергәннәр. Гөлнара Ринат кызы профсоюз эшләре белән шөгыльләнә, цех комитеты рәисе булып тора. «Түбән Кама Нефтехим»ның «Гаилә учагы. Без бергә бәхетле!» бәйгесендә Гыйльмановлар өченче урынны алды.

Киселевлар гаиләсе турында да туган предприятиеләрендә барлыкка килгән, дияргә була. Андрей белән Надежда бер сменада эшли, төш вакытында бергәләп ашханәгә йөриләр. Туй көннәреннән соң 30 ел узган, һәм шушы вакыт эчендә аларның мәхәббәте ныгыган гына.

Гөлирә белән Рушан Хөрмәтуллиннар институтның икенче курсыннан бергә. Быел алар бергә гомер итүләренең 33 еллыгын билгеләли. Аларның уллары Айдар Рушан улы – династияне лаеклы дәвам итүче, бүлек начальнигы булып эшли.

«Түбән Кама Нефтехим» Гавами акционерлык җәмгыяте гаилә династияләренең язмышлары да охшаш. «Юбилярлар парады»нда катнашучылар туган предприятиеләрендә танышкан, ул – алар өчен гаиләнең финанс иминлегендәге тотрыклы нигез, ә хезмәт коллективы уңышларга бергә сөенеп, проблемаларны бергә хәл итә торган зур бер тату гаилә булган. Шушы бердәм гаилә, компаниянең генераль директоры Азат Бикморзин һәм предприятиенең профсоюз оешмасы исеменнән бәйрәмдә катнашучыларга «Түбән Кама Нефтехим»ның профсоюз оешмасы рәисе Фәнис Мортазин мөрәҗәгать итте. «Бүген мөһим, матур бәйрәмгә җыелдык. Гаилә институты кеше өчен һәрвакытта да – беренче урында. Кеше иң элек гаиләдә формалаша, анда нинди тәрбия алса, шуның белән кеше арасына чыга. Моның ачык мисалы – мөхтәрәм юбилярларыбыз һәм бирегә җыелган һәммәбез. «Түбән Кама Нефтехим» администрациясе, безнең берләшмәнең зур коллективы һәм шәхсән үз исемемнән сезгә бик күпләргә үрнәк булып, бер-берегезгә ихтирамлы мөнәсәбәтегез өчен, бер-берегезне кадерләвегез өчен рәхмәт әйтергә рөхсәт итегез. Сезгә ныклы сәламәтлек һәм тигез гомер телим», – диде ул.

ХЫЯЛЛАР ЧЫНГА АШКАН ҖИР

Әнә шулай итеп кайчандыр яшь комсомоллар үз куллары белән төзегән предприятие аларның бәхетле хезмәт һәм гаилә тормышының бер өлеше булып киткән. Предприятиенең беренче легендар генераль директоры Николай Лемаев вакытында ук нигез салынган традицияләр бүген дә дәвам итә. Әйтергә кирәк, директорның 90 яшьлек юбилеен «Түбән Кама Нефтехим» 14 ноябрьдә билгеләячәк. Компания һөнәри яктан үсәргә, бөтен гаиләнең сәламәтлеге турында кайгыртырга, бергәләп ял итәргә мөмкинлекләр бирә – болар барысы да коллектив килешүдә язылган. Сәламәтлек саклау, хезмәтне һәм ялны оештыру, торак белән тәэмин итү, нефтехимикларның гаиләләре турында кайгырту буенча программалар «Түбән Кама Нефтехим»ның социаль яктан җәлеп итә торган предприятие, абруйлы һәм лаеклы эш урыны булуын раслый.

«ӘНИ КЕБЕК КӨЧЛЕ ХАТЫННАР СИРӘК...»

Беркөн авылга кайткач, сүз иярә сүз китте дә: «Майтап апага йөз яшь тулды. Әле дә ялгызы яши. Ашарына да үзе пешерә, бакчасына суны да үзе сибә», – диделәр. Гаҗәпләндем. Йөзне тутырган әбиләр турында шактый язылды, әмма ялгызы яшәп, ризык әзерләп ашаучыларны күргән юк иде. Туган нигеземнән бер урам аркылы гына яшәүче Майтап апага алдарак бармаганыма үкенеп тә куйдым.

Автор:
Руфия Фазылова

ГӨЛБАКЧАЛЫ ЙОРТ

Майтап апа Зәйнетдинова Апас районының Олы Бакырчы авылында яши. Тормыш иптәше Шәйхетдин абый белән 9 бала үстерә. Тыштан караганда биредә һич кенә дә йөз яшен тутырган ялгыз әби яши димәссең! Йорт-җирләр ялт иткән, капка төбеннән үк таш түшәлгән. Ишек алды да шау чәчәктә утыра. Башка беренче килгән сорау: бу чәчәкләрне кем утырткан да, кем су сибә икән?

Ишекне шакып, Майтап апаның өенә уздым. Бер авылда, күрше урамнарда гына яшәсәк тә, күптән күргәнем юк иде үзен. Юк, әллә ни үзгәрмәгән. Кем икәнемне әйткәч тә таныды. Дәү әни, дәү әти исемнәрен атадым. Журналга язам, дигәч, аптырап китте:

– Тукта, алайса, матур күлмәгемне кияргә кирәк, – дип куйды.

– Күлмәгең бик матур, Майтап апа, кирәк түгел, – дигәч:

– Алайса яулыгымны булса да алыштырыйм, – дип хафаланды.

Йорт эчен күзәтәм: һәр нәрсә үз урынында, челтәрле мендәрләр матур итеп утыртып куелган. Ник бер артык әйбер аунап ятсын. Тәрәзә төбендә гөлләр үсеп утыра.

– Майтап апа, капка төбеңнән үк чәчәкләр үсә, өең дә бик чиста. Балаларың кайтып булышадыр? – дим.

– Әйе, балалар. Яшел Үзәндә Фәрит улым яши, теш врачы ул, беләсеңдер. Менә аның теплицасы бар. Иртә яздан чәчәкләр утырта, монда да алып кайта. Минем чәчәкләр яратканны белә ул.

– Ә кем аларга су сибә? – дим.

– Төрлечә, балалар килмәгәндә үзем дә чыгам. Краннан су килеп тора бит. Таякка таянам да сибәм. Балалар, эшләгәнемне күрсәләр, әрлиләр инде. Соң аяк-кул йөргәндә өйдә утырып буламыни?!

Йөз яшен тутырган өлкәннәр белән сөйләшкәндә, еш кына бер сорау бирәм: хәзер ничәнче ел? Президент кем? Авылдаш әбиемә дә бирдем ул сорауны. Ул, бер дә озак уйлап тормыйча:

– Беләм, беләм, 2016 ел бугай, – диде.

– Юк, Майтап апа, 2019 ел быел. Сиңа быел 100 яшь тулган бит, – дип төзәтергә туры килде. Ә менә «татар егете – Рөстәм исемле Президентның» исемен белде.

– Әле тагын берсе бар, анысы Мәскәүдә, исемен генә оныттым. Ай саен миңа өстәмә акча җибәреп тора. Әйе, мин бит хезмәт ветераны. Шуның өчен Мәскәүдән 4 мең 900 сум акча килеп тора. Башта 4 мең 500 сум иде, 17 нче майдан арттырганнар. Шуңа өстәп, Казаннан төп пенсия килә, 16 мең. Әлһәмдүлилләһ, бик рәхәттә яшим.

– Майтап апа, йөз яшь тулган икән сиңа. Моны сизәсеңме? – дим.

– Юк, наным, миңа узган ел 100 тулды. 1918 елгы мин. Ирем мине 1919 дип яздырган. Сугыштан соң Ташкент шәһәренә чыгып киттек. Читкә киткәндә документ кирәк булгач, ирем Шәйхетдин шулай дип яздырып кайткан. Аннан үзгәртеп йөрмәдем инде, шулай калды.

Майтап апа авылның Арттагы урамында яши. (Бездә күпчелек урамның борынгыдан килгән рәсми булмаган шундый исемнәре бар.) Яшь вакытларын искә алып, менә ничек сөйләде ул:

– Мин Түбән очта үстем. Дәүләр каршында елга бар бит, менә шуның янәшәсендә иде безнең йорт. Минем кушамат – «Шәпи», әтине «Шәпи Зәһидулласы» дип йөриләр иде. Әнинең төп нигезе су буенда – Тәкәрлектә булган. Анда элек алмагач бакчасы иде. Олы Бакырчы бик зур иде бит, гомер-гомергә районның иң зур авылы саналды. Тау башы урамы гына да үзенә бер авыл кебек иде. И, хәзер бетте инде. Тәкәрлектә, Тау башында да берничә йорт кына калды. Әле безнең Арттагы урамда ярыйсы, кеше бар. Күршеләрем дә әйбәт. Берәр ят машина, кеше килсә, тәрәзәдән күреп, хәзер килеп җитәләр.

Фото: Лилиана Вәлитова

Майтап апа хәзер капка төбеннән ары китми икән, башым әйләнә, ди.

– Кайбер көнне ашарга да пешерә алмыйм, Гөлинә килә. Кич тә кунып китә, – диде.

Кызы Гөлинә апа күрше урамда гына яши. Сорау туарга мөмкин: ни өчен йөз яшьлек әнисен үзләренә генә алып китми:

– Килми бит, – ди Гөлинә апа. – Мин генә түгел, башка балалары да әйтеп карый. Юк, үзендә яшисе килә. Нишләмәк кирәк? Кызлар, киленнәр, оныклар килеп, өен җыештырып китәбез. Үзенең хәле булмаганда ашарына да пешерәбез. Ул безгә йөк булудан курка. Әни кебек көчле хатын-кызлар сирәк очрый. Гаҗәп кеше ул...

БАТЫР ЙӨРӘКЛЕ МАЙТАП АПА

Майтап апа чынлап та батыр йөрәкле. Тормыш иптәше Шәйхетдин абый Бөек Ватан сугышыннан бер аягын өздереп кайта. Шул килеш ул аңардан 10 бала табарга курыкмый.

– Сугышка кадәр ирем белән бер ел гына яшәп калдык, – диде Майтап апа. – Ул вакытта балаларыбыз булмады. Сугыш вакытында мин окоп казыдым, ат җиктем. Шәйхетдин кайткач, Ташкентка чыгып киттек. Анда тормыш җиңелрәк, диделәр.

Тик ир белән хатынның өметләре акланмый. Майтап апа әйткәнчә, аларны анда берәү дә көтеп тормый. Өч ел яшәгәннән соң, уллары Зыятдинны күтәреп, сумкаларын төйнәп, туган якларына кайтып китәләр. Ташкентта яшәп, ике ел буена җыелган мөлкәтләре – өч кило дөге һәм кипкән җиләк-җимеш. Хәер, сугышта ачлыктан тилмергән ир белән хатынга Үзбәкстан җимешләрен ашау җәннәттә булып кайткан кебек тоела.

– Ни өчен кире туган ягыгызга кайтырга булдыгыз? – дидем Майтап апага.

– Сагындырды. Анда да, монда да шул тормыш икән, дидек. Туган ягыңда, ичмасам, белгән, якын кешеләрең. Шәйхетдингә ияреп чыгып китүемнең сәбәбе дә бар: сәламәтлеге яхшырсын, дидем. Сугыштан бик бетеренеп кайткан иде.

Ташкенттан кайтуның исә тагын бер сәбәбе булырга да мөмкин. Дөрес, моны Майтап апа ачыктан-ачык әйтмәде. Шулай да хәтер сандыгында йөртә аны.

– Болай гына әйтә алмыйм. Карточкадан карасам беләм. Тәк... Иң олысы Зыятдинныкылар – алты бала, Әгъзамныкы – ике, Рәшитнеке – өч, Гөлинәнеке – ике, Равиянеке – ике, Әлфиянеке – бер, Фәритнеке – ике, игезәкләремнең берсе Рифкатьтә – 2, Фиркатьтә – 3. Тагын бер кызым бар иде, анысы дүрт айлык чагында үлде.

Майтап апа нарасый кызын гына түгел, ике улын да җирләде. Өченче улы Рәшит абый, төпчеге Фиркать абый да юк инде.

– Фиркать бигрәк яшь китте, корган тормышының рәхәтен күрми калды, – диде ана кеше. – Төннәр буе уйланып ятам. Хәзер йокы бит төрлечә. Уянам да авылның бер очыннан кереп, икенчесенә чыгам. Бу йортта кемнәр яшәде соң, дип саныйм. Үз балаларымның яшен саныйм. Саташтыра хәзер, буталам. Әле ике-өч ел гына хәтер болай түгел иде. Йөз яшь үзен сиздерә икән, наным. Аякта йөрсәң дә, баш бетә.

Әлбәттә, Майтап апага тугыз баласын аякка бастыру җиңел булмаган. Ике ел саен бала тапкан ул. Аны менә ничек кызык итеп сөйли:

– Иң авыры балаларны ашату түгел иде, ә юындыру. Берсеннән берсе кечкенә бит. Башта мунчага берсен алып барам, юындырам да өйгә күтәреп чабам. Аннан икенчесен алып киләм. Шулай биш-алты тапкыр киләм. Аннан соң гына үзем юынам. Аллага шөкер, балаларны таза-сау үстердем. Ике яшькә кадәр имездем...

Авылыбызның озын гомерле ак әбие белән бергә яшелчә бакчасын карап чыктык. Бөтен нәрсә үсә бирәдә.

– Балалар утырта, алар чүбен дә утый, – диде.

Майтап апа июль башыннан бирле яңа бәрәңге ашый икән. Иртә өлгерә торган төрен утырткannар.

– Улларым да, кызларым да әйбәт. Алар кыландыра инде. Мин бик бәхетле ана, – диде.

...Йөзьяшәр әби капка төбенә кадәр озата чыкты. Изге теләкләрен теләп, кул болгап калды ул. Кайтканда үзем өчен бер ачыш ясадым кебек: тырыш, зар белмәүче, пакъ күңелле кешеләр генә йөзгә кадәр җитәдер сыман тоелды. Һәрхәлдә, мин күргән йөзьяшәр әбиләрнең барысын да шул сыйфатлар берләштерә.

– Шәйхетдин сугышка кадәр Ташкентта яшәп алган, – диде. – Шунда ул бер үзбәк хатыны белән торган. Хәтта бер кызлары да туган. Аннан кайтты да миңа өйләнде. Ә мин аның Ташкентта нишләп йөргәнен белмәдем. Бу турыда соңрак, сугыштан соң гына белдем. Хәтта Ташкентта базарда йөргәндә иремнең беренче хатынын күрсәттеләр дә...

Майтап апа бу хәлләрне уздырып (хәер, ничек итеп уздырганын үзе генә белгәндер) ире белән яшәвен дәвам иткән. Әйткәнемчә, бер-бер артлы 10 бала тапкан.

Шәйхетдин абый да тырыш булган. Шул бер аягы белән өч тапкыр йорт кына салып кергән. Майтап апага өйләнгәнче дә йорты булган аның.

– Ташкентка киткәч, каенанамнан хат килде, – дип сөйләде Майтап апа. – Сеңлеңә акча кирәк, син эшләгән йортны сатып җибәрдек, дип язган. Шәйхетдин бик ачуланды, тик җавап язмады. 1949 елда Ташкенттан кайттык. Яшәргә урын юк. Каенанамның йорты иске, бик кечкенә. Шуннан без бер иске йортны сатып алдык. Анда кандала иде, йоклап булмый. Шуны агулап, йортны яңадан сипләдек. Шәйхетдин, аяксыз булса да, бер эштән дә куркып тормады. Аяклы кешеләр белән тигез эшләде. Икенче улыбыз тугач, иске йортны сүтеп, яңасын эшләдек. Мин дә бик булыштым. Ул заманда ир, хатын эше дип бүлеп тору юк иде...

«ИҢ АВЫРЫ – БАЛАЛАРНЫ ЮЫНДЫРУ»

Майтап апа белән балалары турында сөйләшеп утырабыз. Ул алар белән бик горурлана. Икенче улы, Әгъзамы, ТРның атказанган табибы. Тагын бер улы – теш табибы. Бөтен тирә-якта беләләр үзен. Калган ике улы – эшкуар, кызлары да төшеп калганнардан түгел. Пар канатлары белән мул тормышта яшиләр.

– Гел шуны уйлап, сөенеп утырам: балаларымның барысы да башлы-күзле булды, бер дигән итеп яшиләр, – диде ун дистәне түгәрәкләгән әби. – Төпле булдылар. Бер-берсенә ярдәмчелләр, үзара татулар. Әле быел Сабантуйга йөздән артык кеше җыелды. Урманда бик зур бәйрәм ясадылар. Минем йөз яшьлекне бәйрәм иттеләр. Мине дә алып менделәр, зурладылар...

– Ничә оныгың бар? – дигәч, Майтап апа алгы яктан фотосурәт алып чыкты. Һәм санарга кереште:

МӘҢГЕЛЕК КЫЙММӘТЛӘР

БУ САНДА ТӘКЪДИМ ИТӘБЕЗ:

Йосыповлар нәселе **НИЧЕК** дәвам итә

Татар язучысына беренче музей **КАЙЧАН** ачыла

Профессионаллар мизгелләрне **НИЧЕК** туктата

Иң тырыш кешеләр **КАЙДА** яши

ЙОСЫФ МОРЗА ВАРИСЛАРЫ

Халкыбызның иң атаклы шәхесләреннән берсе Сөембикә Йосыф кызының тууына быел 500 ел тула (1519–1557). Аның турында без сөйләп үткән идек инде (журналыбызның быелгы 3 нче санын карагыз). Әлеге мәкаләдә сөекле ханбикәбезнең юбилее уңаеннан, аның изге рухына багышлап, әтисе Йосыф морза варислары турында да кыскача белешмә бирергә булдык. Бик катлаулы һәм гыйбрәтле язмыш ияләре аларның барысы да. Россия тарихында сизелерлек эз калдырганнар.

Йосыф морза
(1480нче – 1555)

Йосыповлар династиясенең тарихын кайвакыт Мөхәммәт пәйгамбәрнең дусты, көрәштәше, ахыр чиктә кияве (ул аның Гайшә исемле кызына өйләнә), Багдад хәлифәтенең беренче хәлифәсе Әбү-Бәкердән башлап җибәрергә тырышалар. Тик бу чыганаклар белән расланмаган бер версия генә. Йосыф морза – Алтын Урда таркалып барган чорда аның бердәмлеген яңадан торгызырга омтылыш ясаган олуг карачыбәк, Ногай Урдасына нигез салучы атаклы Идегәй нәселеннән. Монысы – тарихи факт. Йосыф морза (1480 нче елларда туган дип фаразлана) 1554 елда нугай морзалары арасында туктап тормаган низаг-талашлар вакытында үтерелә. Бу вакытта аның сөекле кызы, көчләп Шаһгалигә кияүгә бирелгән Сөембикәсе, Касыймда тоткынлыкта яши. Ике энесен – Ибраһим белән Илморзаны – әтиләре үлгәннән соң Мәскәүгә Иван IV патшага хезмәткә җибәрәләр, «туенып тору» өчен Романов шәһәрен (хәзерге Ярославль өлкәсендәге Тутаево шәһәре) өязе белән өлеш итеп бирәләр.

Автор:
Фаяз Хуҗин

Ибраһим морза нәселе XVIII гасырда өзелә, аның варислары арасыннан тарихта эзләрен калдырган атаклы шәхесләр чыкмый. Ә менә Илморза (1611 елда вафат) балалары һәм оныклары аркасында тарихка кереп калган затлар шактый.

ЙОСЫПОВЛАР – РОССИЯ ТАРИХЫНДА

Илморзаның биш улы Михаил Романов (1613–1645), Алексей Михайлович (1645–1676) патшалык иткән чорда хәрби хезмәттә булалар. Биш баланың дүртесе православие диненә күчә, берсе, Сөюш исемлесе, ислам диненә тугрылыклы булып кала. Сөюшнең Габдулла исемле бер улы 1681 елда Дмитрий исеме белән чукындырыла. Моның өчен аңа элеккеге морза урынына кенәз титулы бүләк итәләр. Ул 1682 елгы укчылар чуалышы вакытында үзен кыю һәм тәвәккәл хәрби җитәкче итеп күрсәтә: кул астындагы отряды һәм аңа ияргән татар йомышлылары белән берлектә Троица Лаврасында яшерелгән ун яшьлек Петр Алексеевичны – тиздән император булачак патшаны – сакларга килә һәм аны үлем куркынычыннан коткарып кала. Моның өчен аның Романов өязендәге вакытлы биләмәләрен вотчина – нәселдән нәселгә күчә торган җирләр дәрәҗәсенә күтәрәләр. Тиздән кенәз Дмитрий Сөюшевич дворяннар нәселеннән чыккан Катерина Яковлевна Сумарокова исемле бай тол хатынга өйләнә һәм, елдан-ел байлыгын арттырып, 1695 елда гүр иясе була.

Григорий Дмитриевич Йосыпов (1676–1730) – Дмитрий Сөюшевичның кече улы, бай мөлкәтенең варисы, тарихка император Петр I нең якын тарафдары, уң кулы буларак кереп калган олы шәхес. Петр I тарафыннан алып барылган барлык сугышларда – 1695–1696 елгы Азов походында, 1700 елгы Нарва, 1709 елгы Полтава яуларында, хәрби флотилия төзүдә Григорий Дмитриевич искиткеч активлык күрсәтә. Намуслы хезмәте белән танылып өлгергән Григорий Дмитриевичны Петр I коррупциягә һәм закон бозуларга каршы көрәш комиссиясе җитәкчесе итеп куя. Ул аны

Иллюстрацияләр: «История рода князей Юсуповых» китабыннан; Фәридә Харрасова

Сөембикә ханбикә,
Йосыф морза кызы

Дмитрий Сөюш улы Йосыпов (Абдул морза),
Сөембикәнең энесе Илморзаның оныгы

Григорий Дмитриевич
(1676–1730)

Борис Григорьевич Йосыпов,
Г.Д. Йосыповның улы
(1695–1759)

Николай Борисович
(1751–1831)

Борис Николаевич
(1794–1849)

Николай Борисович (кечесе)
(1827–1891)

Зинаида Николаевна
(1861–1939)

Феликс Феликсович,
кенәз Йосыпов,
граф Сумароков-Эльстон
(кечесе)
(1887–1967)

үзенә тапшырылган эшләрне вакытында һәм җиренә җиткереп башкарып чыгуы, дәүләт хезмәтенә җитди һәм җаваплы каравы, империягә тугрылыгы һәм фанатларча бирелгәнлеге өчен хөрмәт иткән. Шунысын да әйтеп үтәргә кирәктер: Петр I вафат булгач, аны соңгы юлга озатканда, табуты артыннан императорга иң якын торган дәүләт сановниклары – кенәз Александр Меншиков, граф Федор Апраксин һәм кенәз Григорий Йосыпов баралар.

Григорий Дмитриевичны Петр I дән соңгы императорлар да хөрмәт иткәннәр, хезмәтен югары бәяләгәннәр. Екатерина I (1725–1727) аңа беренчеләр рәтендә Изге Александр Невский ордены тапшыра (шул орден булдырылган көнне үк), Император Петр II Мәскәүдә бик матур һәм зур сарай салып бүләк итә, үзе полковник булып исәпләнгән Преображенский полкның подполковнигы итеп билгели, Анна Иоановна (1730–1740) Григорий Дмитриевичны генерал-аншеф дәрәҗәсенә күтәрә. Ул бай җирбиләүче феодал да була: фидакарь хезмәте өчен аңа Түбән Новгород, Калуга, Рязань, Курск, Харьков, Воронеж, Ярославль губерналарында дистәләрчә мең дисәтинә сөрүлек җирләре, крепостной крестьяннары белән авыллар бүләк итеп бирелә.

Борис Григорьевич Йосыпов (1695–1759) әтисенең әнә шул байлыгына ия булып туа. Егерме ике яшендә аны башка дворян уллары белән берлектә Франциягә, гардемариннар әзерли торган Тулон училищесына укырга җибәрәләр. Әмма ләкин Россиягә әйләнеп кайтуга ук, ул хәрби-диңгез хезмәтен ташлый. Анна Иоановна вакытында Борис Григорьевичка сарай камергеры чины бирелә, аннан соң ул Мәскәү генерал-губернаторы итеп билгеләнә. Елизавета Петровна идарә иткән чорда (1741–1761) Борис

Григорьевич хакыйкый яшерен киңәшче чинына лаек була, Коммерц-коллегия президенты итеп сайлана, дворян балаларын хәрби һәм чиновниклык карьерасына әзерли торган Коры юл шляхта кадет корпусы – привилегияле уку йорты директоры вазыйфаларын башкара.

Утыз сигез яшендә Борис Григорьевич уналты яшьлек Ирина Зиновьева исемле гвардия капитаны кызына өйләнә. Бу никахтан аларның дүрт кызы һәм Россия тарихында киләчәктә күренекле урын алып торачак уллары Николай туа.

Николай Борисович Йосыпов (1751–1831) – «Европаның иң атаклы шәхесләре рәтендә аталып үтәргә тиешле зат». Бу сүзләрне Николай Борисовичның чордашы, Париж Фәннәр академиясе академигы Виллуазон язган. Бу бала яшьтән үк белемгә омтыла, сәнгатьнең төрле төрләре белән кызыксына һәм егерме өч яшендә унбиш ел буена (1774–1781) берөзлексез диярлек Европаның Германия, Голландия, Дания, Англия, Испания, Португалия, Франция, Италия, Австрия кебек илләрендә сәяхәт итеп, аларның картина галереяларында, театрларында, аксөяк салоннарында була – күрә, өйрәнә, сәнгать дөньясына кереп чума. Шул ук вакытта Лейден университетында хокук, фәлсәфә, сәясәт һәм табигый фәннәр буенча курслар үтәргә, атаклы галимнәрнең лекцияләрен тыңларга да өлгерә. Гаагада кенәз Йосыпов Дени Дидро, Лондонда Бомарше белән таныша (шагыйрьнең аңа багышланган юморескасы да бар), Парижда аны король Людовик XVI һәм аның хатыны Мария-Антуанетта Версальгә чакыралар. Биредә ул Вольтер белән күрешә. Венада исә композиторлар Гайдн һәм Глюк белән әңгәмә кору бәхетенә ирешә.

1783–1789 елларда Николай Борисович Италиядә Россия илчелегендә дипломатик хезмәт белән шөгыльләнә. Ул биредә үзен башлыча сәнгать белгече буларак таныта, Европаның танылган антикварлары, коллекционерлары белән бәйләнешкә керә, Екатерина II заказы буенча Эрмитаж һәм үзенең шәхси коллекциясе өчен картиналар, скульптура әсәрләре, кыйммәтле ташлар, бизәнү әйберләре сатып ала. Европаның талантлы рәссамнарына аерым темага картиналар язарга заказлар бирә. Папа Пий VI рөхсәте белән бөек Рафаэль тарафыннан эшләнгән Ватикан фрескаларының күчермәләрен ала. Бу фрескалар бүген дә Эрмитаж коллекцияләренең бизәге булып тора.

Россиягә әйләнеп кайткач, Николай Йосыпов үзен дәүләт хезмәтендә күпкырлы талант иясе буларак күрсәтә: 1791–1799 елларда ул – Император театрлары, Эрмитаж, пыяла һәм фарфор заводлары, шпалер мануфактуралары директоры, 1796 елдан башлап – Мануфактур-коллегия президенты, 1800 елдан – уделлар министры, 1823 елдан – Дәүләт советы әгъзасы.

Россия империясендә тиңе булмаган факт: Николай Борисович Йосыпов баш маршал дәрәҗәсендә 29 ел эчендә өч императорны – Павел I не (1797), Александр I не (1801) һәм Николай I не (1826) коронацияләү – рәсми рәвештә тәхеткә утырту тантанасы белән җитәкчелек итә.

1793 елда, кырык ике яшендә, Николай Борисович егерме дүрт яшьлек графиня Татьяна Васильевна Потемкина белән гаилә кора. Тиздән аларның Борис исемле уллары дөньяга килә. Никахлары уңышлы булып чыкмаса да, алар рәсми рәвештә аерылышмыйлар. Татьяна Васильевна өч баласы белән (икесе элеккеге никахтан) Петербургта кала, Николай Борисович Мәскәүгә күчеп китә, Архангельское исемле шәһәргә якын бер бистәдә яшәвен дәвам итә. Биредә ул Александр Пушкин белән таныша, алар озак кына сөйләшеп утыралар, соңыннан дуслашып ук китәләр. Пушкинның Николай Борисовичка атап язылган «К вельможе» исемле шигыре сакланып калган.

… Ты понял жизни цель: счастливый человек,
Для жизни ты живешь. Свой долгий ясный век
Еще ты смолоду умно разнообразил…

Феликс Феликсович (олысы) һәм Зинаида Николаевна граф Сумароков-Эльстон ягыннан туганнары белән. 1880 нче еллар фотосы.

Борис Николаевич Йосыпов (1794–1849) – Николай Борисович белән Татьяна Васильевнаның бердәнбер улларын талант иясе дип булмый. Аңа әти-әнисеннән бай мирас кала: 250 мең дисәтинә җир, 40 меңнән артык крепостной крестьян, Мәскәүдә, Петербургта, Кырымда менә дигән йортлар, сарайлар… Бу милек белән башлыча аның хатыны Зинаида Ивановна идарә итә. 1830 елда сатып алынган өч катлы, патша сараедай искиткеч матур йортның биш зур залында картиналар галереясы урнаштыралар. Борис Николаевич шул галереяда урнаштырылган 483 картина һәм 31 скульптура әсәрләренең каталогын төзи һәм француз телендә бастырып чыгара.

Николай Борисович Йосыпов (кечесе) (1827–1891) – Борис Николевич белән Зинаида Ивановнаның бердәнбер уллары. Исеме бабасы хөрмәтенә куелган. Тикмәгә түгелдер: ул да бабасы Николай Борисович кебек сәнгатькә, бигрәк тә музыкага тартыла, әдәбиятны ярата, үзендә картиналар коллекциясе булдыра, меценатлык белән шөгыльләнә. Петербург университетының юридик факультетында укып югары белем ала һәм 1850 елда император Николай I канцеляриясендә үзенең хезмәт карьерасын башлап җибәрә. 1852 елда аны Тифлиска, Кавказ наместнигы канцеляриясенә, бераздан Рига генерал-губернаторы карамагына җибәрәләр. 1854 елда, Кырым сугышы чорында, Николай Борисович үз хисабына ике пехота батальонын сугыш киемнәре һәм кораллар белән тәэмин итә, моның өчен Изге Владимир ордены белән бүләкләнә. 1855 елда ул Бавариядәге рус илчелегендә дипломат вазыйфаларын башкара. Николай I үлгәннән соң, император Александр II коронациясенә церемониймейстер буларак чакырыла.

Николай Борисович карьера баскычы буйлап һаман югарыга үрмәли: аны статский советник дәрәҗәсенә күтәрәләр, Бөек сарайның гофмейстеры итеп билгелиләр. Буш вакытларында ул музыка белән шөгыльләнә, Рим музыка академиясенең, Париж консерваториясенең, Мюнхен сәнгать җәмгыятенең шәрәфле әгъзасы булып тора. 1867–1868 елларда Николай Борисович Йосыповлар нәселе турында «О роде князей Юсуповых. Собрания жизнеописаний их, грамот и писем к ним Российских Государей» исемле ике томлык китабын бастырып чыгара.

Хатыны графиня Татьяна Александровна Рибопьер белән Зинаида һәм Татьяна исемле ике кыз тәрбияләп үстерәләр. Татьяна 22 яшендә, әтисеннән өч ел алдан үлә.

Зинаида Николаевна Йосыпова (1861–1939) **һәм Феликс Феликсович Сумароков-Эльстон.** Зинаида искиткеч чибәр, мөлаем һәм тәрбияле кыз булып үсә. Аңа хәтта Европаның төрле илләреннән корольгә, герцогка, графка кияүгә чыгуын сорап, яучылар килә. Зинаида Николаевна 1882 елда граф Феликс Феликсович Сумароков-Эльстон исемле кешегә кияүгә чыга. 1891 елда Николай Борисович (кечесе) – Йосыповлар нәселеннән соңгы ир-ат – Баден-Баденда үлә. Атаклы нәселнең киселмәвен, дәвам иттерелүен теләп, әлбәттә, гаиләсенең рөхсәте белән, ул әле исән чакта ук Александр III гә кияве Феликс Феликсовичка Йосыпов фамилиясен бирүне үтенеп мөрәҗәгать иткән була. 1894 елда, үзе үлгәннән соң, аның бу үтенече канәгатьләндерелә. Хәрби карьерасын бөек кенәз Сергей Александровичның адъютанты сыйфатында башлап җибәргән Феликс Йосыпов (Сумароков-Эльстон) соңрак генерал дәрәҗәсенә күтәрелә, 1914 елда Мәскәү хәрби округы башлыгы, аннан соң Мәскәү генерал-губернаторы итеп билгеләнә.

Феликс Феликсович Йосыпов (кечесе) (1887–1967) – Зинаида Николаевна белән Феликс Феликсович (Сумароков-Эльстон) Йосыповларның кече уллары (олысы Николай 25 яшендә үлә). Озын буйлы, төз гәүдәле, зыялы гаилә кагыйдәләренә, аристократия этикетына сыешмыйча, үзен артык иркен тотарга күнеккән чибәр егет булып үсә. 27 яшен тутыргач, аны бик уңышлы өйләндерәләр, хатыны Ирина Александровна – император Александр III нең оныгы. Ирина исемле кызларының исем атасы (крестный отец) – император Николай II.

Феликс Йосыпов императорга, Ватанга хезмәт итүдә артык тырышлык күрсәтми. Ул тарихка император сараенда бик абруйлы саналган шарлатан һәм әхлаксыз зат Распутинны үтерүдә катнашучы буларак кына кереп калган (бу турыда Феликс Йосыпов үзенең «Конец Распутина» дигән истәлекләр китабында тәфсилләп сөйли). Әлеге гамәле өчен аны 1916 елда Петроградтан Курск губернасындагы утарына «сөрәләр». 1917 ел вакыйгаларын ул шунда каршылый. Болганчык еллар башлана. Феликс Йосыпов үзенең гаиләсе белән башта Кырымдагы резиденциясенә кача. 1919–1921 елларда алар Лондонда яшәп алалар, аннан соң Парижга килеп төпләнәләр (Париждагы тормышларын Феликс Йосыпов «В изгнании» дип аталган китабында бәян итә).

Зинаида Николаевна, бөек княгиня Ксения Александровна, Ирина Феликсовна һәм Ирина Александровна. 1933 елгы фото. Париж.

1938 елда Ирина һәм Феликс Йосыповларның кызлары Ирина граф Николай Дмитриевич Шереметьевка кияүгә чыга. Аларның 1942 елда туган кызлары Ксения Йосыпова-Шереметьева (ул иренең фамилиясен йөртә – Сфирь) бүген дә исән, үзенең ата-бабалары Ватанын онытмый. 1999, 2005 елларда һәм быел июнь аенда ул Петербургта булып китте. 2000 елда Ксения Николаевнага Россия Президенты указы белән, башында Нугай Урдасы идарәчесе, Сөембикә-ханбикәнең әтисе Йосыф морза торган борынгы нәселгә караган күренекле затларның Ватан алдындагы хезмәтләрен тану һәм югары бәяләү билгесе итеп, Россия гражданлыгы бирелә. Т

Ксения Йосыпова кызы Татьяна һәм кияве Антонис белән. 2005 ел. Санкт-Петербург. Йосыповлар сарае

КЕЧЕ ВАТАН ПАТРИОТЛАРЫ

МАТУР ТУГАНДА, ЯКИ УЙЧАН КЕШЕ

Балачакта миңа бу гыйбарә искиткеч серле булып тоела иде. Тел очында тәмен кат-кат тояр өчен, бертуктаусыз кабатлап йөргәнем хәтердә. «Ә нигә матурлык түгел?» дип сораганым да. Бу сорауга җавапка татар теле һәм әдәбияты укытучысы: «Матур туганда – ул матур киләчәк тә була ала, матур кешеләр дә, матур хыяллар да, матур әсәр дә, матур дәүләт тә...» – дип җавап биргән иде. Хәзерге акылым белән аңлыйм: язучы күздә тоткан матурлык төшенчәсе үз эченә революция шаукымын гына алмаган, ә яңа матур тормыш төзибез дигән ихлас ымсынуны да.



Әзерләде:
Луиза Янсуар

«ЯЗГАННАРЫМДА ЯМАН БЕРНИ ДӘ ТАПМАССЫЗ...»

Шәриф Камал турында архивларда истәлекләр әллә ни күп сакланмаган. Кайсы гына әдәби стенограмма, беркетмәгә юлыкма, катнашучылар арасында исеме телгә алына, ә үзе, әйтерсең, юк. Бик сирәк кенә кистереп әйткән фикере яңгырап куя. Әйе, шулай хәтерлиләр аны: аз сүзле, анык фикерле, дип. Күп сөйләми, әйтсә, кистереп әйтә, ә инде принципиаль мәсьәләләргә килгәндә, үз фикерендә ахыргача кала.

Партиядән чыгаралар, килеп чыгышына бәйләнәләр, әмма бер тапкыр да кулга алмыйлар Шәриф Камалны. Хәтта кулга алынган каләмдәш дусларын, шәриктәшләрен яклап күтәрелүенә дә карамастан.

ТР Милли архивы фондларында татар язучылары белән бәйле архивлар мулдан саклана. Кәрим Тинчурин, Шамил Усманов, Кави Нәҗми, Фатих Кәрим язмышларына бәйле документларда Шәриф Камал исеме дә калкып чыга. Гади хезмәт кешесе тормышына багышланган реалистик әсәрләре белән билгеле әдипне, яңа идеологияне пропагандалаучы буларак, хакимият танымый калмый. Ул татар язучыларыннан беренче булып Ленин орденына лаек дип табыла. Ә аннары, «халык дошманнары белән бәйләнештә торганы өчен», партбилетыннан колак кага. Партиядән чыгарып ташлау өчен Кәрим Тинчурин белән дуслыгы, Кави Нәҗмигә тагылган гаепнең ялган булуын кистереп әйтүе, Шамил Усмановны яклап чыгуы гына да җитә, билгеле.



Фотолар: ТР Милли музее, Байгильдиевлар архивыннан алынды



«Ул елларда әдәбият оешмалары башында баручы иптәшләрнең хәзергеләрнеке кебек «фән докторы», «атказанган» дигән дәрәҗәле исемнәре дә юк иде. Әмма алар идеалларына бирелгән нык, үзфикерле кешеләр иде. Бу иптәшләр, шәхси тормышларын онытып, авыр да, җаваплы да әдәбият йөген үз өсләренә алдылар, аны фидакарьләрчә бирелгән хәлдә, бөтен көчләре белән тартып бардылар. Әдәбиятны замана таләбе югарылыгына күтәрергә тырыштылар».

Гомәр Бәширов истәлекләреннән.

1936 елның августында Татарстан Язучылар союзы идарәсе каршысындагы партия оешмасы «троцкист-зиновьевчыларга каршы актив көрәш башлап җибәрә». Бу сәяси шаукымда иң беренче булып олы зыян күргән язучыларның берсе Шамил Усманов була. Аны берләнбер Шәриф Камал яклап чыга. «Зәңгәр шәл», «Казан сөлгесе» әсәрләрендә революциягә кадәрге крестьян тормышын сурәтләүдә, социалистик реализм таләпләреннән читләшүдә гаепләнгән Кәрим Тинчуринны да, Гөлсем Камская, Мөхтәр Мутин, Хөсәен Уразиков, Гөлсем Болгарскаялар белән беррәттән, Шәриф Камал яклый. Беренче тапкыр сират күперен исән-имин килеш узган Тинчуринны озакламый кабат алып китәләр. Баштарак аның тормыш иптәше Заһидә ханым белән дус булып исәпләнгәннәр дә кул биреп күрешми башлый. Шундый бер истәлек сакланып калган: көннәрдән бер көнне Шәриф Камал, урамның икенче ягында Заһидә Тинчуринаны күреп ала да, аның янына чыгып кулын бирә, Кәримнең хәлләре ничек, дип сораша. Бу да аны шәхес буларак күрсәтә торган сыйфатларның берсе, дияргә буладыр…

1919 елдан бирле ВКП (б) әгъзасы булып торган Шәриф Камалны партия сафларыннан чыгаргач, ул бик бирешә, кайгыра. Мондый сүзләре сакланып калган: «Язган-

Кулга алынган язучыларны нигездә Җинаять кодексының 58 нче статьясы буенча гаеплиләр, ә ул үз эченә 14 маддәне ала. Димәк ки, атып үтерүгә кадәр җәзалауның барлык төрләрен куллануга киң мөмкинлекләр бирә, дигән сүз. 50 гә якын татар язучысы бу җәза иттарткычы аша уза һәм кайсы сорау алганда, кайсы тоткынлыкта, кайсы сөргеннәрдә һәлак була.

«Сабан» газетасы редакциясе коллективы белән. Оренбург. 1925 ел.

Шәриф Камал гаилә әгъзалары белән. 1920 нче еллар.

Төрле елларда – каләмдәшләре белән.

нарымда яман берни дә тапмассыз. Миңа инде яшәргә күп калмады. Әгәр сез мине, 1919 елдан бирле партиядә торган әгъзаны, аның сафларыннан чыгарасыз икән, соңгы минутларымны гына якынайтачаксыз...»

Асылда, шулай була да. Татар әдәбиятының классигы Шәриф Камал 1942 елның 22 декабрендә 56 яшендә Казанда, Островский урамында урнашкан фатирында үз үлеме белән үлә.

Мин аны иң соңгы мәртәбә Союзда Шәйхи Маннурның фронттан кайтуы уңае белән уздырылган мәҗлестә очраткан идем. Кичәдән без Афзал Шамов, Гариф Галиев белән бергә чыгып, Шәриф абыйны Островский урамындагы квартирына кадәр озата бардык.

Иртәгесен Шәриф абзый ишегалдында утын яргән, квартирына утын ташыган. Шул эшләрдән соң, «әллә нигә башым әйләнеп тора» дип, канәфиенә кереп яткан. Шул ятудан инде тора алмаган. 22 декабрьдә, кичке сәгать 5 тулып 20 минутта Шәриф абзый мәңгегә күзен йомды.

Гомәр Бәширов, «Күзгә ачы җилләрдә»

ТОРМЫШ САБАКЛАРЫ

«Татар әдәбияты тарихында Шәриф Камал иң башлап кыска хикәя-новеллалар остасы буларак танылган язучы. Бу жанрны ул реалистик юнәлештә үстереп җибәрде һәм аның эчтәлеген заман чынбарлыгы белән сугарды. Беренче адымнарыннан ук аның әдәби иҗат кыйбласын тормышчанлык һәм халыкчанлык билгеләде», – дип яза әдип турында әдәбият галиме Гали Халит.

Шәриф Камалетдин улы Байгилдиев 1884 елның 27 (15) февралендә элекке Пенза губернасы Инсар өязе (хәзерге Мордва Республикасы Рузаевка районы) Пешлә авылында туа. Атасы Камалетдин шул авылда муллалык итә, бик иске карашлы һәм каты күңелле кеше булган, диләр. Әнисе Зөләйха абыстай исә нечкә күңеллелеге, самимилеге белән аерылып торган.

Ул башта үз авылында күрше мәхәлләдәге мәдрәсәдә укый. Унике яшендә аны, күбрәк белем алсын дип, Пешләдән бераз читтәрәк Лөбәҗә мәдрәсәсенә җибәрәләр. Бу вакытларда Шәриф инде 14–15 яшьләрдә була. Аңарда иске мәдрәсә тормышыннан ризасызлык уяна башлый, үзенчәрәк яшәү теләге туа. Мәдрәсәне ташламаса да, 16 яшьлек егет шул вакытларда салына башлаган Мәскәү – Казан тимер юлына эшкә китә.

1900 нче елларда Шәриф Камал шәлче байларга приказчиклыкка ялланып, алар белән төрле җирләргә сәүдәгә чыгып йөри. Бу эш тә аңа шактый гыйбрәтле тормыш сабагы бирә: ул төрле кешеләр белән очраша, чынбарлыкның яхшы-яман якларына күзе ачыла бара. Шулай йөри торгач, Рига шәһәренә барып

1923 елның 13 мартыннан башлап шул елның сентябрь аена кадәр мин атаклы татар язучысы Шәриф Камал абый белән Оренбург шәһәрендә 18 нче балалар йортында эшләдем. Оренбург мәгарифе тарафыннан Шәриф абый белән без бер үк көнне ул заведующий, мин тәрбияче булып билгеләндек. Шәриф абый белән таныш булуым һәм бергә эшләргә тиешлегем турындагы шатлыгым әле дә исемдә. Мин Шәриф абыйны, язучы булгач, аерым бер зур кешедер, дип уйлый идем. Ләкин ул бик гади кеше булып чыкты. Без Шәриф абый һәм аның гаиләсе белән бер гаилә кешеләре кебек яшәдек.

Сентябрь аенда 18 нче балалар йорты бетерелеп, балалар икенче балалар йортына таратылды. Мин балалар белән берлектә 11нче балалар йортына күчтем. Шәриф абый Оренбург татар педагогия техникумына укытучы булып күчте. 1924, 1925 елларда ул шунда укытты...

Педагог Гөлкәй Зәйнуллина истәлеге.
22.12.1944 ел.

җитә, аңарда шундый урында белем алу хыялы кузгала. Ләкин Ригада хыялын тормышка ашыру мөмкин булмагач, 1901 елда бер иптәше белән Одессага юнәлә. Максаты – Төркиягә чыгып, андагы уку йортларының берсенә эләгү була. Кесәсендә акча, чит илгә чыгу өчен паспорт юклык та аны юлдан туктатмый. Ул Төркиягә барып җитә. Монда шулай ук ярлы егеткә берәү дә якты чырай күрсәтми. Шулай да Шәриф Камал аптырап калмый: ачтан үлмәслек язу-сызу эшләре таба һәм укытучылар хәзерли торган «Дарелмөгаллим»гә лекцияләр тыңларга йөри.

Берәр елдан соң Шәриф Камал Истанбулдагы татар яшьләре белән Мисырга китәргә карар кыла. Каһирә шәһәренә килеп җитәләр. Ләкин кая барсалар да, фәкыйрьлек эзәрлекли. Шәриф Камал бервакыт, пошынудан туктап, ныклы рәвештә укырга керешә. Гарәп газетасының редакторы Гали Йосыфның мәкаләләре белән, Йосыф Брагыйның хикәя һәм новеллалары белән кызыксына башлый. Бигрәк тә аны Мөхәммәт Габдеһе (Габду) кызыксындыра. Габду – шул вакытта яшәгән гарәп публицисты һәм Англиянең колониаль сәясәтенә каршы кискен мәкаләләр, очерклар язган журналист була. Әнә шул очерклар каләм тибрәтү хыялы белән янган егетне бик нык рухландыра.

Каһирәдә бер елдан артыграк торганнан соң, 1903 елда Шәриф Камал Россиягә кайта. Шундый «изге» җирләрне күргән егетне мулла булырга үгетли башлыйлар. Ләкин ул үз кул көче белән көн күрү, бәхет табу ниятеннән һич тә чигенми. 1903 елда Екатеринослав (хәзерге Днепропетровск) губернасындагы күмер шахталарына барып, күмер ташучы һәм забойчы булып эшли, тимер юл төзәтә, балык тоту промыслында тир түгә.

Шәриф Камал бәхет эзләгән еллар – Россия тарихының иң кызган, ил өстендә революция дулкыны күтәрелгән чорына туры килә. Ярлыларга яңа, матур тормыш бүләк иткән идеология, әлбәттә инде, яшь егетне дә җәлеп итми калмый. 1905 ел башларында ул туган ягына әйләнеп кайта. Бирегә «Канлы якшәмбе» турындагы хәбәрләр килеп ирешә, Шәриф Камал Пешлә авылына күрше генә Рузаевка станциясендәге тимер юл эшчеләренең митингларында катнаша. Аннан Петербургка китә һәм анда укытучылык эшенә керешә. Ныклап рус телен өйрәнә башлый. Аның югары уку йортына керү теләге тагын да көчәеп китә. Гадәттәгечә, бу максатына ирешә алмаса да, икенче изге ният – язучы булу нияте ныклап кабына. Туганы Гыймади Байгильдиев ярдәмендә Петербургтагы мөселман җәмәгатьчелеге белән якыннан таныша. Аның ярдәме белән «Нур» газетасында шигырьләре белән хикәяләрен бастырып чыгаруга ирешә. 1906 елда яшь егетнең «Сада» («Аваз») исемле тәүге шигырьләр җыентыгы дөнья күрә.

1907–1910 елларда Шәриф Камал үз авылларында яши һәм балалар укыта. Шунда беренче хикәясе «Уяну»ны язып, «Шура» журналына җибәрә, һәм хикәя басылып та чыга. 1910 елда, Төркестан якларына барганда, ул Оренбургта тукталып кала. «Шура» редакциясенә үзенең хикәяләрен тәкъдим итә һәм матбугат органнарының берләшкән конторасына хисапчы булып эшкә керә, аннары «Вакыт»ның корректоры, ахырдан әдәби хезмәтчесе булып эшли.

Оренбург Шәриф Камалның иҗаты чәчәк аткан урын була. Нәкъ менә биредә ул үзенең башлангыч чор иҗатының таҗы саналган «Акчарлаклар» әсәрен яза, «Хаҗи әфәнде өйләнә» пьесасын иҗат итә. Соңгысы революциягә кадәрге чордагы комедия жанрының өлгесе санала. Бу әсәр белән Габдулла Кариев кызыксынып китә һәм аны «Сәйяр» труппасына куяр өчен җибәрүен үтенеп, авторга хат юллый. Спектакль зур уңыш белән бара.

Әмма Оренбургтагы тормыш шартларының Шәриф Камал гаиләсе өчен шактый авыр булуы да мәгълүм. «Матди кысынкылык һәм яшәү урыннарының начарлыгы язучының көндәлек юлдашлары булып, аның саулыгына һәм иҗатына кире тәэсир ясап торалар», – дип яза аның бу еллары хакында шул ук Гали Халит.

КАЗАНГА –
ИҖАТ КАЗАНЫНА

1925 елда Шәриф Камал Казанга күченеп килә. «Кызыл Татарстан» газетасында, «Совет әдәбияты» журналында эшли. Биредә ул «Таң атканда», «Козгыннар оясында», «Таулар», «Томан артында», «Матур туганда» кебек татар әдәбиятының классик фондын тәшкил иткән әсәрләрен яза.

1934 елда иҗатының 25 еллык юбилеен шаулап уздыралар. Юбилярны республика дәрәҗәсендә зурлап тәбриклиләр. Чакырылган кунаклар исемлеге 150 дән артык кешедән гыйбарәт була. Алар арасында Кави Нәҗми, Кәрим Тинчурин, Галимҗан Нигъмәти, Хәсән Туфан, Газиз Гобәйдуллин, Евгения Гинзбург һ.б. була. Татарстан Язучылар Союзына күпсанлы котлау телеграммалары агыла.

Шул ук 1934 елда Шәриф Камал СССР Язучылар Союзы сафларына алына. Әмма репрессияләр дулкыны башланып, баш очында, Гомәр Бәширов әйткәнчә, «яшеннәр уйный» башлагач, Шәриф Камалның бу иҗади уңышларын да исәпкә алмыйлар. ТР Милли архивы фондында Шәриф Камалга ачылган шәхси эш саклана. Анда язучының автобиографиясе дә бар. Ул язучы тарафыннан үзен саклап калыр, совет дәүләтенең магистраль идеологиясенә тугры икәнлеген исбатлар өчен язылган булса кирәк. Автобиография машинкада басылган, әмма Шәриф Камалның үз култамгасын сакламаган, бәлки дело өчен аны кемдер әзерләгән, дигән фараз да бар.

ТЕЛЕГРАММА

СРОЧНАЯ ТЕЛЕГРАММА

ПЛАМЕННЫЙ ПРИВЕТ ТЕБЕ, ДОРОГОЙ ШАРИФ КАМАЛ, ПО СЛУЧАЮ ИСПОЛНЕНИЯ ДВАДЦАТИПЯТИЛЕТИЯ ТВОЕГО ТВОРЧЕСКОГО ТРУДА. В ПРОЦЕССАХ ДОЛГОЙ УПОРНОЙ БОРЬБЫ ТОБОЮ СОЗДАНЫ ПЕРЕДОВЫЕ ШЕДЕВРЫ ТАТАРСКОЙ ЛИТЕРАТУРЫ. В ТЕБЕ СЧАСТЛИВО СОЧЕТАЮТСЯ БЛЕСТЯЩИЙ ТОНКИЙ ХУДОЖНИК, ГЛУБОКАЯ СВЯЗАННОСТЬ С НАШИМ ВЕЛИКИМ СОЦИАЛИСТИЧЕСКИМ СТРОИТЕЛЬСТВОМ. ИСКРЕННЕ РАДУЮСЬ ТВОИМ УСПЕХАМ, ЖЕЛАЮ ДАЛЬНЕЙШИХ БОЛЬШИХ ТВОРЧЕСКИХ ДОСТИЖЕНИЙ,

ГАЛИМДЖАН ИБРАГИМОВ.

ОСТРОВСКИЙ УРАМЫНДАГЫ 15 НЧЕ ЙОРТ

Шәриф Камалның вафатыннан соң, аның кызы Зәйнәп Байгильдиева язучының фатирын дәүләт карамагына тапшыра. 1944 елда өч бүлмәне биләп торган бу фатирны әдәби музей итәргә дигән карарга кул куела. Шулай итеп, 1950 елда Казанда татар язучысына беренче музей ачыла.

Музейның йөрәге – мемориаль фатир – хәзерге көнгәчә сакланган, ул Шәриф Камал яшәгән чордагы атмосфераны тулаем чагылдыра. Бирегә «Шәриф янына» яки «Шәриф абый янына» дип үз чорында каләмдәш дуслары, аркадашлары, музыкантлар, яшь иҗатчылар килә торган була. Аларның исемнәрен атау гына да җитә: Кәрим Тинчурин, Салих Сәйдәшев, Мансур Мозаффаров, Гази Кашшаф, Муса Җәлил, Гадел Кутуй, Фатих Кәрим, Җәүдәт Фәйзи, Гомәр Бәширов... Островский урамында – элеккеге сәүдәгәр йортында урнашкан коммуналь фатирда үз чорының иң күренекле шәхесләре җыелып, иҗади сөйләшүләр, бәхәсләр алып барган, «матурлык тудырырга» омтылган. Шәриф Камалны яшь язучыларга гаять игътибарлы булган әдип буларак та хәтерлиләр. Аның сүзе әдәбиятка килүчеләр өчен фатиха булып яңгыраган.

Җәйнең матур бер көнендә Түбән Осланның чирәмле калкулыгында «Сиваш» романыннан өзек тыңларга җыелдык. Шәриф абый да килде. Бу өлкән агайның килүе безне, яшь язучыларны, чиксез шатландырды. Һәрвакыт киеп йөри торган калын кысалы зур күзлеген төзәткәләп, тамак кырып алганнан соң, Шәриф Камал да сүзен әйтте:

– Моңарчы язылган әсәрләрнең күбесе, гомумән, гражданнар сугышы хакында булса, синең әсәрең конкрет бер чорга – Кырымны азат итүгә багышланган, – диде ул.

Әмма Шәриф абыйның «ләкин»е дә бар иде.

– Ләкин, миңа калса, Гомәр иптәш, геройларның халәте рухиясен тагын да тирәнрәк итеп бирергә мөмкин булыр иде кебек сизәм. Моңа әсәрдә мөмкинлек бар. Гомәр иптәш, сез Язучылар союзына алуларын үтенеп гариза яздыгызмы әле?

– Юк әле, Шәриф абзый.

– Минемчә, мондый әсәрне язган авторның союз члены булырга хакы бар. Болай булгач, өметле инде, өметле.

Мин бу сүзләрне Шәриф абзыйның миңа зур әдәбиятка керергә фатихасы дип аңладым.

Бу кешеләр талантлы авторларның яңа әсәрләренә чын күңелдән куана беләләр иде. Матбугатта аларга киң юл ачалар. Бу бәхәсләр кайчакта ярты төнгә кадәр сузыла. Тынып калган Казан урамнары буйлап мин еш кына аларны уйлый-уйлый кайта идем.

Гомәр Бәширов,
«Көзге ачы җилләрдә»

КРАТКАЯ АВТОБИОГРАФИЯ ШАРИФА КАМАЛА

Теперь мне больше пятидесяти лет. Большая часть моей дореволюционной жизни, насчитывавшей больше тридцати лет, прошла в морально гнилой среде, в духовно-смрадной атмосфере. Я, родившись в семье деревенского муллы, до семнадцати лет учился в старой, религиозной школе (медресе).

Тогда я стал стремиться к тому, чтобы вырваться из этого гнилого болота. Нанявшись на работу к одному человеку, уехал. Нелегально перебрался в Турцию. Поехал в Египет. Два года в нищенском положении учился. Однако не нашел себе удовлетворения. Вернулся снова в Россию.

Попал на Донбасс. Около года работал в шахтах Екатеринославской губернии в кругу татарских и украинских рабочих в качестве салазочника и забойщика. После этого уехал на Кавказ, где около года работал на железнодорожном ремонте, а затем на прикаспийских рыбных промыслах.

И здесь надоели жестокая эксплуатация, бескультурье, беспросветная жизнь. Тогда вернулся в деревню и несколько лет учительствовал. Но урядничий гнет, кулацкая эксплуатация, фанатико-религиозный смрад душили и здесь.

Уже в те годы я пописывал рассказы, в которых отражал отдельные явления из рабочей и деревенской жизни. Основы классовой борьбы и марксистская философия еще не были мне знакомы. (...)

Октябрь переродил меня сызнова. Я осознал вполне ясно, что во все предыдущие годы жил слепо, бессмысленной, жалкой и дешевой жизнью, в обстановке слез и воплей. Я уже ясно видел, что нет другого пути кроме революционной борьбы большевиков, чтобы избавиться от бескультурья, беспросветной жизни, разрушить ее и построить другую жизнь, новую, светлую.

После Октября я стал работать в большевистской печати. В 1919 году вступил в ряды партии. Благодаря условиям Татарской республики, созданной на основе Ленинско-Сталинской национальной политики, для меня открылись неисчерпаемые творческие возможности для работы в области литературы и драматургии. Я считаю величайшим своим счастьем, что живу в эпоху великого Сталина и веду творческую работу под руководством партии.

Шариф Камал.



Шәриф Камал шәһәр музеенда (хәзерге көндә – ТР Милли музее).



Габдулла Кариевның Шәриф Камалга язган хаты. 1915 ел.



«Акчарлаклар». «Вакыт» газетасы типографиясе. Оренбург. 1915 ел.



Михаил Шолоховның «Поднятая целина» әсәре Шәриф Камал тәрҗемәсендә.

Шәриф Камалның туган авылы Татар Пешләсе. Мордовия Республикасы, Рузаевка авылы. 1940 нчы еллар.



Рамиль Гали:
– Начар фотолар – коточкыч хаталы итеп язып, аны бөтен кеше күрерлек итеп, «Инстаграм»га яки «Фейсбук»ка элеп кую кебек ул. Чеп-чи надан-лык булып чыга.
Фотога төшергәндә, мин үземне рәссам итеп хис итәм: буяуларны күрәм, аларның төсмерлә-ренә, пейзажның төсләр көйләнешенә игътибар итәм. Вакыйга төшергәндә, иң элек болытларга, үләннәргә, кар көртләренә карыйм, аннан соң гына эченә чумам, әлеге матурлыкның эчендә ятканны эләктереп алырга омтылам…



Александр Ефремов:
– Минем өчен фотография – яшәү рәвеше һәм дөньяга караш ул. Шул ук вакытта фотография – ул айсбергның башы гына, аның тирәнлеге – рух хәрәкәте, үзенә күрә медитация. Хәзер телефонга төшереп, шундук социаль челтәрләргә куеп була… Ләкин, минемчә, бөтен кешегә иҗатны гына күрсәтеп була, тормышыңның миллион да бер мизгелен яки тәнеңнең бер өлешен түгел. Сакалмы ул, кендек-ме, йә булмаса, теш чистартумы, яисә йомырка тәбәсе ашаганыңны күрсәтүме – боларның берсенең дә әһәмияте юк. Үзеңнең тырнак ас-тыңны күрсәтеп бару фотография дигән сүз түгел әле. Эчке һәм тыш-кы арасында чик җуелганны күрсәтә торган диагноз бу. Бу фотограф-лар өчен оят нәрсәләр.

МИЗГЕЛДӘН МИЗГЕЛГӘ

Аларның хезмәте куркыныч та, кыен да. Һәм, беренче карашка, күренми дә кебек… Алар мизгелләрне туктату, вакыйгаларны мәңгеләштерү, ел фасылларындагы үзгәрешләрне теркәп калдыру сәләтенә ия. Алар безне матуррак, сөйкемлерәк итә алалар, шул ук вакытта үзебезгә ошамаган якларыбызны да тотып алырга мөмкиннәр. Тиз һәм төгәл эшлиләр, мизгелдән мизгелгә. Эссе челлә дә, зәмһәрир суык та аларны куркытмый. Алар эшли. Күктә дә, җирдә дә. Йөгерә-йөгерә, сикерә-сикерә, оча-оча һәм… кырын ятып. Әлеге осталар һөнәри бәйрәмнәрен 12 июльдә билгеләп үттеләр. Журнал эшендә фотографлардан башка мөмкин түгел! «Татарстан»ны алар матур да, көчле дә, хисле дә итә.

Алена Кутыркина:
– Минем өчен фотография – кадрны күрү ул. Дөньяга мин матурлык күрәм дип карыйм, һәм кайсыдыр бер мизгелдә мин теләгән кадр оеша, шул вакытта мин камерага үреләм… Шуңа да минем өчен һәрбер сурәт, шул исәптән «Инс-таграм»га куелганы да, төймәгә басу гына түгел, ул үзендә минем вакыйганы ничек күрүемне, шул мизгелдәге кәефемне чагылдыра.



Солтан Исхаков:
– Жанрлы фотолар төшерергә яратам. Анда мизгелнең асылын күрсәтергә, фотога карап, кәефне чамаларга була. Портретта кешенең холкын күрсәтергә тырышам. Бернәрсәне дә аңлатмаган йөзләрчә сурәт күз алдыннан үтә, алар мине җәлеп итми, кызыксыну уятмый – бу секундның меңнән бер өлешенә игътибарны үзенә тарткан клиплы фикерләү рәвеше генә.

Ната Смирнова:
– Эмоцияләр, хисләр, үз-үзеңә ышаныч, хәтер – фотога төшергәндә менә шул тойгылар белән ала. Фотографны да, модельне дә. Һәм тагын репортажга дигән күзәтүләр – уйнамыйча, табигый, иреннәрне кабартмый гына… Тормышны-ы-ың үзен күрсәтү! Чынын! Фотографиядән чабылмаган үлән исе килгәндә, җилдән бала йоннары кабарганда, кояш нурларыннан җылы бөркелгәндә. Мин кешеләрне фотога төшерергә яратам, бигрәк тә бер-берсен сөйгәннәрне, гашыйкларны. Мин аларны тоям, алар белән бергә хисләнәм, очам, йөзәм. Минем эш – тоташ ярату ул.

Александр Эшкинин:
– Еллар узган саен кешеләрнең хисләре сүлпәнәя бара. Ләкин фотография минем өчен һәрвакыт кызыклы булып кала, ул төймәгә басу гына түгел, ә процесс буларак үзенә тарта. Бервакыт телевизорда яшь фотографларга: «Цифрлы фото бетеп, элеккеге кебек тасмага төшерә торган фото гына калды, ди. Нишләячәксез?» – дигән сорау бирделәр. Алар шунда ук бу эштән китәчәкбез, безгә һәр кадрның күренеп баруы кирәк, дип җавап бирделәр. Хикмәт бит анда түгел, хикмәт иҗадилыкта. Ә ул төймәгә басудан бигрәк, кадрны эзләп табуны таләп итә. Миңа фотография хобби буларак кызыклы. Хоббием – эшем, һәм мин шуңа бәхетле дә.





КӨЧЛЕ ТАТАРСТАН

ГЕР КҮТӘРҮ БУЕНЧА РОССИЯ ЧЕМПИОНАТЫ

Июнь 2019.
Казан.
«Ак Барс» Көрәш сарае

Иң көчле 200 гер күтәрүче, Россиянең төрле төбәкләреннән килгән 38 команда иң көчле исемен алу өчен ярышты.





Фото: Александр Ефремов

ЧЕМПИОНАТ РОСС
II
3
56
8 56
3

ЯШЕЛ ТАТАРСТАН

«ГОЛЬФ ЯРАТУЧЫЛАР – 2019» БӨТЕНРОССИЯ ЯРЫШЛАРЫ

Июнь 2019.
Югары Ослан районы, Савино авылы.
«Свияжские холмы» гольф клубы

Россиянең төрле төбәкләреннән җыелган 100 гольф яратучы, шулай ук Чехия Республикасыннан, Австралиядән килгән, Россиядәге чит ил уенчылары 18 чокырны үтте.



Фото: Александр Ефремов

КАНАТЛЫ ТАТАРСТАН

RED BULL AIR RACE УЗЫШЛАРЫ

Июнь 2019. Казан. Кремль яр буе

Master класслы 14 очучылар командасы һәм Challenger класслы 10 очучы җиңел манёврлы самолётлар белән идарә итү осталыгы буенча Казансу елгасы өстендә көч сынашты.

Фото: Александр Ефремов

ҖИЛКӘНЛЕ ТАТАРСТАН

ҖИЛКӘНЛЕ КӨЙМӘЛӘР ФЕСТИВАЛЕ

Май – июнь 2019.
Түбән Кабан күле акваториясе

Җилкәнле көймәләр фестивале – Җилкәнле көймәләр милли лигасы сериясенең өченче этабы. 300 спортчы Лиганың өч – Югары, Премьер һәм Балалар дивизионнары буенча иң көчлеләрне билгеләделәр.

Фото: Александр Ефремов

6

УКУЧЫ ТАТАРСТАН

ҖӘЙГЕ КИТАП ФЕСТИВАЛЕ

Июнь 2019.
Казан.
«Черек күл» паркы

80 нәшрият укучыларына бестселлерларны да, тиешсезгә игътибардан читтәрәк калган җәүһәрләрне дә тәкъдим итте. Алар арасында публицистик, фәнни-популяр, документаль һәм балалар өчен басмалар бар иде. Кунак булып килгән ил – Швеция. Казанга шулай ук Австрия, Польша һәм Америка әдәбиятчылары килде.

Фото: Алёна Кутыркина

ЧИТТӘН КАРАШ, ЯКИ КИТАПЛАРДА ЯШӘГӘН КЕШЕЛӘР

Нон-фикшн жанры элеккегечә мавыктыргыч һәм ымсындыргыч булып калуын дәвам итә. Бу сезонда берьюлы берничә нәшрият кызыклы яңа китаплар белән куандырды. Шуларның кайберләренә тукталып узыйк.

Автор:
Луиза Янсуар

«БУ – ҺӘРБЕРЕБЕЗ ӨЧЕН ДӘ КИСӘТҮ»
МИП ГИЗ, ЭЛИСОН ЛЕСЛИ ГОЛД. «ВОСПОМИНАНИЯ ОБ АННЕ ФРАНК. ИСТОРИЯ ЖЕНЩИНЫ, КОТОРАЯ ПОМОГЛА ПРЯТАТЬСЯ СЕМЬЕ ФРАНК».

«Эксмо» нәшриятының нон-фикшн жанрындагы китаплар сериясе өчен җаваплы «Бомбора» бастырып чыгарган Мип Гиз басмасы чын мәгънәсендә вакыйга буларак кабул ителергә тиеш. Тарихтагы реаль вакыйгаларга өстәмә күзлектән карарга мөмкинлек биргән бу китапның тәкъдим ителеше үк резонанс тудыруга корылган. Без барыбыз да Анна Франкның атаклы көндәлеген беләбез, „Убежище“-ны укымаган булса да, ишетми калган кеше юктыр, дип уйлыйм.

Китабында Мип Гиз безне үзләрендә Франклар гаиләсен яшереп саклаган оккупация көннәренә чакыра. Исеме бөтен дөньяга билгеле булган, Холокост корбаннары символын гәүдәләндергән кызчыкның истәлекләр маршруты буйлап атларга өнди.

Без бу тарихның икенче елъязмачысын тыңлый-тыңлый, детальләр дөньясына күмеләбез. Сүз уңаеннан, Анна Франк истәлекләрен теркәп барган җирән тышлы дәфтәрне дә кайчандыр кызның әтисе Отто Франкка сугыштан соң нәкъ менә Мип Гиз тапшырган була.

Мип Гиз Анна Франк истәлекләренә бик сак һәм кадерләп якын килә. Ул хәтта үзенең китабындагы персонажларны да кечкенә Анна атаган хәлдә калдыра. Китапның эпиграфы буларак та Анна Франк сүзләре

Фото: www.livelib.ru, www.goodfon.ru сайтларыннан алынды.

китерелә: «Как видишь, Мип никогда не забывает о нас, затворниках…» Бу сүзләрнең язылу датасы да теркәлгән: 1944 елның 8 мае. Ә 1945 елның мартында 15 яшендә бу тәвәккәл кыз инде якты дөнья белән хушлаша.

Бүген ул вакыйгаларның тере шаһитлары инде берсе дә исән түгел. Соңгы булып 2010 елда Мип Гиз якты дөнья белән хушлаша. Аның истәлекләрен китап рәвешенә китереп бастырып чыгаруны үз өстенә Элисон Лесли Голд ала. Китап ике авторлыкта басылып чыкты.

Мин каһарман түгел. Минем исемем ул елларда бичара яһүдләр өчен ни дә булса эшли алса, шуны эшләгән батыр йөрәкле голланд кешеләре исемлегенең иң азагында тора. Ул еллар хәтердән беркайчан да җуелмас. Ул чакларны кайта-кайта уйламаган бер генә көнем дә юк.

20 меңнән артык голланд кешесе яһүдләрне качырып сакларга булышты. Яһүдләрне генә түгел, ярдәмгә мохтаҗ һәркемне. Без ирем белән көчебездән килгәннең барысын да эшләдек.

Мин беркайчан да үземне ниндидер батырлык кылдым дип санамадым. Бу тарихны сөйләвемне үтенгәч тә, алай уйламыйм, дип кистереп әйттем. Әмма Анна Франк язмышының миллионлаган кеше өчен ничек әһәмиятле булуын да исәптә тотарга кирәк Ул язмыш берәүне дә битараф калдыра алмый. Һәр кичне җир шарындагы кайсы да булса театрда пәрдә күтәрелә, һәм Анналның күпсанлы телләргә тәрҗемә ителгән «Убежище» китабы буенча спектакль башлана, дип юкка гына әйтмиләрдер. Аның китабы – һәрберебез өчен дә кисәтү ул.

Мип Гиз китабында вакыйгалар хроник эзлеклелектә сурәтләнә. Ул детальләргә, тарихи полотнога зур игътибар бирә. Анна һәм аның гаиләсе белән башка яһүдләр «Убежище»га килеп эләккәнче булган хәлләрне Мип белән ире, әлбәттә, өлкән кешеләр буларак киңрәк, масштаблырак бәяләгән. Мип Гизның китабы шуңа да хроника буларак аеруча зур кыйммәткә ия, миңа калса.

Китап фактларга, даталарга, саннарга ифрат бай. 1940 елның көзе белән башланып китә ул. Мип Гиз беренче хәвефле сигналлар турында салкын канлы итеп, читтән карагандай сөйли. Ул хисләргә, рефлексиягә китапның буеннан-буена әллә ни урын калдырмый. Һәм бу стериль караш ноктасының артында никадәр кан-яшь торганлыгын ваемлаган хәлдә, бу кешеләргә карата булган ихтирамлы мөнәсәбәт тагын да көчәя. Үзләренә дә, аның позицияләренә дә: без бу турыда ачыктан-ачык, әмма дулкынланмый, хискә бирелмичә сөйләргә тиешбез, шул чакта гына хакыйкатькә күпмедер дәрәҗәдә якыная алабыз, дигән караштa тора алар. Объектив булырга тиешбез, дигән караштa. Ә бит дулкынлану җавапка янәдән психологик дулкын, хәтта ки хәвеф кенә тудырырга мөмкин… Бүгенге Европа киңлегендә барган тарихи хәлләр уйланырга мәҗбүр итмимени?

Сабыр гына, ашыкмыйча, Мип Гиз фашизм беренче адымнарын атлаган елларда Голландиядә барган эзәрлекләүләр тарихын торгыза. Ул адымнарның ничек ныгый баруын тасвирлый. Аның китабында тарих, бер йомарланып, кечкенә генә гаилә, кешеләр язмышына әверелә, бер, язылып, таралып, дөньякүләм масштабка омтыла.

Без барыбыз да үзебезне гадәти тотарга тырыштык. Әйтерсең, берни дә булмаган. Әмма акрынлап парклардагы эскәмияләрдә «яһүдләргә утырырга рөхсәт ителми» дигән язулар пәйда була башлады. 1941 елның 12 февралендә басылып чыккан нацистлар газетасында яһүдләр турында «алар – вампирлар, немец солдатларының кан тамырын тешләп өзеп, каннарын эчәләр» дип язылган иде. Без, моны укыгач, кычкырып торган ялганнан телсез калдык. Голландлылар тиз кабынучан халык түгел, әмма сабыр касәләре бер тулып ташыса, аларның ачуы чикне белми. 1941 елның 25 февралендә без яһүдләрне яклап забастовкага күтәрелдек. Бердәмлек хисен тоюдан да гаҗәебрәк хис юк икәнен аңладык.

Анна чып-чын экстраверт иде. Ул бөтен нәрсә турында да ачыктан-ачык сөйләшергә яратты. Яһүдләргә каршы кулланылган сәясәтнең дә гаделсез булуын курыкмыйча кычкырып әйтә белде 12 яшьлек бу кыз бала. Коточкыч вакыйгалар аны бик тиз үзгәртте – ул вакытыннан алда өлгерде, олыгайды.

ДОСТОЕВСКИЙ ҺӘМ ТОЛСТОЙ ӘСИРЕ
ЭЛИФ БАТУМАН. «БЕСЫ. ПРИКЛЮЧЕНИЯ РУССКОЙ ЛИТЕРАТУРЫ И ЛЮДЕЙ, КОТОРЫЕ ЕЕ ЧИТАЮТ», «ИДИОТ»

2018 елда рус классигы Федор Достоевскийга сылтама белән язылган «Идиот» романы өчен Пулитцер бүләгенә ия булган Элиф Батуман исеме тиз арада, яшен тизлегендә популярлашты. АСТ нәшрияты бүгенге көндә аның ике китабын рус теленә тәрҗемә итеп бастырып чыгарды.

Әлеге автор – чыгышы белән Төркиядән, Америкада яши. Журналистика һәм язучылык эше белән шөгыльләнә. Публицистикасы белән билгеле. Элиф Батуман – чагыштырма әдәбият белеме өлкәсендә белгеч, фән докторы, ул лекцияләр белән чыгыш ясый, әдәбият теориясе өлкәсендә хезмәтләр яза.

Үзе турында: «Достоевский һәм аның җеннәре әсирлегендә яшәрмен дип күз алдына да китермәгән идем, әмма шулай килеп чыкты», – дияргә ярата. Батуманның язмышы Россия һәм рус мәдәнияте белән тыгыз бәйләнгән, ул истәлекләрендә дә, китапларында да рус мохитендә яшәгән елларын яратып искә ала, аларны «бәхетле еллар» дип атый.

Ярый, азмы рус әдәбияты белән кызыксынучылар дияргә дә мөмкин. Әмма Элиф Батуман очрагында шуны да исәптә тотарга кирәктер: рус әдәбиятын, классик язучыларын яратучы һәркем дә Лев Толстойны кем үтергәнен ачыклар өчен Ясная Полянага чыгып китми. «Анна Каренина»ны идеаль мәхәббәт тарихы дип атаучылар да әллә никадәр табылмастыр.

Элиф Батуман әсәрләрендә рус әдәбиятының һәм мәдәни катламының ничек чагылуы – шактый четерекле һәм кызыклы күренеш. Авторның уйнак-җиңел ирониялә стиле исә аның китапларының популярлыгын билгели. Ә популяр китаплар аша укучы үзаңына күзаллаулар сеңә.

Кайчандыр бөтен дөнья һушсыз калып укыган Дэн Браун әсәрләре искә килеп төшә ирексездән. Анри Труайя китаплары. Читтән караш ноктасы, әлбәттә, мәдәниятнең эчендәге барлык агымнарны тоеп язу эффектын бирми. Әмма ул шуңа күрә кызыклы да: ул караш яссылыгында башка күтелмәгән яклар ачылып китә, Россия вакуумыннан тыш процесслар кайбер нәрсәләрне яхшырак аңларга, анализларга мөмкинлек бирә.

Кайбер руслар чит илдән килүчеләр аларның мәдәнияте, бигрәк тә әдәбияты белән кызыксынса, скептик караш белән каршылый. Өнәп бетерми. Паспорт контролендә беренче студент визама мөһер куйган офицерны һич онытасым юк. Ул миңа болай дигән иде: «Америкада да бар бит язучылар, мәсәлән, Джек Лондон. Тел белән дә җәфаланасыгыз булмас иде, аны өйрәнсәгез, виза артыннан йөреп тә...»

Элиф Батуман рус телен һәм әдәбиятын гомерлеккә сузылган мәхәббәте дип кат-кат ассызыклый. Бу аның тормышындагы (һәрхәлдә, романнарындагы) беренче мәхәббәт белән дә кисешә. Әнә шуңа да ул Американың престижлы университетларының берсенә килеп, үз милли әдәбияты тарихы, Көнбатыш культурасы белән генә чикләнеп калмый, ә бөтенләй ят булган рус дөньясын үзләштерүне максат итеп куя.

«Идиот» романы төрек кызының Америкага килеп, рус мәдәниятен үзләштерә башлавы, беренче мәхәббәтен очратуы, беренче кыенлыклар белән маңгайга-маңгай бәрелүе турында. Колачлырак итеп алсак, яшь кешенең олы тормышка аяк атлап, үз сукмагын эзләвенә багышланган ул. Ә менә «Бесы» – үз урынын тапкан авторның ирониялерятулы җитлеккән караш ноктасы. Гәрчә иртәрәк язылса да. Биредә Элиф Батуман әдәбият белгече буларак сүз алып бара, шуңа да аның теле, стиле күпмедер дәрәҗәдә нейтральлеккә тартыла.

Ә нигездә, аның теле һәм стиле шактый күпләрнең ачуын китерә, кемнәрнедер аңа җитди караманска да этәрә. Әмма онытмаска кирәк: нон-фикшн стильләр синтезына йөз тота, фрагментарлыкны табигый күрә. Шуңа шәхсән мине әле генә Пушкин, Толстой, Чехов турында гадәти танышлары турында сөйләгәндәй язган, ә икенче бер мизгелдә Әнкарадагы өйләре, музыка укытучысы, югалткан чемоданы турында бәян итәргә керешкән Батуман гаҗәпләндерми. Киресенчә, елмайта, кәефемне күтәрә. Ул ике тоташтырып булмый торган чикне – фәннилекне һәм популяр жанрларга хас булган җиңеллекне берләштерергә омтыла.

Рус дөньясы да, әдәбияты да – экзотика. Психологик каршылыклары, мантыйгы, дөресрәге, Көнбатыш өчен аңлавы кыен булган мантыйксызлыгы белән. Әмма Элиф Батуман интуитив тоемлау белән ул мантыйкка күмелә, аны ваемлый. Бәлки, Көнчыгыш тоемлавына ул килешәрәктер. Күпсанлы япон язучылары, шул исәптән, бүгенгеләре, әйтик, Мураками да, Достоевский белән Толстойның үзенә ничек көчле тәэсир ясавы турында кабат-кабат юкка гына сөйләмидер, бәлки...

– Сез минем иң талантлы һәм әкәмәт студентларымның берсе, – дип шаркылдап көлде курс җитәкчем, мин аңа теориямне сөйләп биргәч. – Димәк, сезнеңчә Толстойны үтергәннәр? Ха-ха-ха! Аңа бит 82 яшь була үлгәндә, әкият сөйләмәгез, ул яшьтә кеше белән нәрсә килеп чыкмас!

– Нәкъ менә шуңа да аның үлеме – тарихтагы идеаль үтерү очракларның берсе, – дип, үз сүземдә торуымны дәвам иттем мин.

Әмма аны ышандырып булмады. Шулай да Ясная Полянага доклад белән очарга рөхсәт алынды.

Биредә кием кибете булмаганлыктан, конференциянең дүрт көнендә дә нәрсә киеп килсәм, шул киемнән йөрергә туры килде: шлепанцы, спорт чалбары, фланель күлмәк. Конференциягә җыелган Толстой темасын өйрәнүчеләрнең кайберләре миңа аеруча зур ихтирам белән карый башлады. Алар минем өс-башымны Толстой идеяләренә тулаем тәңгәл дип тапты: бөек рус классигы да атналар, айлар буе сандали белән крестьян күлмәгеннән йөргән ләбаса. Минем бөек әдипкә тугрылыгым бирәүдә дә шик калдырмады...

Элиф Батуман романнарын тәнкыйтьчеләр, нигездә, тирәнгә кереп үзләштерүне максат итеп куймыйча, постмодернистик уен алып баруда гаепли. Фактлар, вакыйгалар, дискурслар белән жонглерлыкта. Әмма Батуман моны үзе дә таный. Ул әдәби-тарихи тулыканлылыкка дәгъва итми, ә нәкъ менә җиңеллекне, ирониялә якын килүне өстен күрә.

Укып чыкканнан соң, тагын бер нәрсәгә төшенәсең: асылда, бу китаплар аша Төркия–Америка–Россия җепләрен тоташтырырга тырышкан автор бүгенге фән дөньясына, әдәбиятка чикле караш формалаштырган академик системага да кизәнә. Әмма кискен итеп түгел, ә көлемсерәп. Аек акыл, салкын канлылык, тик яратулы җылылык белән.

Без инде объективлык, аек акыллылык белән хисләрне берләштерә алырга өйрәнеп килəбез, димәк.

МАХСУС ПРОЕКТ

— 44нче чыгарылыш —

Татарстан юбилярлары

Ришат Әбүбәкеров,
VI чакырылыш Россия Дәүләт Думасы депутаты, июльдә үзенең 60 яшьлек юбилеен билгеләп үтә.

Туган төбәкнең иминлеге хакына

Мәҗит Салихов,
«ТР ДЭБИ» ДАУ башлыгы

– Хөрмәтле Ришат Фазлытдинович! 60 яшьлек юбилеегыз уңаеннан Сезгә иң ихлас теләкләремне җиткерергә, тәбрикләргә рөхсәт итегез.

Бер гыйбарәдән башлар идем сүземне: «Тормыш авырлыклары һәркемгә төрлечә тәэсир итә: көчлеләрне – сөендерә, ә көчсезләрнең ачуын китерә». Сез, һичшиксез, көчлеләр сафына карыйсыз. Сезнең рухыгыз нык, үзегез эшлекле, максатчан, һәрвакыт – көр күңелле.

Сезнең кебек чын профессионал белән бер командада эшләү – зур горурлык. Сез – бөтен тормышын Әлмәт районына багышлаган зат. Ә бу район республикабызда җир мәйданы буенча гына иң эре районнарның берсе генә түгел, икътисадый куәте буенча да – алдынгылар рәтендә. Сез – үз эшен яхшы белгән җитәкчеләрдән, шуңа да иң катлаулы бурычларны хәл итәргә алынырга курыкмыйсыз. Әлмәт районы һәм Әлмәт шәһәре администрациясе башлыгы, Әлмәт муниципаль берәмлеге башлыгы, Әлмәт муниципаль районы Советы рәисе, «Әлмәт шәһәре» муниципаль берәмлеге Советы рәисе – мондый җаваплы вазыйфалар кешегә очраклы гына йөкләнми, аларга олы хезмәт юлы үтеп, чын профессионал булып кына килеп була.

Сез 10 елдан артык муниципаль районны җитәкләдегез, аның социаль һәм икътисадый үсеше өчен искиткеч зур көч куйдыгыз. Сезнең җитәкчелектә сәламәтлек саклау, мәгариф, мәдәният, спорт буенча күп кенә программалар эшләнде һәм уңышлы рәвештә тормышка ашырылды. Торак-коммуналь комплексны яңарту һәм реформалаштыру буенча проектлар да зур игътибарга лаек. Юл инфраструктурасын, социаль-мәдәни билгеләнештәге объектларны реконструкцияләү һәм төзү-төзекләндерү, Әлмәт урамнарын белән ишегалларын тәртипкә китерү – Сез боларга да гаять зур әһәмият бирдегез.

Сез яраткан шәһәрегез өчен чын мәгънәсендә янып-көеп яшәүче зат. Әлмәтлеләрнең яшәү шартлары уңайлы булсын өчен искиткеч тырыштыгыз. Шуңа да Әлмәт бүген республикадагы иң күркәм калаларның берсе. Сез алып барган актив җәмәгать һәм хәйрия эшчәнлеген дә искә алмый булмый, Сез республика халкыннан рәхмәт сүзләрен еш ишетәсез.

Юбилей көннәрендә Сезгә күтәренке кәеф, тормышыгызның якты, күңелле вакыйгаларга, бәхетле мизгелләргә бай булуын телим. Сезнең үзегез өчен дә, якыннарыгыз өчен дә кадерле бу датаны сәламәт рух белән каршылагыз. Башлаган эшләрегезне актив рәвештә тормышка ашырып, аларның нәтиҗәсен, бәрәкәтен күреп, озын-озак еллар яшәргә насыйп булсын. Уңыш Сезгә һәрчак елмаеп, ә теләкләрегез тормышка ашып торсын!

Реклама

Фото «ТР ДЭБИ» ДАУ архивыннан

Радик Гайзатуллин, ТР финанслар министры, июль аенда үзенең 55 яшьлек юбилеен билгеләп үтә.

Заманча Татарстан турындагы хыялларыгыз чынга ашсын!

Айдар Метшин,
Түбән Кама муниципаль районы башлыгы,
Түбән Кама шәһәре мэры

– Хөрмәтле Радик Рәүфович!

Сезне 55 яшьлек юбилеегыз белән чын күңелдән тәбрик итәм! Бу тантаналы һәм шатлыклы көндә Сезгә ныклы сәламәтлек, иҗади һәм рухи күтәренкелек, киләчәктә дә эшләрегезнең уң булуын телим.

Сезне максатчан һәм гаҗәеп күркәм сыйфатларга ия зат буларак беләм. Тынгысыз эшчәнлегегез Татарстанда гына түгел, ә Россия һәм чит илләрдәге икътисадый мохиттә дә яхшы билгеле. Сезне ихтирам итәләр, югары бәялиләр.

Ватан алдындагы бурычыгызны Сез күп еллар дәвамында намус белән, менә дигән итеп башкарасыз. Бу бәрәкәтле эшкә, кызганмыйча, бар көчегезне, сәләтегезне, тәҗрибәгезне, иҗади энергиягезне багышлыйсыз. Сезнең принципиаль һәм һәрчак тәгаенләнгән үз позициягез бар, шул ук вакытта Сез акыллы, үтемле компромиссларга әзер кеше. Республиканың икътисадый сәясәтен алып барудагы зирәклегегез күпсанлы башка җитәкчеләр өчен дә гражданлык бурычына тугрылык үрнәге булып тора.

Җитди һәм җаваплы вазыйфагыз Сезнең алга гаять югары таләпләр куя, аларга яраша белү – зур осталык. Сез барлык авырлыкларны да җиңеп чыгарга сәләтле, чөнки эш сөючән, максатчан һәм тәвәккәл кешене берни дә туктата алмый. Безнең үзара ышанычка, эшлекле һәм конструктив аралашуга корылган хезмәттәшлекне мин бик югары бәялим. Түбән Кама муниципаль районында килеп туган мәсьәләләргә, проблемаларга һәрчак игътибарлы булуыгыз өчен рәхмәтемне җиткерәм. Алга таба да безнең эшчәнлекне, инициативаларны шулай күтәреп алсагыз иде, бергә-бергә эшләргә насыйп булсын.

Сездә булган искиткеч эшлекле һәм кешелекле сыйфатлар киләчәктә дә туган республикабыз һәм Россия бәрәкәте өчен хезмәт итсен. Заманча Татарстан турындагы хыялларыгыз уңышлы рәвештә чынга ашсын! Бар эшләрегездә уңыш насыйп булсын! Югары нәтиҗәләргә сөенеп яшәгез!

Фото: Түбән Кама муниципаль районы матбугат хезмәтеннән алынды

Виктор Смыков, «Татнефть» ГАҖ нең «Ямашнефть» нефть һәм газ табу идарәсе башлыгы, июль аенда үзенең 70 яшьлек юбилеен билгеләп үтә.

Бөтен тармак өчен дә үрнәк

Марат Насыйбуллин, «КАРА АЛТЫН» предприятиесе» ЯАҖ генераль директоры

– Хөрмәтле Виктор Васильевич! «КАРА АЛТЫН» предприятиесе» ЯАҖ коллективы исеменнән һәм шәхсән үз исемемнән Сезне бу түгәрәк дата – 70 яшьлек юбилеегыз белән котлыйм.

Юбилей – Сезгә булган ихлас теләкләрне һәм рәхмәтләрне җиткерү өчен чираттагы бер яхшы уңай форсат. Иманым камил, бу көндә Сезнең тарафка искиткеч күп җылы сүзләр явадыр: күпьеллык җаваплы, җитди хезмәтегез өчен рәхмәтләр дә, Татарстан нефть сәнәгатен үстерүгә керткән искиткеч зур өлешегез өчен соклану да, өстәвенә, депутат эшчәнлеген алып барырга өлгергәнегез өчен ихтирам да.

Теге яки бу өлкәдә, һөнәрдә чын мәгънәсендә үз эшенең остасы булган затлар еш очрамый. Әмма мондый затларның хезмәте шул дәрәҗәдә олы була ки, абруйлары бөтен тармак өчен чын мәгънәсендә локомотивка әверелә – җитештерүне дә, фәнне дә, икътисадны да алга этәрә. Сез, Виктор Васильевич, һичшиксез, шундый затларның берсе – нефть һәм газ сәнәгате өлкәсендәге яшь белгечләр өчен үрнәк тә, ориентир да.

Нефть өлкәсендә чын танылуны бары тик аның үзәгендә кайнаган, «кара алтын» чыккан урыннан – авыр хезмәттән башлаганнар гына яуларга мөмкин. Алдынгы фикер йөртү сәләте, тырышып уку һәм эшлеклелек, тармакны гына түгел, ә аңа бәйле барлык социаль мохитне дә үстерергә кирәклеген тирәннән аңлап эш итү Сезгә зур уңышларга ирешергә ярдәм итә.

Актив иҗтимагый позиция, спортка мәхәббәт һәм сәламәт тормыш рәвеше – боларны алга сөреп, Сез Әлмәт районы гражданнары тормышын яхшыртуга зур этәргеч ясадыгыз. Бу өстенлекле эш юнәлешләрегез исемлегендә һәрчак иң яхшы кешелеклелек сыйфатлары һәм гамәлләре генә беренче урында торуы турында сөйли.

Сезнең кебек масштаблы шәхесләр һәрчак соклану уята. Нинди генә эшкә алынсагыз да, уңышка ирешәсез. Саекмас тормыш энергиягез ирешкән нәтиҗәләрдә генә тукталып калмаска өнди, Сезне гел алга әйди. Шуңа да Сез эш һәм бурыч турында беркайчан да онытмыйсыз, тынгысыз рәвештә алга атлыйсыз.

Илһам һәм уңыш һәрчак янәшә атласын, бар ниятләрегез тормышка ашсын! Һәр яңа туган көнегез бәхетле мизгелләрдән үрелсен! Сәламәтлек, иминлек юлдаш булсын, тирәгездә гармония хөкем сөрсен!

Фото «КАРА АЛТЫН» предприятиесе» ЯАҖ нән алынды

ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ БАСМА

ТАТАРСТАН

TATARSTAN

facebook.com/protatarstan

twitter.com/protatarstan

БЕЗНЕҢ ТӨРКЕМНӘРГӘ РӘХИМ ИТЕГЕЗ!

instagram.com/protatarstan

Реклама 16+

Рафаил Нурмөхәммәтов, «Лениногорскнефть» НГТИ башлыгы, «Татнефть» ГАҖ директорлар советы әгъзасы, августта үзенең 70 яшьлек юбилеен билгеләп үтә.

Рөстәм Хөснетдинов,
«Охтин Ойл» ЯАҖ
генераль директоры

Атказанган нефтьче һәм ихтирамга лаек шәхес

– Хөрмәтле Рафаил Сәетович, юбилей көнегездә күпсанлы җылы сүзләргә һәм котлауларга кушылырга рөхсәт итегез!

Безнең бөек илебезнең нефть тармагында эшләү Сезнең гомерлек хезмәтегезгә һәм язмышыгызга әверелә. Белем алу юнәлешен сайлаганда ук Сез, үзегезнең киләчәкне билгеләп, нефтьче булу кебек авыр һәм кызыклы һөнәрне сайлагансыз.

Сезнең кебек уңышка ирешкән һәм абруй яулаган кешеләр профессия үзләштерүне һәрвакыт нигезеннән башлыйлар. Татарстанда, аннан читтәрәк урнашкан берничә билгеле нефть табу идарәләрендә эшләп, Сез тәҗрибә туплыйсыз, күнекмәләрне чарлыйсыз. Тырышлык, җаваплылык һәм нәтиҗәсе күренгән фидакарь хезмәт Сезгә хезмәт баскычы буйлап үсәргә булыша, Россия нефть тармагын үстерүдә турыдан-туры катнашырга мөмкинлек тудыра.

Җитәкче урынга билгеләү – ул һәрвакыт шәхесне һөнәри яктан гына түгел, кешелеклелек ягыннан да сынау. Сез, Рафаил Сәетович, әлеге сынауны бик җиңел узасыз. Сез җитәкләгән коллективлар, һичшиксез, уңышка ирешәләр һәм бердәмлек, энтузиазм үрнәге булып торалар. Озак еллар Сез «Лениногорскнефть» НГТИ башлыгы сыйфатында алдыгызда торган бурычларны уңышлы хәл итеп киләсез, үз хезмәтегез һәм эшкә мөнәсәбәтегез белән хезмәткәрләрегез һәм коллегаларыгыз арасындагы абруегызны арттыра барасыз.

Сезнең хезмәтегез Татарстан Республикасының атказанган нефтьчесе исеме бирелү, Халыклар дуслыгы һәм «Почёт билгесе» орденнары тапшырылу кебек дәүләт бүләкләре белән лаеклы рәвештә билгеләп үтелә. Сез керткән хезмәт нәтиҗәсендә Лениногорск районында һәм республикада нефть тармагы актив үсеш кичерә һәм чәчәк ата.

«Охтин Ойл» ЯАҖ коллективы исеменнән һәм шәхсән үз исемемнән Сезгә ихлас күңелдән һөнәри эшчәнлегегездә уңышлар, шәхси тормышыгызда гармония һәм бәхет телим. Һәр кылган гамәлегез Сезгә канәгатьлек, тотрыклылык һәм иртәгәге көнгә ышаныч китерсен! Актив озын гомер, сәламәтлек һәм иминлек юлдаш булсын!

Фотолар «Охтин Ойл» ЯАҖнән алынды.
Реклама

Игорь Рассман, «Татарстан. XXI гасыр җитәкчеләре» Илебез менеджментын үстерергә ярдәм итү фонды директоры, ТР Предприятиеләр һәм сәнәгатьчеләр ассоциациясе генераль директоры урынбасары, июльдә үзенең 70 яшьлек юбилеен билгеләп үтә.

Виллен Балоев,
«Гамәли оптика дәүләт институты» ФҖБ» АҖ генераль директоры

Хөрмәтле Игорь Олегович!

Берләшмәбез коллективы исеменнән һәм шәхсән үз исемемнән Сезне юбилеегыз белән котлыйм!

Эшлекле кешеләр, ә Сез, һичшиксез, алар арасына керәсез, күренекле даталарны билгеләп үткәндә, узган юлларына бәя биреп кенә калмыйча, киләчәккә планнар да коралар.

Әлеге уй-нияләрегезне тормышка ашыруда уңышлар юлдаш булсын!

Сезгә хас актив тормыш позициясе һәм җаваплылык, кешеләрнең һәм коллективларның омтылышын куелган бурычларны үтәрлек итеп туплый белү сәләте оборона-сәнәгать предприятиеләрендә эшләвегез дәверендә уңышларыгызның нигезе булды. Соңрак Татарстан предприятиеләре һәм эшкуарлары ассоциациясендә хезмәт куйганда – эшчәнлегегез республикабыз тормышының барлык якларына кагылганда да бу шулай булып калды.

Предприятиеләрнең республика Хөкүмәте, муниципалитетлар, профсоюзлар һәм башка структуралар белән күпьяклы диалогының иң кискен мизгелләрендә Сез, уйланылган һәм үлчәнелгән позициядә торып, һәрвакыт нәтиҗәлелеккә ирешү юлына басасыз.

Игорь Олегович! Сезгә һәрвакыт якыннарыгызның йөрәк җылысын тоеп яшәргә язсын, дусларыгызның һәм хезмәттәшләрегезнең хуплавы юлдаш булсын!

Сезгә ихлас күңелдән ныклы сәламәтлек һәм иминлек телим!

Фото «Гамәли оптика дәүләт институты» ФҖБ» АҖ матбугат хезмәтеннән алынды.

ЯНӘШӘБЕЗДӘГЕЛӘР ҺӘМ ЯКЫНДАГЫЛАР ТУРЫНДА

ТАТАРСТАН TATARSTAN

ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ БАСМА

Реклама бүлеге:

тел: (843) 222-09-76,

8-9272-483-384

e-mail: 89272483384_pr@mail.ru

Владимир Гинсбург, «Казан электротехника заводы» АҖ генераль директоры, августта үзенең 65 яшьлек юбилеен билгеләп үтә.

Ронис Шәрипов,
«Радиотехника» ФҖБ»
АҖ генераль директоры

Айрат Хөснетдинов,
«Радиоприбор»
АҖ башкарма директоры

Нәсих Хәйдәров,
«Радиоприбор» Әлмәт
заводы» АҖ башкарма
директоры

Тормыш принцибы буларак югары профессиональлек

– Хөрмәтле Владимир Сергеевич, Сезне үзебезнең исемнән һәм коллективларыбыз исеменнән юбилеегыз белән тәбрикләргә рөхсәт итегез!

Хезмәт биографиягезне ремонтлаучы слесарь ярдәмчесе вазыйфасыннан башлап, җитештерүне нигезеннән үк өйрәнеп, тырыш хезмәт һәм зирәк акылыгыз нәтиҗәсендә Сез үзегезнең беренче һөнәри күнекмәләрегезне аласыз. Табигый сәләтегез һәм талантыгызга таянып, тиздән үз эшегезне табып, Казан электротехника заводында хезмәт куя башлыйсыз. Куәтле, әмма кайбер проблемалары булган заводның потенциал күреп, Сез техник-технологтан предприятиенең генераль директоры вазыйфасына кадәр булган үсеш баскычын уңышлы үтәсез.

Һөнәри яктан камилләшә барып, Сез институтта укуыгызны заводта эшләү белән бергә алып барасыз. Алдынгы технологияләрне үзләштерә бару омтылышы хезмәт юлыгызда һәрвакыт янәшә атлый. Шул рәвешле Сез еллар дәвамында сыналган җитештерү куәтләрен инновацияле эшләнмәләр белән бәйләүгә ирешәсез. Сезнең актив тормыш позициягез шулай ук зур роль уйный. Ул Сезнең күпләгән коллегаларыгыз һәм фикердәшләрегез өчен үрнәк һәм үсеш ноктасы булып тора. Нинди генә коллективта пәйда булсагыз да, Сездәге харизма һәм энергия кешеләрне үзенә җәлеп итә. Ачыктан-ачык күренеп торган лидерлык сыйфатларына, тирән тәҗрибәгә һәм һөнәри белемнәргә ия кеше хөрмәт, ышаныч һәм бергә хезмәттәшлек итү теләге уята, кызыклы заказларны гамәлгә ашырырга рухландыра.

Сез шулай ук шәп стратегик фикерләү сәләтенә ия, нәкъ менә Сезнең хезмәтегез нәтиҗәсендә Казан электротехника заводы Россиянең радиоэлектроника базарында ышанычлы позицияләр яулап алды. Шул ук вакытта Сез кыйммәтле кадрларны саклап кала, хезмәткәрләрне рухландыра, аларны киң колачлы һәм җаваплы заказларны бергә башкару максатына туплый аласыз.

Сез җитәкләгән предприятиегә оборона сәнәгате проектларын ышанып тапшыралар. Дөньякүләм дәрәҗәдәге вакыйгаларны техника белән тәэмин итеп, туган шәһәребез иминлеге хакына хезмәт куясыз. «Сакчыл җитештерү» программагыз – 77 еллык тарихы булган предприятиенең инновацияле үсеш өлкәсендә күрсәткән лаеклы үрнәге.

Бер сүз белән әйткәндә, Сез җитәкчелек иткән Казан электротехника заводы Россиядәге производстволарның заманча үсешендә актив катнаша. Һәм без, Владимир Сергеевич, Сезнең кебек югары һөнәрмәндлеккә ия, алдан күреп эш итә белүче партнерыбыз һәм коллегабыз булуы белән горурланабыз!

Сезгә актив озын гомер, куелган максатларыгызга һәм яңадан-яңа җиңүләргә ирешүегезне телибез! Гаилә бәхете, имин-мул тормыш, үзегезгә һәм якыннарыгызга ныклы сәламәтлек юлдаш булсын!

Фотолар «Шимко исемендәге «Радиоэлектроника» ФҖБ» АҖ матбугат хезмәтеннән алынды.
Реклама

КОЕЛЫ КИШЕР АКСУЫ

Аксу авылының даны еракларга таралган. Биредә күпләп кишер, суган, чөгендер үстереп саталар. Сезон алар өчен июльнең беренче яртысында башлана. Ягъни нәкъ менә шушы чорда беренче уңышны җыеп, сатуга чыгаралар. Җирле халык әйтүенчә, тирә-як авыллар кишер үстерергә нәкъ менә Аксудан өйрәнгән. Шушы үзенчәлекле, тырыш авылны күрергә теләп, Буа районына юл алдык.

Автор:
Руфия Фазылова

СУ КИРӘКМЕ, ЮКМЫ?

Җирле халык теләндә авылның атамасы «Кишер Аксуы» дип йөртелә. Дөрес, бүген аның исеме җисеменә бик үк туры килеп бетми. Биредә, элеккеге кебек, өчәр бакча кишер утырту беткән. Моның сәбәбен алга таба язармын.

Аксуда ун ел элек булган идем. Ул вакытта анда яшәүче тырыш кешеләргә һәм саланың юлсыз урамнарына гаҗәпләндем. Бу килүемдә исә авыл эчендә машина белән рәхәтләнеп йөрдек. Чокыр-чакырлы урамнарга таш түшәлгән, асфальт салынган урыннары да бар.

– Ниһаять, авыл эчендә дә туфли белән йөрергә була икән, – дидем Аксу авыл җирлеге башлыгы Марат Хәйретдиновка.

– Әйе, юлларны карадык, – диде тыйнак кына җитәкче. – Үзсалым акчасына да, республика программасы кысаларында да юлларга вак таш, асфальт түшәлде. Хәзер менә «Чиста су» федераль программасы белән су линияләре үткәрергә йөрибез.

– Яңа су торбалары сузасызмы? – дим.

– Беренче линия. Безнең авылга әлегә кадәр су кермәгән иде.

–?! – гаҗәпләнүемнең чиге юк.

Бактың исә, аксулылар шушы көнгә кадәр суны коедан алган. Һәр кешенең ихатасында бар ул. Аерма бары шунда гына: берәүләрнең коесы 8 метр тирәнлектә, икенчеләр 20 метрга кадәр казыган. Авылга су кермәгәнен ишетеп бер гаҗәпләнсәм, аны кертергә дә теләмәүчеләр барын ишетеп, икенче гаҗәпләндем.

Фото: Лилиана Вәлитова

Аксулылар шушы көнгә кадәр суны коедан алган. Һәр кешенең ихатасында бар ул.

Бу бит өч кенә йортлы, кечкенә авыл түгел. Аксуда 302 хуҗалык бар, 620 кеше яши. Һәм – сусыз! Хәер, аңа карап, алар заманнан артта калмаганнар. Автомат кер юу машиналары да бар, бәдрәфләре дә өйдә. Суны коедан махсус зур савытларга суыртып куялар икән. Шуның өчен «Чиста су» программасы ярдәмендә су торбалары сузуга бик исләре китми. Моның сәбәбен үзләренчә аңлаттылар:

– Су керткән өчен акча түлисе, тагын әле квартал саен түләп торырга кирәк икән, – диделәр.

– Коедан су суыртып азапланасыгыз булмый. Су өчен түләү дә бер кварталга кеше башыннан 150 сумнан артмый инде. Дәүләт программасы бит, өйгә су кертү зур суммага чыкмас, – дим, тынычландырырга тырышып.

Гомер буе Аксу урта мәктәбендә химия, биология укыткан мөгаллимә Мөнзилә апа Минһаҗева да өенә су кертү яклы түгел икән. «Агарту» эшләре алып баргач:

– Уйлап карармын, – диде.

Мөнзилә апа туган нигезендә яши, тормышка чыкмаган. Бөтен гомерен яраткан эшенә – балалар укытуга багышлаган.

– Аксу мәктәбендә 1965 елда эшли башладым, – диде ул. – Бер төркем яшь укытучылар идек. Ул вакытта мәктәбебез җидееллык булса да, 360 бала укыды. 1984 елда унъеллык мәктәп булып ачылды. Ул вакытта әле Аксу гөрләп тора иде. Авылның бүгенге халәтен мәктәптә укучы балалар саны күрсәтә: унбер класска 67 укучы бар.

Мөнзилә апа, лаеклы ялга чыккач та, шактый еллар эшләгән. Бүген дин юлына баскан. Яшьләр, олылар өчен дә киңәшче, остаз ул.

– Бергә эшләгән коллегалар белән аралашып яшибез. Мәктәпкә дә еш чакыралар, – диде Аксуның ихтирамга лаек өлкән мөгаллимәсе.

– Бергә эшләгән коллегалар белән аралашып яшибез. Мәктәпкә дә еш чакыралар, – диде Аксуның ихтирамга лаек өлкән мөгаллимәсе Мөнзилә апа Минһаҗева.



– Элеккеге кебек дүртәр бакча кишер утыртмыйбыз шул хәзер, – диде Люция апа Зиннәтуллина.

ШӘРӘФЛӘР БҮЛӘГЕ

Аксу халкы кишерне 1900 нче еллардан бирле үстерә. Мәгърифәтче, сәясәтче, бертуган Шәрәфләр (биш кыз, биш ир туган) – тумышлары белән Аксу авылыннан. Алар туган авылларына күп яңалык алып килгән. Шуның иң зурысы: кишер үстерергә өйрәткәннәр.

– Эх, аларны совет хакимияте юк итмәгән булса, безнең авыл «Аксуград» буласы иде, – диде бер авыл агае.

Менә шушы атаклы нәселнең бер улы туган ягына Әстерханнан кишер орлыгы алып кайта. Кызылсары төстәге, озынча формадагы бу татлы яшелчә җирле халыкта зур кызыксыну уята. Орлыгын күз карасыдай саклап, җиренә җиткереп утырталар. Санаулы вакыт эчендә Аксудагы һәр йортта диярлек кишер үстерә башлыйлар. Тирә-як авыллардан да бу яшелчәне сорап килоләр. «Кишер Аксуы» дигән атама нәкъ менә шул елларда барлыкка килә дә.

Аксуның атаклы кишер үстерүчесе Люция апа Зиннәтуллина белән дә танышып чыктык. Күп еллар фермада сыер сауган ул, бүген лаеклы ялда.

– И, наным, элеккеге кебек дүртәр бакча утыртмыйбыз шул хәзер, – диде Люция апа.

– Ә ник алай? – дим.

– Беренчедән, эшләргә кеше юк, балалар читкә китеп бетте. Икенчедән, аның файдасы да юк. Июль аенда да кишернең килосын 12–15 сумнан җыялар иде. Көзгә ул 5–7 сумга төшеп бетә. Азапланып йөргән бае да юк. Хәзер ике бакчага печән чәчтек, бер-

сен кешегә бирдек. Аның кадәр җир белән нәрсә эшлим...

Аксу бакчалары бүтән авылларныкыннан аерыла. Биредә күрше бакчасы каян башлана да, хуҗаныкы – каян, аңламассың. Барысы да тоташкан, ике арада рәшәткә дә, киртә дә юк. Тагын бер үзенчәлек – һәр яшелчә буйдан-буйга, түтәл итеп утыртылган. Мисал өчен, өч озын түтәл кызыл чөгендер, биш түтәл кишер, ике түтәл суган, аннан бәрәңге.

– Уңыш өлгерде инде, – дип, Люция апа түтәлдән өч кишер йолкып алды. – Бу атнада җыялар, дип әйттеләр, берничә капчык әзерлисе булыр инде.

– Ә кемнәр җыя? – дим.

– Үзебезнең авыл егетләре. Аларның йөк машиналары бар, шулай халыктан җыеп, Казанга илтәләр.

Әлегә (без июль башында бардык) кишернең килосы 25 сум. Августка таба бәя төшә икән.

– Алайса кишерне хәзер урнаштырып бетерү отышлырактыр, – дим.

– Алай дип әйтеп булмый, – ди Люция апа. – Июль башына бары тик түтәл кырыенда үскән кишерләр генә өлгерә. Шулай бер кат йолкып чыкканнан соң, кайбер елны сабаклары саргая, бүтән үсми дә. Һәм тагын: әле бит кишерләр зур түгел. Бер кило булсын өчен, биш-алтыны йолкырга кирәк, ә көзгә аның өчесе бер кило була.

Люция апа орлыкны үзе әзерли. Яз көне зур кишерне җиргә күмә дә, көзгә орлыкларны җыеп ала, аннары киптерә. Шуннан кул белән уып, сабакларын җилдә очыра.

Кишерне биредә кар бетүгә чәчәләр. Мисал өчен, быел апрельнең 15е булган ул. Тагын бер үзенчәлек: аксулылар орлыкны авыз белән чәчә. Башта түтәлләрне ясап, сызып куялар да, хатын-кызлар орлыкны кашык белән авызларына алып, җиргә өрә.

– Бездә балалар да кишер утырта белә. Аксудан киткән яшь киленнәр хәзер үзләре әлеге шушы юл белән кишер утырта, – ди Люция апа.

Аксуда дистәгә якын фермер бар. Аларның барысы да диярлек үсемлекчелек белән шөгыльләнә. Шул исәптән кишер, кызыл чөгендер үстерәләр. Аксу авыл җирлеге башлыгы Марат Хәйретдинов белән кырларны урап чыктык. Әкәмәт: кая карасаң да, кишер басулары җәелеп ята. Ләкин алардагы кишер әле шәхси хуҗалыкларныкы кебек сатуга чыгарырлык зур үсмәгән.

– Фермерлар кишерне соң чәчә, шуңа күрә татлы тамыр азыклары көзгә генә өлгерә, – диде Марат Хәйретдинов.

Аксуда дистәгә якын фермер бар. Аларның барысы да диярлек үсемлекчелек белән шөгыльләнә. Шул исәптән кишер, кызыл чөгендер үстерәләр.

«КӨРӘШЕП ЯШӘРГӘ ЯЗГАН...»

Аксуда яшәүче Хәмзә Зиннәтуллинны тирә-як районнарда да беләләр. Имәннән җиһазлар ясау остасы ул.

– Мәрхүм әтием Сәлах гомере буе балта остасы булды, – дип, үзе белән таныштырды Хәмзә абый. –Авылыбызда аның кулы тимәгән өйләр юктыр да. Бу сәләт миңа да күчкән дип уйлыйм. Кечкенәдән аның кул арасына кереп, агачтан җиһаз ясау серләренә өйрәндем. Ун яшемдә урындыклар ясап, шуларны сата идем. Аннан тәрәзә рамнары, йорт өчен кирәкярак ясый башладым. Яраткан һөнәрем буенча үсәргә теләп, Казан төзелеш техникумына укырга кердем.

Кулына диплом алгач, Хәмзә абый туган ягына әйләнеп кайта. Колхозда прораб вазыйфасын башкара. Гаилә кора. Бер-бер артлы өч баласы туа. Эштән бушаган арада тәрәзә рамнары ясап, гаилә бюджетына аз булса да өстәмә акча кертә. СССР таркалгач, тормышы бөтенләй икенче юлдан китә.

– Колхоз таралгач, эшсез калдым, – ди әңгәмәдәшем. – Нишләргә? Озак уйламадым, агач эшенә ныклап тотынырга булдым. Тик 1990 нчы елларның нинди авыр икәнен күпләр хәтерлидер. Әле үз эшеңне ачу дигән әйбер ят нәрсә. Хәтта утка рөхсәт бирмичә, гел өзеп аптыраттылар. «ИП» ачтырмый интектерделәр. Тик шулай да кул селтәмәдем. Буа районында шәхси эшмәкәр булып теркәлгән кешеләрнең берсе мин.

Башта Хәмзә абый остаханәсендә бөтен эшне үзе генә башкара. Клиентлар арта, заказлар күбәя башлагач, өлгерә алмам, дип, бер ярдәмче ала. Аннары тагын икене, дүртне. Шул рәвешле тулы бер команда белән тирә-як авылларны гына түгел, районнарны да имәннән ясаган урындык, өстәл, караватлар белән тәэмин итә башлый. 2007 елда яңа йорт җиткерә. Балалар да үсеп җитә. Кыскасы, тормышы түгәрәкләнә. Тик... озакка түгел.

– Миңа Аллаһы Тәгалә гел кыенлыклар белән көрәшергә язгандыр, – ди Хәмзә абый. – Гомер иткән хатыным авырып, урын өстенә ятты. Аны карап, соңгы юлга озаттык. Безгә ярдәм итәргә дип, улыбыз да, өйләнеп, төп йортта калган иде. Ике яшьлек чәчәк ке-

– Ике миллион сум кредит алдым, авыл кешеләре дә бик булышты, Алланың рәхмәте яусын! Цехны монда эшләүче егетләр белән төзедек, – ди Хәмзә Зиннәтуллин.

бек оныгыбыз яман шештән үлеп китте. И, кайгырганнар...

Шулай да Хәмзә абый төшенкелеккә бирелми. Ир уртасы бит әле, ялгыз яшәп булмас, дип, берәр хатын-кыз белән танышу җаен карый. Танышу игъланыннан Сәрия исемле ханымның телефонын язып ала. Аралаша башлыйлар.

– Өйдә генә эшли торган, намаз укый торган хатын булсын дип теләдем, – ди Хәмзә абый. – Теләкләрем кабул булды. Сәрия нәкъ шундый. Җайлы, сабыр һәм бик тырыш. Казандагы бар тормышын, эшен ташлап минем янга кайтырга булды. Башта ышанмаган да идем.

– Ник алай дисең, хатын-кыз кызыгырлык ир бит син, – дип сүзгә кушылды Сәрия апа. – Тормыш иптәшем вафат иде. Балаларның үз тормышы. Ике дә уйламыйча кайттым.

Никахлашып бер ай узганнан соң ихаталарында янгын чыгып, ир белән хатын бер кат күлмәк белән урамда басып кала. 2014 елның ноябрь ае була ул.

– Иртәнге дүрттә янгын чыкты, – диде хуҗа кеше. – Цехтан башланды. Ялкын тиз арада йортка, каралты-курага да үрмәләде. Әле үзебез исән калдык. Сәрия китәр инде дип уйлаган идем.

Сиңа бер тәлинкә аш булганда, миңа да табылыр, диде.

Ике ай дигәндә, Хәмзә абый цехын торгыза.

– Нинди акчага? – дим.

– Ике миллион сум кредит алдым, авыл кешеләре дә бик булышты, Алланың рәхмәте яусын! Цехны монда эшләүче егетләр белән төзедек. Андый очракларда район җитәкчеләренә караганда, гади кешеләр күбрәк хәлеңә керә икән, шуңа инандым.

Йортны исә майда эшли башлап, июль уртасына өлгертәләр дә. Иминиятләштерү фонды 1 миллион 500 мең сум күчерә. Нигездә, шул акча җитә дә. Зиннәтуллиннарның бүгенге тормышын язып тормыйм, күз тиюдән куркам. Шуны гына әйтәм: бөтен җирләре – чәчәктә, тормыш кайный биредә. Икесенә – биш бала, сигез онык, кода-кодагыйлар...

– Бу безнең йорт кына түгел, ул кибет вазыйфасын да үти, – дип, Хәмзә абый үзләре эшләгән җиһазларны күрсәтеп йөрде.

– Килгән кешеләрне дә шулай өйгә чакырам. Татар тотып карамый ышанмый бит.

– Иң күп заказлар нәрсәгә? – дим.

– Баскычларга. Унлап заказ әзер инде. Әле егетләр тагын эшли.

– Бәяләре күпме? – дип кызыксынам.

– Имән баскыч – 150 мең сум, каенныкы – 100 мең. Халык күбрәк имәннән эшләтә. Мәңгелек бит, затлы да.

– Җиһаз ясау өчен агачны кайдан аласыз?

– Нигездә, Чувашиядән. Үзем дә барып алам, китереп тә бирәләр.

...Менә шундый язмыш. Нинди ачы хәсрәтләр күреп тә, егылмаган, сыгылмаган ул. Соклангыч.

ТАРИХ БИТЛӘРЕННӘН

«Аксу авылы моннан 300 еллар элек оешкан дип фаразлана. Болында, Бола елгасыннан 1 чакрым ераклыкка, Аксу исемле кеше килеп утырган, диләр. Тора-бара аның янына 6–7 гаилә дә килеп урнаша. Аксу бабай хөрмәтенә авылга шундый атама бирәләр.

Чит кешеләрдән сакланыр өчен, авылның тирәюнен койма белән әйләндереп алалар. Анда бер капка да була. Ләкин болай яшәү тора-бара халыкта ризасызлык тудыра, чөнки койма белән әйләндереп алынган кечкенә авылда кешеләр бер һөнәр белән дә шөгыльләнә алмый. Шуннан соң бу койма сүтеп алына, тулы урамнар хасил була. Халык игенчелек белән шөгыльләнә башлый. Аның даны күрше салаларга да тарала. Кешеләр белемгә, дингә омтыла».

Фәридә Нургалиева, Аксу авылы китапханәчесе.

ПСИХЕЯ һӘМ ТАНТАНАЛЫ БАЛ

Ике «фея» җиңел зур ташны каплаган япманы тартып төшерә. Иң өстә – кыз бала. Аның хыялый карашы каядыр еракка төбәлгән, аркасында бәләкәй генә күбәләк канатлары җилпенгән хәлдә туктап калган… Әлеге гүзәлнең исеме «тын, сулыш» яки «күңел» дигәнне аңлата, грек теленнән тәрҗемә итсәк – Психея…

Әлеге сынлы композициянең идеясен ТР Республика клиник психиатрия дәваханәсенең коллективы уйлап чыгарган. Аны Татарстанның психиатрия хезмәтенә 150 ел тулуга багышлап, гамәлгә ашырырга тырышканнар. Хәзер акыл сәламәтлеген яклаучысының сыны республиканың иң өлкән махсуслаштырылган клиникасы каршына куелган. Ташка әлеге медицина учреждениесенең беренче һәм аннан соңгы җитәкчеләренең исемнәре уеп язылган. Шул рәвешле Психея биредә – шәфкатьлелек гәүдәләнеше генә түгел, ә тарихка баш ию, ихтирам билгесе дә.

Хезмәттәшләрен түгәрәк даталары белән котлар өчен, Россиянең барлык почмакларыннан ике йөздән артык фәнни хезмәткәр һәм табиб-психиатр килгән. Докладлар, фикер алышулар һәм рәсми котлаулардан соң, барысы да «Бехтерев янына» тантаналы балга җыелды – Татарстан клиникасы әлеге легендар психиатр исемен йөртә бит. Мазурка һәм полонез, кадриль һәм вальс… Төрле костюмнардагы табиблар һәм кунаклар вальс әйләнгәндә, күбәләк канатлы кыз аларны дикъкать белән күзәтеп торды. Психея бу турыда хыяллана алдымы икән?

Фото: Александр Ефремов

ТАССРНЫҢ 100 ЕЛЛЫГЫНА

БАГЫШЛАНГАН УНИКАЛЬ ОТКРЫТКАЛАР КОЛЛЕКЦИЯСЕН ҖЫЙ



Казан. Пушкин урамы. 2019 ел.

Фото: Александр Ефремов

ТАССРның 100 еллыгына

багышланган уникаль открыткалар коллекциясен җый

Казан. Куйбышев урамы. 1973 ел. «Вузовец» кинотеатрында «Командир счастливой «Щуки» фильмы бара. Фото Абдулла Дубин коллекциясеннән.